**Ключевые слова:** *революционные обороты; гражданская война; Октябрьская революция; историко-биографический роман.*

# HISTORICAL EVENTS IN TATAR LITERATURE OF THE TWENTIETH CENTURY

***Antonova Diana Anatolyevna***
***Dautov Gumar Filgizovich***
Elabuga Institute of Kazan (Volga Region) Federal University,
Elabuga, Tatarstan, Russia

**Abstract.** *The first half of the XX century is a period rich in historical events. From the first years of the XX century, revolutionary movements began to gain momentum in Russia. In this article we get acquainted with such novels as "Our Days", "Deep Roots", "Daughter of the Steppe", written this year. We also analyze the works of such people as Shamil Usmanov, Kavi Najmi, created during these years.*

**Keywords**: *revolutionary revolutions; civil War; October Revolution, historical and biographical novel.*

XX йөзнең беренче яртысы тарихи вакыйгаларга бай чор. XX гасырның беренче елларыннан ук Русиядә инкыйлаби хәрәкәтләр, күтәрелешләр көчәя башлый. Моның сәбәбе: халыкның яшәп килүче самодержавие патша строе белән килешмәве, тормышта феодал, крепостной калдыклары булуы, чиновникларның башбаштаклыгы, халыкны изеп тотуы. Халык изелүгә чыдый алмыйча хокуксызлыкка нәфрәтен белдереп төрле хәрәкәтләрдә катнаша башлый. Халыкта демократик тәртип урнаштыру, демократия төзү максатка әверелә. 1905 елгы инкыйлабның төп үзенчәлеге дә шунда – халыкларны милли азатлык хәрәкәтенә күтәрү. 1905-1907 елгы инкыйлабтан соң илдә сүз иреге игълан ителә, татарлар яшәгән төбәкләрдә вакытлы матбугат барлыкка килә. Аерым язучыларның китаплары бастырып чыгарыла. Иң күп тираж белән Гаяз Исхакый, Габдулла Тукай китаплары чыга. XX йөз башында татар әдәбияты тиз арада үсеп китә. Төрле әдәби юнәлешләр, стильләр, иҗат методлары барлыкка килә. Идея-тематик яктан да әдәбият нык дәрәҗәдә киңәя. Төп темаларның берсе булып – милләт һәм дин проблемасы күтәрелә.

Галимҗан Ибраһимов татар совет әдәбиятында беренчеләрдән, инкыйлаб, гражданнар сугышы вакыйгаларын, егерменче еллар башында авылда һәм шәһәрдә җәелгән кискен сыйнфый көрәш *картиналарын («Тирән тамырлар» романында, 1926)* [1, б. 595] калку итеп сурәтли. Галимҗан Ибраһимовның иҗат колачы милли кысаларда гына чикләнеп калмый, ул инкыйлабка кадәрге чор казакъ тормышының социаль һәм ыруглык каршылыкларын искиткеч

тирән һәм тәэсирле итеп ачкан *«Казакъ кызы» (1923) романын иҗат итә* [2, б. 611], әүвәлрәк язылган *«Татар хатыныниләр күрми»* повесте белән *«Безнең көннәр»* романының яңа вариантларын бирә. *“Безнең көннәр”* романы басылып чыгу татар әдәбиятында зур вакыйга була.

*“Безнең көннәр”* романында гражданнар сугышы, инкыйлаб еллары сурәтләнә. Төп геройлар Булат, Гәрәй, Гриша, Давыт – революционерлар. Алар – якты киләчәк, бөтен җирдә тигезлек өчен көрәшүчеләр. Алар якты бәхетле тормыш власть патша кулыннан, гади халык – эшчеләр, крестьяннар кулына күчкәч башланачагына чын күңелдән ышаналар. *“Безнең көннәр”* романында вакыйгалар шәһәр җирлегендә барса, *“Тирән тамырлар”*да авыл җирлегендә. *“Тирән тамырлар”* романында яңа тема – илне социалистик үзгәртеп кору темасы күтәрелә. Роман ревком рәисе Фәхринең үле гәүдәсен табудан башлана. *“Безнең көннәр”*дә тискәре герой булып Кадыйр бай сурәтләнсә, *“Тирән тамырлар”* да Вәли бай образы бирелә. Ике әсәрдә дә тискәре геройлар булып башкалардан финанс яктан яхшы тәэмин ителгән кешеләр тора. Кадыйр бай мәдрәсә тотып шәкертләр укытса, мәчеткә сәдакалар биреп тора, Вәли бай – авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнеп авыл халкын эшле итә. Әсәр ахырында ике герой да үтерелә. Бу романнарда социализмга ирешүнең нинди юллар белән барганы, күпме корбаннар китергәне ачык чагылыш тапкан. Галимҗан Ибраһимов бу әсәрләрендә шул чорда булган инкыйлаби рухны бүгенге чор кешеләренә дә җиткерә.

*“Казакъ кызы”* романында Галимҗан Ибраһимов иҗтимагый-сәяси темаларны көнкүреш белән тыгыз бәйләнештә бирә. Әсәрдә барган вакыйгалар XIX гасыр ахырына – XX гасыр башына карый. Бу вакытта казах далаларының Россия белән кушылу процессы бара. Киң далада җир өчен, власть өчен ыруглар арасында тарткалаш китә. Галимҗан Ибраһимов казакъ хатын-кызларының тормышын, аларның җәмгыятьтә, илдә тоткан урынын бәян итеп менә шушы борчулы, тынгысыз тормыш белән бергә үрелдереп барган. Әсәрнең төп героинясы – казакъ кызы Карлыгач-Сылу образы аша казакъ хатын-кызларының гына түгел, мөселман хатын-кызларының да иреккә, хөрриятькә тартылган күңелләре тасвирланган. Язучы халык тормышының эченә үтеп кереп, шул чорда казах далаларында яшәүчеләрнең социаль проблемаларын ачып сала ала.

Октябрь инкыйлабы сәяси, икътисади һәм иҗтимагый тормышка да, шул исәптән әдәбият-сәнгать өлкәсенә дә үзгәрешләр алып килә. Корал ярдәмендә хакимиятне яулап алган большевикларга да хакимиятне саклап калырга да кирәк була, шуңа күрә алар агитация һәм пропагандага зур игътибар бирәләр, шул максатлардан сүз сәнгатенә дә кискен таләпләр куела. Ягъни, икенче төрле әйткәндә, әдипләргә нәрсә язарга һәм ничек язарга дигән күрсәткечләр бирелә һәм алар үтәлмәгән очракта язучының әсәрләре дөнья күрми, үзе исә әдәбият мәйданыннан читләштерелә.

Совет матбугаты үзенең беренче адымнарын күренекле әдипләрне матбугат эшенә тарту белән башлап җибәрә. Гражданнар сугышы елларындагы әдәбиятның төп үзенчәлекләренең берсе – компартиянең әдипләрне, публицистларны милли матбугат тирәсенә туплавы. Большевистик рухлы татар гәҗитләре Россиянең татарлар яшәгән күп кенә төбәкләрендә чыгып киләләр. Гражданнар сугышы елларында фронт гәҗитләре оештырыла. Шушы чорда әдәбиятта Шамил Усманов, Кәрим Тинчурин һ.б беренче әсәрләре басылып чыга.

Шамил Усманов – әдәбият мәйданына турыдан-туры гражданнар сугышы эченнән, совет власте өчен үз-үзен аямыйча көрәшкән кызыл гаскәр арасыннан күтәрелеп чыккан язучыларның берсе. Аның тәүге иҗат тәҗрибәләреннән булган *«Канлы көннәрдә»* һәм *«Беренче адым»* драмалары сугышның иң кызган чорында – 1919 елда языла һәм кульъязма хәлендә фронт сәхнәләрендә уйналып йөри. Шамил Усманов 1923-1935 еллар арасында үзенең зур әсәре, аның иҗат юлын билгели торган – *«Легион юлы» («Тургай далаларында»)* исемле дилогиясе өстендә эшли. Реаль тарихи фактларга нигезләнгән бу повестенда автор төрле милләт вәкилләреннән оешкан интернациональ кызыл гаскәр легионының гражданнар сугышы чорында ак казакларга каршы алып барган героик көрәш юлын сурәтли һәм шул киеренке, драматик шартларда инкыйлаби массаның корыч ихтыяры, бердәмлеге формалашуын җанлы картиналар һәм үзенчәлекле кеше характерлары аша күрсәтә. Әсәрдә

яхшы коралланган дошман белән авыр көрәш алып баручы интарнациональ легионның көндәлек тормыш-көнкүрешләре сурәтләнә. *“Легион юлы”* – автобиографик әсәр. Ул авторның истәлекләреннән, легион хәрәкәт иткән юлда булган вакыйгалардан тора. Автор әсәрне үз исеме – легион командиры исеменнән сөйли. Романда көрәш һәм көрәшкә булган мөнәсәбәт күрсәтелә. Геройлар авторны күбрәк солдат буларак кызыксындыра, ул аларның шәхси билгеләренә әллә ни игътибар бирми.

Егерменче елларда Кави Нәҗми зур активлык белән әдәби иҗат эшенә керешә. Гражданнар сугышы аша социализмга килүен, яңа тормыш төзи башлавын реалистик картиналар һәм образлар аша сурәтләгән *«Яр буенда учаклар» (1928), «Якты сукмак» (1929), «Крошлы яңгыр» (1930)* повестьлары белән ул шул чор татар совет язучыларының алдынгы сафына баса. Сугыштан соң, 1948 елда, Кави Нәҗми үзенең озак һәм күп көч салып эшләгән төп әсәрен – *«Язгы җилләр»* исемле тарихи-революцион романын тәмамлый. *«Язгы җилләр»* – зур тарихи вакыйгаларны эченә алган күп геройлы һәм күп планлы әсәр. Әдип анда татар халкының инкыйлаби үзгәрешләр чорындагы тарихи юлын, татар эшчеләренең сыйнфый аңы уянуын һәм башка халыкларның пролетариаты белән бергә самодержавиегә каршы инкыйлаби көрәш мәйданына аяк басуын һәм җиңүгә ирешүен җанлы итеп тасвирлый. Шунысын искәртү зарур, 20-30 еллар татар әдәбиятында үткәннәр белән кызыксыну арта. Моны М.Галәүнең “Болганчык еллар”, “Мөһәҗҗирләр”, Ш.Усмановның “Легион юлы”, А.Шамовның “Днепр буенда”, “Бер мәхәббәт турында” әсәрләрендә күрергә мөмкин. Әйтелгән мисалларда чагылыш тапкан татар тарихи революцион прозасында, әлбәттә, алгы планга сыйнфый көрәш чыгарыла. Бу хәл гомумсовет әдәбиятына хас булып тора.

Бу чорда иҗат ителгән тарихи-революцион әсәрләрнең үзәгендә, кагыйдә буларак, конкрет-тарихи шәхес түгел, ә уйлап чыгарылган герой тора, аның язмышы тарихи яшәеш һәм чор вакыйгалары аша чагылдырыла. Сюжет сызыгын тарихилык белән кушып алып бару аерым бер схема аша башкарыла. Г.Ибраһимов төн биргән “тормышның төбеннән күтәрелгән” кешене күрсәтү өчен, геройлар тормышы авылда башланса да, тора бара, сәяси вәзгыять дулкыннары белән алар зур шәһәрләргә күчереләләр.

Язучыларның бердәм союзы оештырылу әдәбиятның тагын да үсеп китүенә зур этәргеч булды. Төрле әдәби органнарда социологик идеяны фаш иткән күп кенә хезмәтләр басылып чыга башлый. Утызынчы еллар әдәбияты илдәге социалистик төзелешкә актив катнаша. Ул һәртөрле изелүләргә дучар булган кешеләрне үзенең герое итеп ала, аның уңай сыфатларын гына күрсәтеп тасвирлый. Прозада заман темасы алга чыга. *Галимҗан Ибраһимовның “Безнең көннәр”*нең яңа басмасы, *Шәриф Камалның “Матур туганда”* романы моның ачык мисалы.

Узган гасырның 60 елларында “Хрущев җепшеклеге” исеме белән тарихка кергән, беркадәр демократия урын алган чор әдәбият-сәнгать өлкәсенә беркадәр уңай йогынты ясый. Әмма җитмешенче еллар башында партия йогынтысы янә көчәя һәм ил тормышында “торгынлык” исеме алган вакыт башлана. Ләкин, 60 еллардагы иркенлек, хакыйкатьне төемлау һәм язу ләззәте әдипләрне калдырмый. Шушы башлангыч һәм тарихчыларның яңа ачышлары белән рухланган Н.Фәттах һәм М.Хәбибуллин үткәннәргә мөрәҗәгать итәләр. 1972 елда Н.Фәттахның “Ител суы ака торур” романы дөнья күрә. Әлеге әсәр Х.Әшрәфҗанов тарафыннан “Ител суы ака торур”ның нәшер ителүе татар тарихи романының үсеш тарихында яңа дәвер башлану турында хәбәр итә” дип бәяләнә.

1994 елда әдипнең тагын да колачлырак әсәре “Сызгыра торган уклар” дилогиясе дөнья күрә. Гаять зур тырышлык һәм фидакарьлек белән язылган бу әсәр татар әдәбиятында зур вакыйга буларак кабул ителә.

1980 еллар уртасыннан башланган сәяси, иҗтимагый үзгәрешләр татар әдәбиятына яңа рух өрә. 1984 елда “Кубрат хан” романы белән яңа сәхифә ачып җибәргән М.Хәбибуллин, демократик үзгәрешләрнең шифалы йогынтысы астында бер-бер артлы “Илчегә үлем юк” (1989), “Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный” (1992), “Хан оныгы Хансөяр” (1994) кебек әсәрләрен чыгара.

1960 – 1980 еллар татар прозасында үткәндәге күренекле тарихи шәхесләргә багышланган әсәрләр дә әһәмиятле урын алып торалар. *Атилла Расихның “Ямашев”*

*трилогиясе, Габдрахман Әпсәләмовның "Күк күкрәр"* романнарында тарихи шәхесне гәүдәләндерүгә авторлар үз чорлары таләпләреннән чыгып күрсәтәләр. Атилла Расих трилогиясендә Хөсәен Ямашевның инкыйлаби эшчәнлеген чагылдыру белән беррәттән автор XX йөз башындагы татар җәмгыятенә һәм үзәк герой яшәешенең шәхси ягына да игътибар итә. Нәтиҗәдә әсәрдә ул вакыттагы шактый катлаулы татар дөньясы картинасы һәм Хөсәен Ямашевның каршылыклы яшәеше күзаллана.

Йомгаклап, шуны әйтергә кирәк, хәзерге әдәбиятта чынбарлыкка карашның тирәнәюе авторларның иҗат индивидуальлеге киңәюгә китерде. Әдипләр әсәрләрдә сурәтләнгән чорны масштаблырак һәм тулы канлырак итеп күрсәтүгәирешәләр. Роман – прозаның аеруча катлаулы һәм кыен төре, язучыдан зур осталык, масштаблы фикер, искиткеч куәт һәм дәрт сорый торган төре. Ул – заманның үзәгеннән, тормышның магистраль юлыннан бара торган жанр. Ә соңгы ун-унбиш ел әдәбиятына килгәндә роман жанры тагын да акивлаша төште, моны Р.Сверигин сүзләре белән дәлилләргә була: *«Әдәбиятыбызның казанышы дип саналырдай байтак әсәрләр иҗат ителде. Шуңа күрә, әдәбият ярлыланды, саекты дияргә җирлек юк. Матур, тирән мәгънәле әсәрләрнең бүген дә язылып һәм басылып торган көне. Тик соңгы вакытта күрә-күрсәтә белү ягы гына шактый кыенлашты»* [3, б. 78].

**Әдәбият**


1. Ибраһимов Г. Тирән тамырлар / Г. Ибраһимов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1956. – 595 б.
2. Ибраһимов Г. Казак кызы: роман, хикәя / Г. Ибраһимов. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1957. – 680 б.
3. Сверигин Р. Хәзерге татар совет прозасының кайбер әдәби-стиль үзенчәлекләре турында. – Кит.: Татар әдәбияты мәсьәләләре. 6-җыентык Казан: 1974. – 51-78 б.


УДК 821.512.145

## ЛИТЕРАТУРНО-ЭСТЕТИЧЕСКАЯ ЦЕЛОСТНОСТЬ ПОВЕСТЕЙ Р. МУХАММАДИЕВА
## Р. МӨХӘММӘДИЕВ ПОВЕСТЬЛАРЫНЫҢ ӘДӘБИ-ЭСТЕТИК БӨТЕНЛЕГЕ


***Габидуллина Фарида Имамутдиновна***
Елабужский институт Казанского (Приволжского) Федерального университета,
г. Елабуга, Татарстан, Российская Федерация
*e-mail: farida-vip@mail.ru*



**Аннотация.** *В статье анализируются повести Рината Мухаммадиева. Он – один из авторов, внесших большой вклад в развитие татарской литературы конца XX – начала XXI века. В данной статье выявляются особенности творчества писателя, проблемно-тематическое своеобразие его повестей, роль символов, художественных деталей. Особое внимание уделяется авторской трактовке проблем современной жизни, способов создания образов.*



**Ключевые слова:** *литература; Р.Мухаммадиев; проза; повесть; проблема; идея.*


## LITERARY AND AESTHETIC INTEGRITY OF R. MUKHAMMADIEV'S NOVELS


***Gabidullina Farida Imamutdinovna***
Elabuga Institute of the Kazan (Volga region) Federal University,
Elabuga, Tatarstan, Russia.

**Abstract.** *The article analyzes the stories of Rinat Mukhammadiev, one of the authors who made a great contribution to the development of Tatar literature of the late XX – early XXI century. The features of the writer's creativity, the problem-thematic originality of the stories, the role of symbols, artistic details are revealed. Special attention is paid to the author's interpretation of the problems of modern life, ways of creating images.*
**Keywords**: *literature; R. Mukhammadiev; prose; novel; problem; idea.*

Татар прозасына классик әдәбият традицияләрен дәвам итеп килеп кергән Ринат Мөхәммәдиев үзгәртеп корулар дәверендә җәмгыятьтәге авыру гадәтләрне, сыйфатларны, совет идеологиясе алып килгән коллык психологиясен, милли-әхлакый нигезләрнең җимерелүен аяусыз тасвирлаган әсәрләре белән киң танылу ала. Иҗтимагый-сәяси үткен проблемаларны милли мәнфәгатьләр ноктасыннан яктырта алган повесть-романнары XX-XXI гасырлар чиге татар прозасында лаеклы урын били. Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Ринат Сафа улы Мөхәммәдиев күп санлы әдәби иҗаттагы уңышлары белән бергә, Р. Мөхәммәдиев актив җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе буларак та киң танылa.

Р. Мөхәммәдиев сүз сәнгатенә әдәби тәнкыйть өлкәсеннән килә. Фәнни әзерлеге, дөнья әдәбиятын яхшы белүе, сүзгә талымлыгы һәм бай тормыш тәҗрибәсе эзсез калмый – беренче әсәрләре үк әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итә, тәнкыйть тарафыннан уңай бәяләнә. Балаларга атап язылган «Яңа елга күчтәнәч» (1979) китабыннан соң дөнья күргән «Беренче умырзая» (1985) җыентыгына туплап бирелгән повестьлары татар әдәбиятына хискә бай, оста күзәтүче, сүз-сурәтнең бай төсмерләренә ия язучы килүен хәбәр итә. «Беренче умырзая» (1982) повесте, утыз яше тулып узган әдипнең күләмле тәүге әсәре булуга карамастан, татар әдәбиятының казанышы дип бәяләнә. «Каләм әһелләренең шундыйлары була, алар беренче әсәрләре белән үк җитлеккән язучы икәнлекләрен раслыйлар, ягъни вакытларын өйрәнчеклек чорына сарыф итеп тормыйлар. Р. Мөхәммәдиевкә килгәндә, ул әдәбияттагы өлгерү чорын әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеме белән шөгыльләнү чорында кичерде»[1, б. 6], – дип яза бу хакта Ф. Галимуллин.

«Беренче умырзая» – татар авылы, аның эчкерсез яшьләренә, гаҗәеп табигатенә дан җырлау кебек тә, татар авылларындагы үзгәрешләрне күреп борчылу, чаң сугу буларак та, яшьлек, мәхәббәт, хыянәт кебек интим-лирик кичерешләрне психологик тегәллек белән сурәтләгән әсәр рәвешендә дә укыла, аңлашыла. Әдип мөрәҗәгать иткән тема, әдип сурәтләгән дөнья – яңа түгел. 1960 елларда формалашкан «авыл прозасы» агымы вәкилләре авыл һәм шәһәр арасында яткан упкынны сурәтләү; хөкүмәтнең авылга карата алып барылган сәясәтен тәнкыйтьләү; милли кыйммәтләрне эзләп авылга мөрәҗәгать итү; тирә-як табигатьне саклауны ассызыклау; традицион авыл тормышының юкка чыга баруына нисбәтле күңелләрендә туган моңсулыкны укучыларга җиткерүдә чирканчык алалар һәм бу өлкәдә уңышка ирешәләр. Р. Мөхәммәдиев повестенда да авыл, татарларның электән килгән таянычы, туендыручысы һәм илһамчысы буларак, кадерле мирас югарылыгына күтәрелә. Мәктәп укучысы, 17 яшен тутырып килүче Рәхимҗан яңа тормыш коручы, авыл чишмәләрен күмеп буа ясарга омтылучы баш инженерлардан акыллырак, рухи бөтен шәхес булып күз алдына баса. Язучыга герое тормышын, язмышын хәлиткеч мизгелдә тасвирлау мөһим: Рәхимҗан, башка яшьтәшләре кебек үк, сайлау алдына куела. Бу сайлау я авыл, я шәһәр файдасына карата башкарылырга тиеш. Бабасы Төхфәт тәрбиясенең шифалы йогынтысын тоеп үскән егетне бик күп сораулар борчый: «сабый чакта ук «зиһенле бала, үскәч калага китәр, укып зур нәчәлник булыр», дип сөйделәр аны. Укырга йөри башлагач, инде үзенең күңелендә сәяхәтче булу, инженер яисә очучы булу хыяллары бер-бер артлы уяна торды. Әтисе: «Геолог булырсың, улым, табигатьне, сәяхәтне бик яратасың», – дия килде. (...) Физика укытучысы авиация институтына барырга киңәш итте, химия укытучысы: «Киләчәк химиклар кулында», – диде. Әдәбият дәресләрендә аларны шигырь язарга, шагыйрь булырга димләделәр, чит тел укытучысы – төрле илләргә тәрҗемәче булып йөрү турындагы татлы хыялларга нигез салды. (...) Ләкин, әлегәчә, Рәхимҗанның һичкем авызыннан авылда калырга, иген игәргә» [5, б. 208] дигән сүз ишеткәне булмады.

Авылның шифалы сулы чишмәләренә, шаулап иген үскән басуларына карап, Рәхимҗан үзен дә, укучыны да авылның яшәеш чыганагы икәненә инандыра. Шул ук вакытта укучы күз алдына яшәеш фәлсәфәсе заманга яраклашкан, Рәхимҗанныкына каршы килгән образлар галереясы да килеп баса. Баш инженер, проект та төзеп тормыйча, авыл туфрагын бульдозерлар белән изәргә, чишмәләрне су астында калдырырга, меңъяшәр иманнәрне тамыры белән йолкытырга риза: тизрәк һәм очсызрак кына булсын. Авыл хатыннары инде чишмәдән су алып кайту түгел, колонкадан да алырга иренә башлаганнар. Уяусызлык, гамьсезлек, табигатькә һәм авылга битарафлык аркасында Нурлы Алан матурлыгы су астында кала яза. Бәхеткә, фаҗигагә юл куелмый.

Чишмәләр тарихы, авылның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турындагы бәянын язучы мәхәббәт сюжеты белән үреп бирә. Әсәрдә яшьләр күңелендә бөреләнгән беренче мәхәббәт хисләреннән алып, язмыш сынауларында адашып, үзләренә яисә бер-берсенә хыянәт иткән кыз-егетләр тормышы укучы күңелендә дә төрле истәлек-хатирәләрне яңарта, мәхәббәт һәм нәфрәт, матурлык һәм ямьсезлек, гаилә һәм тормыш турында җитди уйлануларга алып килә.

Язучының «Беренче умырзая» повестенда авыл хронотобы башкарган мөһим вазифа алдагы әсәрләрендә дә күзәтелә. «Ак кыялар турында хыял» (1984) повестенда Нурлы Алан авылы, бер яктан, гаҗәеп табигате, матурлыгы белән әсир итә, икенче яктан, әсәрнең беренче битләрендә үк авылдагы гореф-гадәтләргә, көнитеш үзенчәлекләренә кергән үзгәрешләр укучыны сискәндереп җибәрә. Җырлый-җырлый эшләргә, җырлый-җырлый ял итәргә күнеккән, бәйрәмнәре дә җыр белән бизәлгән татар халкы традициясе биредә көтелмәгәнчә дәвам иттерелә:

Аракы – арыш мае,

Эч әле, карышма әле, – дип сыйлый туй кунакларын Хуҗа абзый.

Аракыны, виноны

Бик яратам мин аны [5, б. 221], – дип җавап кайтаралар канәгать кунаклар.

Туй гөрләгән йорттагы ата кешенең исеме Хуҗа булу һәм аның кулындагы шешә авторның кисәтүе, символ төсендә кабул ителә. Әсәрнең беренче битендә шешә кеше кулында булса, ахырга битләрдә кеше шешәнең колына әверелүе ассызыклана: «Греклар төзегән пирамиданңны да, Сөембикә манарыңны да бәреп ега ул безнең шешә! Пирамидалар җансыз катып калган диләр. Ә Сөембикәсе бөтенләй авышып бара анда. Ә безнең шешәләр менә чылтырап тора. (...) Шешә – безнең нигез, егетләр» [5, б. 224]. Шул рәвешле, язучының үткен сатирасы – экзистенциаль сарказмга әверелә.

«Ак хыялар турында хыял» – авылның рухи нигез баганалары юкка чыгу, аның деградациясе турындагы әсәр генә түгел. Бу аның әһәмиятле беренче катламы гына. Микәй һәм аның ак кыялар турындагы хыялы белән автор икенче катламны – фәлсәфи катламны хасил итә, әмма ул эзоп теленә хас киная, яшерен мәгънәгә төренгән. Микәй – табигатьнең баш бирмәс, риясыз җанлы баласы, бар авылны сокландыручы. Матурлыгы белән бергә, ныклы ихтыярлы, баш бирмәс холкы белән аерылып тора. Әмма әсәр дәвамында ул инде бөтенләй башка сурәттә тасвирлана. Башта – тәмәке, аннары – аракы эчәргә күнеккән кәҗә хыялын да, горурлыгын да оныта, аның бар теләгәне – тәмәке суыру, аракы дигән зәһәр сыеклыкны эчү. Болар аны һәлакәткә китерә дә. Әмма чокыр төбендәге физик үлемнән алда ук Микәй инде рухи яктан да юкка чыккан була.

Микәй – асылда, кол халәтенә китерелгән җан иясе. Әлеге аллегорик һәм символик образ аша әдип, бер яктан, чит җирдә җан иясенең чын бәхетне таба алмавын искәртсә, икенче яктан, бөтен тереклек дөньясына янаган куркыныч турында кисәтә. Әлеге аяныч хәленә үз теләге белән төшми, аның упкынга тәгәрәү мизгелен әкрен-әкрен ул ышанган кешеләр якынайта, биек тау-кыялар турындагы хыялның чокыр төбе белән тәмамлануына төп сәбәпче дә алар. «Автор биредә җисмән тауларны гына түгел, бәлки халкыбызның элек-электән үзен башка кавемнәрдән ким-хур сизмичә, киресенчә, дәүләтчелеген тәэмин итүдә бик күпләр хыяллана да алмаган биеклекләргә ирешеп гомер кичергәнен дә искәртә» [1, б. 6]. Шул рәвешле әсәрдә яуларда баш бирмәгән, көчләп чукындыру сәясәтенә карамастан, иманын саклап кала алган, репрессияләрдә күпме асыл затларын югалтып та үзе югалмаган татар милләтенең үз теләге,

ихтыяры белән упкынга тәгәрәвенең сәбәпләре, шуңа юл куйган, шуны хуплаган идеология ачып күрсәтелә. Сурәтләнгән материалны белеп язуы, сюжет-композиция бөтенлеге, образ-характерлар эшләнеше, символлар, әдәби детальләр аша яшәешнең четерекле якларын ачу осталыгы белән әлеге повесть киң яңгыраш ала.

«Истәлек өчен – Гыйлемханга» (1985) повестенда язучы капиталистик мөнәсәбәтләрнең авыл җирлегенә дә үтеп керә башлавын күрсәтә. Әсәрдә 40 ел буе шахтада эшләп, ниһаять, туган авылына кайткан Гыйлемхан гаять бай күңелле шәхес итеп күз алдына бастырыла. Аңа каршы китереп бригадир Нәҗип сурәтләнә. Бу ике кешенең һәрберсенең яшәү фәлсәфәсе, үз карашы һәм ул карашның асылын аңлатучы «йөзлеге» бар: Гыйлемханның тәрәзә йөзлекләре – авыл халкына матурлык бирүче, ямь өстәүче булса, Нәҗип йөзлекнең кыштырдый торганын гына белә, ул, гомумән, матурлык төшенчәсе белән таныш түгел: «кешенекеннән ким түгелме? Түгел! Нәмә кирәк тагы...» [4, б. 328] дигән принцип белән яши ул.

Гыйлемханның күңелен Нәҗип генә түгел, Дәү апасының балалары Гөлчирә белән Гөлсинә дә яралый. Авылда үсеп кеше булган, аннары, заман шаукымына ияреп, кайсы Бохарага, кайсы Кемеревога китеп барган, хәтере югалган мондый образлар Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять», А. Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән» әсәрләрендә дә сурәтләнә. Билгеле булганча, совет җәмгыятен кору хәтерне җимерүгә нигезләнеп башкарылды, хәтерне юкка чыгару яңа якты киләчәк төзү өчен төп шарт буларак ассызыкланды. Элекке мәдәният, тарих, гореф-гадәтләр җимерелүгә, юкка чыгарылуга дучар ителделәр. Мондый шартларда тәрбияләнгән шәхес туган авылын да, ата-анасын да бик тиз онытырга сәләтле. Шунысы үзенчәлекле: А. Гыйләҗевнең Бибинуры да, Р. Мөхәммәдиев әсәрендәге Дәү апа да балаларын гаепләп чыкмыйлар, аларны яклау өчен йөз сәбәп табалар. Әмма Гыйлемхан авызыннан әдип укучысы алдына җитди сораулар куя: «Үзләрен карынында йөртеп, тәрбияләп үстергән газиз ананы оныткан ул хатыннарны ничек җир күтәрә? Мөгаен, алар үзләре дә ана яисә күптән әби булырга өлгергәннәрдер. Үчти-үчти итеп оныкларын сөя, тәрбияли, аларны әхлакка өйрәтә торганнардыр. Дистә еллар дәвамында газиз анага кош теледәй хат язып сала белмәгән балалардан нинди тәрбия?... Ул сабыйлар кем булып үсәр икән?!» [4, б. 332].

Р. Мөхәммәдиев әсәрләренең нигезен үзе күргән-белгәннәр тәшкил итә. Аңа исә, язучы һәм редактор, сәясәтче һәм депутат, иҗтимагый һәм мәдәни эшлекле буларак дөньяны күп гизәргә туры килә. Болар әдипкә бай тормыш тәҗрибәсе бирә, әдәби материал булып та хезмәт итә. Язучы тормышында һәм ил күләмендә әһәмиятле вакыйгалар – 1991 елгы август, 1993 елгы сентябрь-октябрь вакыйгалары. 1993 елның 3-4 октябрендә Югары Совет тарафдарларының Мәскәү мэриясе бинасын алуы. Моңа җавап рәвешендә Б.Н. Ельцин Мәскәүдә гадәттән тыш хәл игълан итә һәм Ак йортны штурм белән басып алырга әмер бирә. Канлы переворот нәтиҗәсендә илдә буржуаз хакимият урнаша. «Утлы таба өстендә» (1995) документаль әсәрендә әнә шул көннәр сурәтләнә. Әлеге әсәр, бер яктан, Россия тарихының кан исе килеп торган, әмма әдәбиятта, бигрәк тә татар әдәбиятында бөтенләй диярлек яктыртылмаган сәхифәләренең укучыга шуның җанлы шаһите булган язучы тарафыннан тасвирлануы белән игътибарга лаек булса, икенче яктан, «Татарстан – суверен дәүләт. Чит ил парламентын саклап ятмасаң, синә, татар язучысына эш беткән идемени» дип гаеп тагучыларга җавап буларак, «Татарстанның бәйсезлеге тарафындамын. Әмма Россиядә демократия һәм кеше хокуклары сакланмый икән, бу хәл Татарстанга да турыдан-туры тискәре йогынты ясаячак»[3, б. 109], дип яңгырый.

Үзе дә шушы канкойгыч вакыйгалар үзәгендә булган язучыны сәяси уеннар вакытында гади кешеләрнең күпләп кырылуы, имгәтелүе инде беркайчан да тынгылыкта калдырмый. Балалар бакчасыннан кайтканда, мәйданда кешеләр җыелганны күреп тамаша кылырга килгән нәниләрнең тормышы куркыныч астында калуы, Таҗикстандагы афәттән Россиягә качкан һәм балалары белән палаткалар саклап ирен көтеп торган хатынның тынсыз гәүдәсе, әле мәктәпкә дә йөри башламаган сабыйның иясез калган зәңгәр яулыгы сурәтләре, ОМОНнарның мәйданда калган әби-бабайларны, үлгән яки имгәтелгән гәүдәләрне эт үләксәсен ташлаган кебек КамАЗ машиналарына ыргытулары күренеше иҗтимагый-сәяси вазгыятьнең чагылышына әйләнә.

Әдипнең үз әсәрләрендә тормыш чынбарлыгына тугры калуы, вакыйгаларны җанлы итеп күз алдына бастыруы, мавыктыргыч сюжеты, укучыны рухи киеренкелектә тоту осталыгы һәм чор образын тәшкил итүче геройлары белән киң җәмәгатьчелектә яклау таба, күпсанлы тиражлар белән төрле телләрдә басылып чыга.

Күргәнебезчә, Р. Мөхәммәдиев әдәби иҗатның повесть жанрында да үзен иркен хис итә, дөресрәге, аның кечкенә әсәрләргә сыймаган уй-фикерләре нәкъ менә повесть жанрында чагылыш таба. Төрле елларда язылган повестьлары үткен сюжеты, композицион төгәллеге, автор позициясенең ачыклыгы белән аерылып тора. Аның әсәрләренә фикер тыгызлыгы хас, иркен рәвештә диалог һәм монолог төрләрен файдалана, вакыйгаларда төрле әдәби катламнарны үзара ялгап, үреп, повесть геройларын эш-гамәлләренә бәйле психологик яктан ача. Болар укучыга эстетик һәм эмоциональ тәэсирне арттыру мөмкинлеге бирә. Әдип чынбарлык вакыйгалары аша реализмга йөз тотса да, романтик сурәтлелектән һич тә баш тартмый.

Шулай итеп, Р. Мөхәммәдиев үз повестьлары аша укучы белән җитди әңгәмә алып бара, яшәешнең төрле якларын сурәтләп, әхлакый һәм фәлсәфи-эстетик нәтиҗәләр ясауга китерә. Аһәңле тел белән, һәр сүзнең тәмен белеп язылган әсәрләрендә метафора булып килгән күренешләр, ачкыч сүзләр, символлар аша үткәннең һәм бүгенгенең гыйбрәтле хәлләрен, шуларда хәрәкәт итүче тарихи шәхесләрне, замандаш геройларны күз алдына бастыра.

**Әдәбият**


1. Галимуллин Ф. Якутлар табыладыр вакыт белән / Үз кешеләр: хикәяләр һәм повестьлар. – М.: Голос-Пресс, 2011. – 240 б.
2. Мөхәммәдиев Р. Юлда булу хәерле...: хикәяләр, повестьлар . – Казан: Татар. кит.нәшр., 2018. – 161 б.
3. Мөхәммәдиев Р. Утлы таба өстендә (баштан кичкән фаҗига). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 109 б.
4. Мөхәммәдиев Р. Истәлек өчен – Гыйлемханга . – М.: Голос-Пресс, 2011. – 332 б.
5. Мөхәммәдиев Р. Үз кешеләр: хикәяләр һәм повестьлар. – М.: Голос-Пресс, 2011. – 367 б.


УДК 821.512.145

## ИСТОРИЧЕСКОЕ И ЭСТЕТИЧЕСКОЕ ЗНАЧЕНИЕ РОМАНА «СЮЮМБИКЕ» РАБИТА БАТУЛЛЫ «СӨЕМБИКӘ» РОМАНЫНЫҢ ТАРИХИ ҺӘМ ЭСТЕТИК ӘҺӘМИЯТЕ (РАБИТ БАТУЛЛА ИҖАТЫ)

***Ганиева Айгуль Фирдинатовна***
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан,
г. Казань, Татарстан, Российская Федерация
*e-mail: aygulgani@mail.ru*

**Аннотация.** *Сююмбике является не только исторической личностью, она стала национальным образом-символом верности своему народу. Для освещения в литературе исторической личности от писателей требуются как художественное мастерство, так и знание конкретных исторических фактов. В статье исследуется роман Рабита Батуллы «Сююмбике». Автор определяет его историческую и эстетическую значимость в целях пробуждения в читателе национального самосознания.*

**Ключевые слова:** *Сююмбике; Рабит Батулла; историческая личность; образ; герой; национальное самосознание.*

# HISTORICAL AND AESTHETIC SIGNIFICANCE OF THE NOVEL «SYUYUMBIKE» BY RABIT BATULLA

***Ganieva Aygul Firdinatovna***
G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art of the Tatarstan Academy of Sciences, Kazan, Tatarstan, Russia

**Abstract.** *Syuyumbike is not only a historical figure, she has become a national image-a symbol of loyalty to his people. For coverage in literature historical personality from writers are required as artistic prowess, so and knowledge concrete historical facts. The article examines the novel "Syuyumbike"by Rabit Batulla. The author defines its historical and aesthetic significance in order to awaken national consciousness in the reader.*

**Keywords:** *Syuyumbike; Rabit Batulla; historical personality; image; hero; national consciousness.*

Сөембикә образы татар халкы өчен аерым әһәмияткә ия. Ул халык аңында милләт һәм дәүләтчелек төшенчәләре белән бәйле формалашкан. Ханбикәгә карата мәхәббәт һәм хөрмәт хисенең гасырлар буе саклануы язмышы тарихыбызның җәрәхәтле чорына туры килү белән бәйле. Сөембикә фаҗигасе – ул татар милләтенең фаҗигасе. Ватанны югалту кайгысын, гомерлек ачы язмышка дучар ителәчәк халыкның хәсрәтен бөтен тирәнлегендә тойган иҗатчы гына Сөембикә образын сурәтләүгә алына ала.

Шундый милли җанлы язучыларның берсе Рабит Батулла үз әсәрләрендә укучыда милли аң уятуны максат итеп куя. Ул моның өчен иҗатының баштагы чорында күбрәк фольклорга, төрле кинаягә корылган метафорик вакыйгаларга, символларга мөрәҗәгать итеп язса, алга таба Сөембикә, Габдулла Тукай, Кәрим һәм Заһидә Тинчуриннар, Кәбир Бәкер кебек күренекле, затлы шәхесләрнең тормыш юлларын, халык язмышында тоткан урыннарын сурәтләү аша ирешергә омтыла. Бу, бер яктан, язучының «тарихны шәхесләр тудыра» дигән гыйбарәгә ышануыннан, икенче яктан, милли үзаң тәрбияләүдә һәм саклауда конкрет шәхес образының үтемлерәк тәэсир итүен аңлаудан килә.

Совет чорында Казан ханлыгына бәйле вакыйгаларны әдәбиятта яктырту иң четерекле мәсьәләләрнең берсе булып торды. Күп еллар буе яшерелеп килгән темага алынып, халык күңелендә сакланган Сөембикә образын сурәтләү язучыдан тәвәккәллек таләп итә. Батулла «Сөембикә» (1992) романын боларны аңлап, үзендә зур җаваплылык тоеп яза, Һ. Атласи, М. Худяков кебек тарихчыларның хезмәтләрен файдалана, архивларда утыра, М. Госманов, Ә. Кәримуллин, А. Фәтхи, Р. Фәхретдиновлар кебек галимнәр белән киңәшә.

Әсәр Сөембикәнең туганнан алып соңгы көннәренә кадәрге бөтен тормышын иңли. Шулай да аны бер ханбикә турында гына дип булмый. Ул Казан ханлыгының соңгы дәверендәге иҗтимагый-сәяси вазгыятьне көнкүреш вакыйгалары белән үреп биреп, тулы бер картина хасил итә. Батулланың алда язылачак тарихи әсәрләренә нигез итеп алынган төп дүрт принцип «Сөембикә» романында ачык күренә. Алар: тарихилык, борынгы язма әдәбият традицияләренә таяну, фольклорга мөрәҗәгать һәм язучы фантазиясе. Авторның уңышы тарихи фактларга хилафлык китермичә, халык күңелендә яшәгән образны тормышчан тере героиня итеп бирә алуында.

Әсәрнең беренче яртысында романтика өстенлек итә. Туу, үсү, үсмерлек, яшьлек чорларында Сөембикә гади, әмма гадәтилектән өстенрәк итеп сурәтләнә. Башка әсәрләрендә геройның тышкы кыяфәтенә, портретка саран Батулла Сөембикәне гаять чибәр итеп тасвирлый. Ул акыллы, укымышлы, кыю, уңган, мәрхәмәтле дә. Сөембикәнең ахирәтләре белән ир-егетләр киеме киеп сугыш серләренә өйрәнүе, далада гаделлек урнаштырып йөрүе, төшендә күргән Ирәмбагны эзләп Һиндстанга сәфәр чыгуы, анда зирәк һәм шәфкатьле Бабур патша һәм аның улы Хумаюн белән очрашуы, бәхет кошы Хомайның күләгәсе Сөем тутайның йөзенә төшүе – болар барысы да көнчыгыш традицияләре нигезендә язылган мифологик

сюжет элементлары. Алар героиняның гадәттән тышлыгын ассызыклау өчен кирәк. Әлеге мифологик мотивлар әсәрнең жанрын «кыйсса» дип аталуын аклый.

Әсәрнең икенче яртысында героиняның ханбикәлек чоры башлана һәм реалистик сурәтләү алгы планга чыга. Сөембикә булдыксыз Җан Галине ир итеп кенә түгел, хан итеп тота, акылы, зирәклеге белән иренең абруен күтәрә. Ә инде Сафа Гәрәй ханга кияүгә чыккач, Сөембикәнең чын мәгънәсендә бәхете ачыла. Батулла аларның һәр яктан пар килүләренә басым ясый: «Сафа Гәрәй хан олпат ир, күп яуларда катнашкан, күп җиңүләр яулаган бөек баһадир иде. Эш башласа, җене белән эшләр, кылыч алса җене белән орышыр, күңел ачса, чыны белән бәйрәм ясар» [1, б. 247]. Язучы Сафа Гәрәйнең Казан ханлыгы тарихында әһәмиятле урын тотуын тарихи вакыйгалар, кылган эш-гамәлләре, холык-фигыле белән дәлилли. А. Гыйләҗев: «Мондый хан безгә бүген дә бик кирәк иде, Казан ханлыгының бөеклеген тәшкил иткән ил агасы, юлбашчы образы безгә бигрәк тә яшь буынны ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләгәндә җитешми иде. [...] Батулла Сөембикә ханбикә белән янәшә Сафа Гәрәй ханга да һәйкәл куйды» [2]. дип язуы белән хаклы.

Әсәрдә үсмер чорыннан алып соңгы көннәренә кадәр яктыртылган Кошчак олан образы бирелә. Сөембикә белән аның мөнәсәбәтләре турында тарихи язмаларда бернинди дәлил булмаса да, рус әдәбиятында аларга пычрак аткан әсәрләр очрый. (Тулырак мәгълүматны И. Рәмиева хезмәтеннән укырга мөмкин) [3]. Батулла укучы күңелендә бернинди шиккә урын калдырмаслык итеп Кошчакны Сафа Гәрәй ханга, ватанына һәм диненә тугрылыклы, соңгы тамчы канына кадәр көрәшкән саф күңелле, аек акыллы, батыр йөрәкле сугышчы итеп тасвирлый. Казан өстенә яу килгән иң дәһшәтле авыр көннәрдә дә ул Сөембикәнең таянычы була.

Романда кабатланып килгән символик образлар бар. Алар әсәрнең тәэсир көчен арттыруга һәм мәгънә тирәнәйтүгә ярдәм итәләр. Шунысы кызык, алар тормышның капма-каршылыклардан торуын искәртү өчен, күрәсең, антиподлары белән килә: Каракош һәм Хомай кошы, Ирәмбаг һәм Сугыш кыры. Иң тәэсирле һәм уңышлы символик образлар – Каракош һәм утта янмас кыз Гайшә бәгим көе. Каракош, бер яктан, геройларны һәрвакыт сагалап торучы үләксә козгыны – баскынчы кавем булса, икенче яктан, котылгысыз ачы язмышыбыз, кара тәкъдир булып аңлашыла. Гайшә бәгим көе исә – тарихи хәтер. Романның башлам өлешендә, Батулла Болгар дәүләтенең ханнары турында мәгълүматлар биреп үтә. Соңгы хан булып тарихка кереп калган Габдулла хан турындагы бүлектә язучы болгарларның җиңелмәс рухлы горур халык булуы турында яза. Явыз Аксак Тимер бөтен илне хәрабә хәленә китерсә дә, тез чүктерә алмый аларны. Габдулла ханның сөекле кызы Гайшә бәгим янган ташпулат эченнән исән чыга һәм, Тимерханга шарт куеп, өч ир туганын азат иттерә. Батырлык һәм горурлык үрнәгенә әйләнгән бу җырчы кызның көе, гасырлар аша үтеп, Казан ханлыгы кешеләренең күңелендә дә сихри моң булып яшәвен дәвам итә. Барысында да түгел, билгеле. Нәкъ менә үз тамырларын белгән, илен сөйгән, таза рухлы Таргын мирза токымының соңгы оланы Кошчак, шагыйрь Мөхәммәдьяр, аның сеңлесе – Саягөл, Сөембикә кебекләрне тетрәндерә ул көй. Шулай итеп, әсәрнең буеннан-буена лейтмотив булып «яңгырап» торган «Янмас кыз» көе үткәнне яңартып торучы тарихи хәтер образында гәүдәләнеш ала.

Батулла милләт фаҗигасенең сәбәпләре турында уйлана. Бердәмлек булмау, төрле фирка-партияләрнең икейөзлеге, бәкләрнең үз мәнфәгатьләрен генә кайгырткан мәкерле уеннары Казан ханлыгын җимерүгә китергән төп сәбәпләр итеп күрсәтелә. Язучы сәясәтне дә, идарә системасын да, сугыш стратегияләрен дә белеп, аңлап яза. Казан алынуның соңгы көннәре елъязма рәвешендә тәкъдим ителү тарихи вакыйгаларны кинокартина сыман тергезергә ярдәм итә. Халыкның соңгы тамчы канына кадәр көрәшүе, Сөембикәнең илне бирмәскә тырышып бәргәләнүләре, яуга каршы үзе кузгалуы тетрәндерерлек сурәтләрдә бирелә, Казанның бик авырлык белән алынуын күрсәтә. Язучының шәһәр күренешен географик яссылыкта укучы күз алдына бастыру өчен борынгы атамаларны файдалануы бик уңышлы чыккан. Тарихи сүзләрне, архаизмнарны һәрвакыт яратып кулланучы әдип «Сөембикә» романында тагы да иркенрәк эш итә. Ул иске татар телендә кулланышта булып та, инде онытылган сүз-кәлимәләрне урынын туры китереп, мәгънәсе аңлашылырлык итеп

файдалана, үз неологизмнарын җайлы гына урнаштыра. Мәкальләр, гыйбрәтле тәгъбирләрне куллану әсәрдәге тарихи башлангычны калкыта, укучыны үзе сурәтләгән дәвергә алып кереп китә. Юлчатыр (палата), этраман (ялланган гаскәр), тез йөгенү (реверанс), үлчә, ганимәт (трофей), поскын (засада) кебек сүзләр әсәрне бизәп кенә калмый, телебезне үстерә һәм баета да.

Мөхәммәт Мирза язганча, «Сөембикә образын моңарчы яшәгән һәм яшәячәк буыннар алдында гүзәллекнең һәм батырлыкның, тугрылыкның һәм каһарманлыкның символы дәрәҗәсенә күтәреп иҗат итүе автор Р. Батулланың да зур батырлыгы, аның үзенең дә яңа биеклеге һәм мәртәбәсе!» [4].

Җыеп әйткәндә, Батулла борынгы тамырларны барлап, тарихтагы данлы, шанлы сәхифәләрне торгызып, укучыда горурлык, миллият хисен калкуландыра һәм, киресенчә, сызлану-сыкраулары аша үкенечле вакыйгаларны хәтердә яңартып, киләчәккә сабак бирә, Сөембикә образының татар тормышында рухи тоткан урынын, тарихи әһәмиятен ача.

**Әдәбият**


1. Батулла. Сөембикә: Кыйсса. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 415 б.
2. Гыйләҗев А. Әсәр чын бәясен көтә... // Татарстан хәбәрләре. – 1995. – 5 апрель.
3. Рәмиева И.Р. Рус, татар, төрек әдәбиятларында ханбикә Сөембикә образы. – Казан, 2009. – 244 б.
4. Мирза М. Тәнкыйтьчегә тел ачкычы... // Ватаным Татарстан. – 1995. – 24 март.


УДК 82.02/.09

# ИЗОБРАЖЕННЫЙ МИР В РАССКАЗАХ ИЛЬСИЯР ИКСАНОВОЙ ИЛСӨЯР ИКСАНОВА ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ СУРӘТЛӘНГӘН ДӨНЬЯ


***Габдуллина Гульнур Рустемовна***
***Гайнуллина Гульфия Расилевна***
Казанский (Приволжский) федеральный университет,
г. Казань, Татарстан, Российская Федерация
*e-mail:gulfiarasilevna@mail.ru*


**Аннотация.** *В статье рассматривается изображенный мир в рассказах Ильсияр Иксановой, проблематика произведений писательницы. Делается вывод о том, что высокохудожественный мир поэтессы и писательницы современности обогащен символами, насыщен психологизмом. В рассказах ставятся злободневные общественно-философские проблемы.*

**Ключевые слова:** *проза; рассказ; изображенный мир; проблематика.*

# THE PICTURED WORLD IN THE STORIES OF ILSIYAR IKSANOVA


***Gabdullina Gulnur Rustemovna***
***Gainullina Gulfiya Rasilevna***
Kazan (Volga Region) Federal University, Kazan,
Tatarstan, Russian Federation


**Abstract.** *The article deals with the depicted world in the stories of Ilsiyar Iksanova, the problems of the writer's works. It is concluded that the highly artistic world of the poetess and writing of modern times is enriched with symbols, saturated with psychologism. The stories pose topical socio-philosophical problems.*

**Keywords:** *prose; story; depicted world; problematics.*

Хәзерге татар прозасын концептуаль якын килеп өйрәнүче әдәбият галиме Д.Заһидуллина фикеренчә, соңгы елларда “хикәя прозадагы үзгәрешләргә сизгер, яңарыш һәм үсеш кичерүче жанр булып кала. Заман хикәясендә татар әдәбияты өчен традицион алымнарның – психологизм, фәлсәфи гомумиләштерүләргә алып килү, эмоциональлек, символлар теле белән эшләүнең яңа мөмкинлекләре барлана” [1, б. 141].

И. Иксанова соңгы елларда каләмен эпик төрдә чарлап, татар прозасын матур лирик хикәя үрнәкләре белән баетты. Әдибәнең хикәяләре соңгы ике дистә елда төрле матбугат битләрендә даими басыла килде. Илсөяр Иксанованың күп кенә хикәяләрдә иҗтимагый проблемалар шәхескә, фәлсәфәгә, андагы үзгәрешләргә караган кеше проблемасы, фәлсәфи проблемалар белән бер үремтәдә калкытыла. “Болытлар артында кояш бар” (2014) хикәясендә кешеләр арасында ихлас мөнәсәбәтләр турында сүз бара, ярату турында әйтергә кирәклек турындагы фикерне фәлсәфи гомумиләштерүләр аша җиткерә. Язучы проблеманы үзгә яссылыкта күрә. Кешеләр бер-берсенә җылы сүз әйтүдән, ярату хисен ачык белдерүдән ераклаша баралар икән. Әнвәрнең күңел халәтендәге бушлыкның да сәбәбе шуның белән бәйле: “Әнвәр хисе күңеленнән ташып торганда да “яратам” сүзен җиңел гел әйтә алмый. Ул хис ничектер сүзсез генә аңлашылырга тиеш кебек. Әллә нәкъ менә шул гап-гади сүзләрне вакытында, урынында әйтә белмәү аркасында тормышы шундый чуалчык булып чыктымы соң Әнвәрнең?” [2, б. 141]. Авылга җылы эзләп айткан Әнвәрне, чынлап та, апасының җылысы каршы ала. Әнвәрнең күңелендә балачак хатирәләре яңара. Еллар үткәч тә, этисенең хыянәте аның күңелне тырнап тора. Тик Әнвәр аны аңлауга килә: “Әтисен ул бик соң гына, аны югалтып шактый еллар үткәч, тормышның әйтеп аңлатып булмаслык борылмаларында үзе дә шактый абынганнан соң гына аңлады” [2, б. 61].

Әнвәрнең сөйгән кызы Венераны югалтуы, хатыны Мөршидәнең башкага кияүгә китүе бер сәбәпкә – “яратуын җиткерә белмәүгә” тоташа. Автор проблеманы көчәйтеп бирү максатыннан хәдистән алынган сүзләрне китерә: “кемне дә булса яратсаң, аңа яратуыңны әйтергә кирәк, яратуыңны әйтми калу гөнаһ, диелгән иде анда. Әнвәрнең гөнаһлары күп икән шул. әнисе, әтисе. Апасы, Венера, Мөршидә, кызы..” [2, б. 65].Димәк, автор карашы гап-гади проблеманың чишелеше кебек укыла. Ихлас мөнәсәбәтләрнең нигезендә ачыклык, бер-береңә карата җылы, игътибарлы булу ята икән.

“Телефон” хикәясендә дә Дилбәр-Дамир арасында аңлашу җитмәү иң кадерле кешеләрне бәяләмәү аркасында килеп чыга, дигән караш җиткерелә.

И.Иксанова хикәяләре арасында новелла жанрына тартымнары да бар. Шулардан берсе – “Песи” хикәясендә песинең кичерешләре тергезелә. Авыру песинең хикәяләве кебек башланган новелла әнисенең песигә карата битарафлыгын, хәтта вәхшилеген күреп үскән кыз сөйләве һәм газабы кебек дәвам иттерелә. Ярату, наздан мәхрүм бала кешеләр арасында үзенә җандаш тапмый, ялгыз ана булырга җыена. Шул рәвешле, И.Иксанова кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр моделенең бала кечкенә вакытта ук формалашып, киләчәк тормышына йогынтысы турындагы сүзне кузгата һәм бик күп башка хикәяләрендә кабатлый.

Бу урында И.Иксанованың балалар өчен язылган лирик-моңсу хикәяләренә тукталу тиеш. “Күбәләк” хикәясе матур әкият дип тамгалана. Айсылу исемле нәни кыз белән күбәләкнең дуслашуы, бергә уйнаулары лирик рухта бәян ителә. Кыш көне дә күбәләк юкка чыкмый, күбәләк карның нәфислеге шул шакта сөйли, ди хикәяләүче. Әкияттә куелган проблема – баланың учында эрегән кар образы аша бирелә. Күбәләген югалтканга борчылган кызга әнисе болай җавап бирә: “Син югалтмадың. Син таптың. Сиңа бүген уналты яшь тулды. Учыңа кара. Ул – тормыш тамчысы. Анда күбәләк канатларының балкышы да, диңгезләрнең тирәнлеге дә, чишмәләрнең моңы да, бу дөньяның гаме дә бар!” [2, б. 142]. Димәк, күбәләк турындагы могҗиза кызның гомер юлына маяк булып тора.

“Юл” (2000) хикәясендә ана булу теләге белән бәйле әрнү хисен ең тирәнлеге бәян ителә. Берәүләр баласыннан баш тартып, соңрак әрни, икенчеләр исә бала алып кайта алмаганга газап утында яна.

Хикәянең төп герое Ләйлә. Аның теләге гадиләрдән-гади – туган көнендә әнисен сөендерәсе, яраткан йомшак уенчыгын бүләк итәсе килә. Ләйлә тарихы гаҗәеп кызыклы.

Автор ана булу турындагы фикерне җиткерү өчен өч образны янәшәлектә тасвирлый. Ләйлә – Рәхиләнең кызы, тик ул аны яшь чагында балалар тудыру йортында калдырып чыккан, шуңа гомере буе үкенеп яши. Нәсимә исә – Ләйләнең үги әнисе, ләкин Ләйлә үзе моның хакында белми. Чаһра усал, ачы телле авыл хатыны. Бала кайгысы аның да башыннан узганлыктан, усал һәм дорфа. Әлеге өч хатын дә Ләйләгә мөнәсәбәтле, өчесен дә бала кайгысы бәйләп тора. Кешеләрең тупаслыгы, дорфа-ямьсез мөнәсәбәттә булу җылы, наз җитмәүгә, яратудан баш тартуга барып тоташа, ди автор. Әнисе яратып үстергән кызның күңеле чиста: "Көз кояшы тәрәзә аша шундыен да кыздыра, әйтерсең җәйге чиллә. Җылы, якты, рәхәт! Җәйдән дә яктырак көз бу. Сап-сары кырлар, сап-сары урманнар.. чынлап та, алтын көз! Алтын көз – ялкын көз! Әнисенең туган көне" [2, б. 107]. Пейзаж ярдәмендә автор Ләйләнең күңел халәтен күрсәтә. Аңа рәхәт, күңелле, тәрәзә артында кояш елмая. Ләкин шул ук көз Ләйләнең янында утыручы Рәхиләнең күңелендә бөтенләй башка тойгылар уята: "Моңсу. Үзәк өзгеч моңсу. Күзләрне камаштырган сап-сары көз – сары сагыш... мәңге үтмәс сагыш!" [2, б. 107]. Нәкъ менә шундый көзнең бер көнендә ул нарасыен бала табу йортында калдырып чыга, шуңа да көз Рәхиләдә сары сагыш, үкенү хисләре белән бәйле. Димәк, автор карашынча, тормыш-яшәешнең ничек дәвам итүе ихлас хисләргә тугры булып калу белән бәйле икән. Шуңа күрә Ләйләнең көзе белән Рәхиләнең көзе янәшә куела.

Кеше тормышы, аның хисләре белән бәйле юл символы үткәннәр белән хәзергене тоташтыручы күпер мәгънәсен ала. Әлеге символ әсәрне каймалый, әсәр ахырында автор позициясен белдергән уйланулар белән тәмамлана: "Тик аның кайда тукталасын беләү дә белми. Һәм Юл үзе дә моңардан бихәбәр. Тагын күпмегә сузылыр, нинди киртәләрне үтәр язмышның бу сикәлтәле юлы..." [2, б. 110]. "Ләйлә дә, Рәхилә дә, Гөлчаһра да бер үк кеше турында уйланып барсалар да, аларның уйлары кисешми, һәркайсы үз юлында ага иде" [2, б. 110].

"Сүнгән елмаю" хикәсендә дә күтәрелгән проблемалар замана өчен гаҗәеп актуаль. Автор Гөлгенә исемле ханымның баласын корсакта ук үтергәненә үкенүен, сызлануын тергезә. Гөлгенә образы аша "җан кыю – гөнаһ бит!" дигән автор карашы җиткерелә.

Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең ярату, наз җитмәүгә бәйле катлаулануы – И.Иксанова хикәяләрендә еш кабатлана торган эчтәлек, дидек. Бу урында шул ук тема һәм проблеманы үзгәрәк форматта яктырткан тагын бер хикәягә тукталыйк. "Әбиләр сабагы" дип аталган хикәя балалар өчен язылган хикәя кебек укыла. Автор аны үзе эссе жанрына кертеп карый. Безнең карашка, әсәр очерк жанрына якынрак торган эссе кануннарына буйсынып бетми. Хикәядә күтәрелгән проблема балалар аудиторисе өчен актуаль – өлкәннәргә ихтирам мәсъәләсе. Хикәя сюжеты бала исеменнән сөйләнә: "Әби белән үскән баладан да бәхетле кеше бармы икән бу дөньяда?! Мин бу яктан икеләтә-өчләтә бәхетле идем. Мине дәү әнием (әтинең әнисе) белән дәү апам (әтинең апасы) иреләп-назлап үстерделәр" [2, б. 187].

Кечкенә Илсөяр бик иркә, үтә дә хыялый, ихлас күңелле бала: яңа пәлтәен күрсәтергә буранлы көндә урамга чыгып та йөри, тик күршесе Газзә апасыннан кала башка берәүне дә очратмый, Газзә апасы аңа пәлтәсен котлап, икенче көнне ике күкәй кертә; балет дип тә саташып йөри, аяк очында биеп, әнисе чүәкләренең башлары тишелгәнче күрше карчыкларга биеп күрсәтә, алар алдында төрле тамашалар куя: "Йөрсен. Балет биеп, бөтен урам әбиләренең күңелен күрә бит ул" [2, б. 187], – дип яклый дәү әнисе.

Балет мәктәбендә чын-чынлап укырга хыяллануы һәм "ун яшь узгач алмыйлар ди бит анда", "Казанда балет мәктәбе юк", "Ленинградта" дип борчылулары, кызчыкның борын салындырмавы, аның яңа хыялы барлыкка килүе хикәянең лириклыгын баета, камилләштерә.

Пейзаж алымы әсәрне кабул итүгә көйли һәм хикәяләүченең психологик халәтен ача: "И-и-и, ул дәү әни белән урманга йөрүләр, язгы үлән хәтфәләнгәч, яшь үләндә аунарга аланга чыгулар, дәү апам белән умарталыкка барулар (ахирәте умартачы иде аның)..." [2, б. 189].

Әсәрдә дә бер хыял икенчесен алыштыра. Беренче апрель көнн әбиләрнең берсен алдавына сабыйның борчылуын күрсәтергә теләп, автор ачыклаучы психологизм алымына мөрәҗәгать итә: "Мин үкереп елыйм. Беренчедән, дәү әни ачулана. Икенчедән, Мәгърифә ападан куркам. Өченчедән...оят! – Беренче апрель бит. Алдау көне. Көлке көне... – дип дәү

әнигә карышып, үз-үземне юатмакчы булам. Шулай да хәзер инде бер дә көләсе килми. Елыйсы гына килә”. Автор, балалар әдәбиятына хас булган тәмам кертә, үгет-нәсихәт бирә: “ Ә бу хәл миңа гомерлек сабак булды. Әбиләр белән үткән балачагымнан бер дәрес” [2, б. 190] дип яза.

“Соңгы хатирә” хикәясендә И.Иксанова Әсмабикә әбинең үлем алдыннан үз әнисен искә төшерүен бәян итә. Үлем түшәгендә яткан туксан сигез яшьлек әби дүрт яшьлек кыздан ананы алып китү вакыйгасын гаҗәеп тирән әрнү һәм газап белән сөйләп бирә. Автор ана белән бала арасындагы бәйләнешләрнең беркайчан да өзелмәвен, соңгы сулышкача саклануын трагик пафос белән җиткерә. И.Иксанова хикәяләренә аң агышы алымын кертеп җибәрә – вакыйгалар Әсмабикәнең үлем алды саташулары кебек тәкъдим ителә.

Шул рәвешле, И.Иксанова хикәяләрендә лириклык, символлаштыру, психологизм алымнарын үз итә, калкытылган проблемалар иҗтимагый-фәлсәфи, кеше проблемалары буларак төгәлләшә. Хикәяләрендә күтәрелгән проблемалар аша автор фәлсәфи гомумиләштерүләргә алып килә.

**Әдәбият**


1. Заһидулинна Д.Ф. Замана әдәбиятында үзгәрешләр // Казан утлары, 2015.- №1. –Б.141.
2. Иксанова И.В. Болытлар артында кояш бар / Балан чәчәге: повесть, хикәяләр, телевизион фильм өчен сценарий, эссе. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2016. – Б.37.


УДК 821.512.145

## МӘЧКӘРӘ АВЫЛЫ ҺӘМ МӘДРӘСӘСЕ ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ БӘЯЛӘВЕНДӘ


***Галимуллин Фоат Галимуллинович***

Институт филологии и межкультурной коммуникации Казанского (Приволжского) федерального университета, г. Казань, Татарстан, Российская Федерация

*e-mail:alfiya_gali@rambler.ru*



**Аннотация**. *Шигабутдин Марджани – выдающийся татарский ученый XIX века, выдающийся религиозный деятель, историк, философ, просветитель и, конечно, один из великих сыновей нашего народа. В статье рассматривается тема о деревне Мачкара и о медресе. Медресе Мачкары в свое время было одним из важнейших центров духовной жизни нашего народа, религиозного образования и воспитания, развития исламского богословия, обеспечения верующего, благородного, человечного народа.*



**Ключевые слова:** *народ; медресе; деревня Мачкара; ученый.*


## MACHKAR`S VILLAGE AND MADRASAH OF SHIGABUTDIN MARJANI


***Galimullin Foat Galimullinovich***

Institute of Philology and Intercultural Communication of Kazan (Volga Region) Federal University, Kazan, Tatarstan, Russian Federation



**Abstract.** *Shigabutdin Marjani is an outstanding Tatar scientist of the XIX century, an outstanding religious figure, historian, philosopher, educator and, of course, one of the great sons of our people. The article deals with the topic of the village of Maskara and the madrasah. At one time, the Machkary Madrasah was one of the most important centers of the spiritual life of our people, religious education and upbringing, the development of Islamic theology, and the provision of a faithful, noble, humane people.*



**Keywords**: *people; madrasah; Machkara village; scientist.*

Шиһабетдин Мәрҗани – XIX йөзнең күренекле татар галиме, мәшһүр дин әһеле, тарихчы, фәлсәфәче, мәгърифәтче һәм, әлбәттә, халкыбызның бөек улларыннан берсе. Үзе язганча, аның тулы исеме – Мелла Шиһабетдин бине Баһаветдин бине Сөбхан бине Габделкәрим әл- Мәрҗани. Ул тулысы белән XIX гасыр кешесе. 1818 елда туып, 1889 елда вафат булган. Дөньяда 71 ел яшәп, халык күңелендә тирән эз калдырган, заманы өчен генә түгел, үзеннән соң яд итәрлек игелекле гамәлләр кылган, зур эшләр башкарган. Егерме беренче гасырда да кирәкле һәм файдалы китаплары һәм хезмәтләре бу шәхеснең рухи һәм фәнни даирәдә еш телгә алынуын тәэмин итә. Ул “Мөстафадел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар” дигән китабында хезмәтләренең исемлеген үз кулы белән язып та калдырган. Алар 26. Ләкин китаплары бу сан белән генә чикләнми, чөнки үзе дә исемлекнең ахырында күп нокталар куйган. Күбесе кульязма хәлендә булып, басылганнарын да искәртеп бара. Моннан күренгәнчә, бер әсәре Истамбулда, сигезе Казанда басылды, ди. Бу исемлектә “Мөстафадел әхбар...” күренми. “Мөстафадел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар”ның беренче томы 1885 һәм 1897 елларда ике тапкыр, икенче томы 1900 елда басылып чыккан. 1989 елда, ягъни вафатына йөз ел тулгач, шактый җыйнакландырылган варианты бер китап хәлендә басып чыгарылды. Без бу зур эшне башкарган замандашларыбыз Әнвәр Хәйруллин, Сәлам Алишев, Яхъя Абдуллиннарга рәхмәтле булып яшибез.

Башта ук шуны әйтеп кую зарур. Ш.Мәрҗани язган икән, ул бәян иткәннәр дөрес, хакыйкать. Чөнки Ш. Мәрҗани, тарихчы буларак, һәр мәгълүматка шикләнеп караган, бары тик дөреслегенә тәмам ышангач кына аны язуга төшергән. Бохара, Сәмәркандта яшәгән вакытларында Көнчыгышның гарәп, фарсы, төрек чыганакларын ныклап өйрәнсә, Казан чорында ул инде русларда һәм Көнбатышта булган хезмәтләргә дә игътибарлы булган. Үзенә кадәрге затлар калдырган тарихи мираска бик тә тәнкыйди караган, күп нәрсәне аңа үзенә башлап нигезләргә туры килгән.

Китаплы һәм язулы халкыбыз элек-электән үзенең үткәне белән кызыксынып яшәгән. Тарихны килер буыннарга калдырырга тырышкан. Бер дә булмаса, үз даирәсендәге аеруча мөһим хәл-әхвәлләрне һәм кешеләр турындагы мәгълүматларны китап бите читләренә теркәп барган. Ш. Мәрҗани хәтта андый язуларга да игътибарлы булган. Ул бик күп төбәкләрдә булган, укымышлылар белән очрашкан, алардагы исәлекләрне, язмаларны туплаган, бик күпләр белән әңгәмәләшеп утыра торган булган. Гомер буе өйрәнгәннәрен 7 томлык “Вафийятел-әслаф вә тәхийятел-әхлаф” (“Элгәрләрнең некрологлары һәм аларның киләчәк буыннарга бүләге”) һәм ике томлык “Мөстафадел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар” (“Казан вә Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр”) дигән хезмәтләрендә бәян иткән.

Без аның менә шушы “Мөстафадел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар” дигән хезмәтеннән аның кала-авылар, мәчет-мәдрәсәләр, күренекле дин әһелләре булган имамнар, хатыйблар, мөдәррисләр, ахуннар, ишаннар һәм башка элгәрләр һәм замандашлар турында, шулай ук ил тарихына багышланган бик күп мәгълүматларны беләбез.

Шул заманның күп кенә күренекле шәһәрләре, авыллары арасында ул Мәчкәрә карьясына да игътибар итә, хәтта аны аны “мәшһүр Мәчкәрә” дип атый. Болай дигәндә, әлбәттә, Ш. Мәрҗани, әлеге авылның рухи, мәгърифәтебез тормышыбыздагы урынын да лаеклы бәяли.

Ихтимал, мәчкәрәлеләр Ш. Мәрҗанинең бу хезмәтеннән үз авыллары турындагы мәгълүматларны горурланып укыганнардыр һәм укыйлардыр дип ышанырга кирәк. Шуңа күрә Ш. Мәрҗани китергән мисаллар кайберәүләр өчен мәгълүмдер дә. Әмма күңелгә ятышлы нәрсәләрне тагын бер тапкыр искә төшерү бер дә артык булмас.

Соңгы унъеллыкларда Мәчкәрә мәктәбендә табылган шәҗәрә буенча, без егерменче гасырның бөек әдибе Чыңгыз Айтматовның әнисе ягыннан нәсел-нәсәбенең нинди тамырлардан килүен белдек. Ул Туктаргали исеме белән башлана, аның Бөре башы авылында җирләнгәне әйтелә. Кем ул Туктаргали? Шушы Мәчкәрә авылыннан булган Хәмзә, аның кызы Нәгыймә белән бу Туктаргали дигән кешенең нинди бәйләнеше бар? Боларны әлеге шәҗәрәдән төгәл генә белеп булмый. Әмма болар хакында 19 нчы гасырның икенче

яртысында ук (китапның беренче басмасы 1885 елда) Ш. Мәрҗани тәфтишләп язып калдырган икән. Без аның ярдәмендә бу нәселнең тарихын һәм тармакларын күрәбез.

Туктаргали сәүдәгәр булган, Оренбург һәм Каргалы якларында сату-алу белән шөгыльләнгән. 1669 елда вафат булган. Димәк, 17 гасырның икенче яртысында. Бөре башы зиратында җирләнгән. Аның өч улы булган: Мәмәт, Ишман һәм Ишкәй. Мәмәт дигәне Бөре башында калган. Ш. Мәрҗани әйтүенә караганда, "авыл халкының күбрәге шул Мәмәт нәселеннән килә" (Бәлки, безнең мәшһүр казыебыз Җәлил хәзрәтнең дә Мәмәт нәселенә мөнәсәбәте бардыр?). Ишмән белән Ишкәй Бөре елгасының тамагына таба - хәзерге Мәчкәрә җирлегенә күчкән. Күрәсең, Мәчкәрә карьясын нигезләүдә Ишманың өлеше зуррак булган, бу авылны башта "Ишман иле" дип йөртүләре юкка гына булмагандыр. Ул әле Бөре башында яшәгәндә үк мәчет салдырган булган. Әмма андагы бер Эшмәкә исемле кеше белән дошманлашып, аңа үч итеп, шушы мәчетне сүтеп, Мәчкәрәгә китереп сала. Тора-бара Туймәҗ бине Туйкә дигән кеше бу мәчетне кире Бөре башына күчерүгә ирешә. Күрәбез, тарихыбызда мәчетләрнең дә бер урыннан икенчесенә күчереп йөртелүләре кебек гыйбрәтләр дә булган.

Без Ш. Мәрҗани хезмәтеннән бу нәселнең шактый зур шәҗәрәсен күрәбез. Аның башында тимерчелек белән шөгыльләнгән Тәбәҗ исемле ир заты. Аннан Көчек-Туктаргали-һәм өч туган: Мәмәт, Ишман, Ишкәй. Безне бу очракта Ишман дигәне кызыксындыра. Без инде аның Мәчкәрәгә мөнәсәбәтле гамәлләренең кайберләрен искә дә алдык. Аның Гаед, Габдессәлам, Габделмәннән, Сәгыйдь, Бәшир, Нәзир, Үтәмеш исемле җиде улы булган икән. Менә бу Үтәмеш исеме безгә бүген дә ят түгел. Ул сызык безне кызыксындырган Хәмзәгә килеп тоташа.

Сүз дә юк, Мәчкәрә авылында бу нәселнең кәгазьгә төшерелгән шәҗәрәсе табылу зур әһәмияткә ия вакыйга булды. Бәлки, моны кемнәрдер очраклылык дип тә карарга мөмкиннәр. Ләкин, әйтергә яраса, мондый очраклылык бары тик нәсел тамырлары затлы һәм күренекле булган кардәш-ыруларда гына була ала. Чөнки моның өчен беренче шарт – нәсел-нәсәпнең мәгърифәтле, китаплы, үзенең элгәрләре һәм замандаш якыннары белән горурланып, аларны зурлап яшәүчеләрдә генә була ала. Димәк, әлеге нәсел элек-электән үзләре турындагы мәгълүматларның онытылуын теләмәгән, тагы да мөһимрәге аларның халык хәтерендә сакланырга тиешле эш-гамәлләре булган. Шулар турында язып калдыру өчен, аларның укымышлы булулары да кирәк бит әле. Безнең борынгыларыбыз әнә шундый мәгълүматларны хәтта китап битләренең читләренә теркәп тә барганар. Аеруча хәстәрлеләре, әзерлеге булганнары хатларда, төрле язмаларда болар хакында җетеклерәк бәян итеп калдырганнар. Әлбәттә, буыннардан буыннарга күчеп, халык хәтерендә сакланган риваятьләрнең дә әһәмияте әйтеп бетергесез зур. Ни өчен дигәндә, андый халык авыз иҗаты әсәрләре шулай ук тик торганнан гына барлыкка килми.

Ярый, бу шәҗәрә табылды да, ди. Андагы мәгълүатлар дөреслеккә туры киләме, хаклыкны чагылдырамы? Андый вакытта күңелгә бу рәвешле сораулар да килми калмый. Менә мондый сорауларны ачыклау өчен тагын да ышанычлы чыганаклар булуы таләп итә. Шөкер, сүз бара торган шәҗәрәнең дөреслеген ачыклауда бу очракта шундый чыганакларның берсе һәм, әйтергә кирәк, ышанычлысы – Ш. Мәрҗанинең без сүз алып бара торган хезмәте. Аның әһәмияте әйтеп бетергесез зур. Ул безгә бу әлеге шәҗәрәдәге мәгълүатларны егерменче-егерме беренче гасырларда билгеле булганнары белән тулыландыру мөмкинлеген бирә.

Билгеле булганча, Үтәмишевләр тармагы үзе генә дә күп сызыклы, затлы һәм күренекле. Шуларның берсе Хәмзә, аның кызы Нәгыймә аркылы мәшһүр Чыңгыз Айматовка килеп чыгуы үзе генә дә моның дәлиле.

Бу хакта, сак кына, фараз рәвешендә генә әйтеп йөрелсә дә, белүчеләр бар иде. Ләкин шулай да Чыңгыз Торекул улының туганлык җепләре Мәчкәрәгә килеп чыгуын тәгаен генә раслап әйтүче булмады кебек. Ул үзе дә, Татарстаныбызга 1971 елдан башлап килгәләп йөрсә дә, бу турыда сүз чыгарырга җөрьәт итмәде. Сорау туа: ул бу хакта белдеме икән? Мин ышанып әйтә алам: белгән, әлбәттә. 1938 елда Нәгыймә апа, өч баласы белән ялгыз калып, нигездә кыргызлар мохитендә яшәсә дә, үзенең татар кызы икәнлеген бервакытта да исеннән чыгармый. Чөнки аның әти-әниләре балаларын татарның яшәү рәвеше чолганышында

тәрбияләгәннәр. Нәгыймә апаның табигый яшәеше - татарга хас булганча. Чыңгыз этисеннән ун яшьтә кала, олы бала. Урамда, мәктәптә аралашу кыргыз телендә булса да, өйдә әнисе, энесе һәм сеңлесе белән сөйләшкәндә, әлбәттә, татар теле өстенлек итә. 2002-2005 еллар арасында минем үземә Истанбулда, Бишкәктә, Казанда Чыңгыз Торекул улы белән аралашулар насыйп булды. Икәү генә калган чакларда ул татарча сөйләшә иде. Моңа шагыйрь Рәзил Вәлиев тә шаһит. Чөнки сәфәрләребезнең берничәсе аның белән булды.

2004 елда Бишкәк шәһәренең Ч. Айтматов исемендәге кыргыз-төрек гимназиясенең актлар залында минем тарафтан Г. Тукайның “Туган тел” һәм башка шигырьләре укылгач, Чыгыз абыйның татар телендә әйткән сүзләрен мин, шигъри телгә күчереп, болай дип язган ием:

– Бу бинада тәүге тапкыр
Татар теле үз булды.
Безгә бүген иң заруры
Тукай әйткән сүз булды, -

дип Айтматов әсәрләнде,
“Туган тел”не ишетеп,
– Татар телен күтәрегез,
Күп телләргә иш итеп!

Тукай сүзе, анам телен
Назлап искә төшерде.
Үзем өчен Тукайның да
Газизлеген төшендем.

Үзләренең нәсел-нәсәбе Татарстанга тоташуын белсә дә, Нәгыймә апа, ни әйтсәң дә, Ала-Тоу, Эссе Күл җирлеге кешесе.Туган җир төшенчәсе аның өчен шул исемнәр, шул урыннар белән бәйле. Ләкин шулай да ул этисенең туган ягын күрү теләге белән дә яши. Әмма балалар яшь чагында аларны аякка бастырырга кирәк дип тырышса, балалар кеше булгач, сәламәтлеге какшап китә. Бу хакта Рәзил Вәлиев белән миңа Ч. Айтматов үзе әйтте. Димәк, Нәгыймә апа балаларына үзенең чыгышы әнә кайларга – Идел-Нократ якларына барып тоташканын әйтә торган булган. Ч. Айтматовның үз гомерендә иң соңгы сәфәре Кукмара-Мәчкәрә тарафына булуы да күп мәгънәгә ия. Ләкин, Газинур Морат әйткәнчә, кеше туган ягына һәрвакыт кичегә.

Әйе, Мәчкәрә авылының исеме бүгенге көндә өр-яадан киң яңгыраш алган икән, бу, барыннан да элек, Чыңгыз Айтматов белән дә бәйле булды.

Ш. Мәрҗани, башка заман кешесе, шуңа күрә “Мәчкәрә – мәшһүр авыл” дигәндә, авылга дан-шөһрәт китергән башка якларны күздә тота. Аның өчен биредәге мәдрәсәнең абруе, киң танылган булуы мөһим. Ул заманда нинди генә мәдрәсәләр юк. Казанда гына 14 мәчет булган, аларның кайберләре янында мәдрәсәләр дә эшләгән. Тагын Кышкар, Курса, Олы Саба, Оренбург, Каргалы... һәм башка урыннарда. Шулар рәтендә Мәчкәрә мәдрәсәсе. Әлбәттә, аның абруен биредә мөгаллимлек итүче остазлар һәм алардан белем алган бик күпләрнең күренекле дин әһелләре, галимнәр булып китүләре тәэмин итә.

Биредә мәчет авылны нигезләгән Ишман тарафыннан ук булдырылган дип әйткән идек инде. Аннан соң да авыл мәчетсез тормагандыр. Соңгыраклары турында Ш. Мәрҗани төгәл итеп әйтә. Китаптан күренгәнчә, таш мәчет 1971-1793 елларда төзелсә, 1800 ел тирәсендә агач мәчет салына. Агач мәчет 71 ел эшләгәннән соң яна, 1872 елда Исхак исемле игелекле кеше аның урынына мәчетне таштан салдыра. Димәк, 19 гасырның соңгы чирегенән авылда ике таш мәчет була. Ике мәчете дә гөрләп эшләп торган авылда мәдрәсә булдырылуы да гаҗәпмени?

Мәдрәсәдә укыту яхшы куелу сәбәпле, башка урыннардан да балаларын бирегә китерүчеләр елдан-ел күбәя бара. Шактый еракларда да килеп белем алалар. Монда, инде әйтелгәнчә, остазларның нинди булуының әһәмияте иң беренче урында тора. Мәчкәрә мәдрәсәсендәге андый галимнәрнең даны еракларга таралган. Шулай да аларның икесе турында аерып әйтәсе килә. Алар: Мөхәммәдрәхим бине Йосыфҗан һәм Габдулла бине Яхъя.

Мөхәммәдрәхим остаз Мәчкәрәгә 1780 елда кайта. Аңа кадәр биредә, 1758 елдан башлап, 22 ел буена күренекле урынны Мелла Габделхәмид бине Үтәгән әл-Түнтәри тота [2, б. 269]. Ул Адай авылына имам итеп күчерелә. 1805 елда, Түнтәргә кайтып, вафат була.

Мөхәммәдрәхим бер үк вакытта ахун да була. Аның янында бик әйбәт әзерлекле Габдрахман әл-Каргалый дигән остаз да эшли. Аларның атаклы шәкертләренең берсе Нигъмәтлла бине әл-Эстәрлебаши. Чыгышы белән Малмыж өязе Салавыч авылыннан. Бу Нигъмәтулла тагын шуның белән дә билгеле – ул Габденнасыйр әл-Курсавиның фикердәше һәм дусты була

Габденнасыйр бине Ибраһим әл-Курсави Мәчкәрәдә шушы Мөхәммәдрәхимнән башлангыч белем ала. Бохарада да укый. Курсага кайтып, имам, хатыйп һәм мөдәррис була. Мәдрәсә ачып, дәрес бирә. 1908 елда тагын Бохарага бара, андагы галимнәр белән иман һәм фикъһы мәсьәләләре буенча каршылыкка керә, аларны борынгы изгеләр мәзһәбеннән тайпылуда гаепли. Моны белеп, Бохара әмире Хәйдәр галимнәр киңәшмәсен җыя. Аларга бер сорау бирә:

– Бу мосаффир дөрес әйтәме, әллә юкмы?

Күпчелек Габденнасыйрны якламый. Я алар бу нәрсәләрне белмиләр, я әмир алдында яхшы атлы булып калырга телиләр. Каяндыр килеп, аларны өйрәтергә теләүчегә тискәре мөнәсәбәттә булучылары да байтак була. Нәтиҗәдә ул әйткәннәр кире кагыла.

Габденнасыйр авыр хәлдә кала, хәтта аңа үтерү белән яныйлар, аны “ялгыш инануларыннан” баш тартырга мәҗбүр итәләр, тәүбә иттерәләр. Алай гына да түгел, аны алар карашын чагылдырган инану тексты язарга мәҗбүр итәләр, имеш, хаталануыннан язмача ваз кичтерәләр. Аның тарафыннан язылган китаплар яндырыла, кем дә кем аларның берсен генә саклап калса да, ул да үтереләчәк, дип кисәтәләр.

Габденнасыйр Бохарадан китәргә мәҗбүр була. Хива, Хаҗитарханнан аша үтә-үтә Курсага кайта. 1812 елда, 41 яшендә хаҗга барышлый, Костантиниядә ваба авыруыннан үлә. Кабере Өскедар шәһәрендә икән.

Үлгәннән соң, Габденнасыйрны хуплап сөйләүчеләр дә булган. Мәсәлән, үз вакытында Казанда мәгълүм мәхдүм Әбеннәгыйм дигән укымышлы болай дип әйтә торган булган:

– Әбеннасыйр Бохара галимнәренең һәммәсен бер тишеккә тыгып кайтты.

Ш. Мәрҗани туганы Садретдиннең дә аңа карата уңай фикердә булганлыгын әйтә. Аныңча, Габденнасыйрның өстенлекле яклары: сәламәт табигатьле; дөрес фикерле; алдан күрүчән; сеңдереп сөйли белүче; батыр йөрәкле; замандашлары арасында тиңдәшсез. Шул ук вакытта ул аның бик үк зур галим булмавын, карашлары чикле икәнлеген дә әйтә торган була.

Ш. Мәрҗани үз атасы Баһаветдин дә Габденнасыйрны Бохара әмиренең үтермәвенә гаҗәпләнә иде, - дип яза. [1, б. 253]

Габденнасыйр китапларын татар телендә дә язган. Ул вакытта бу да аның башкалардан аерылып труын күрсәтә иде. Чөнки аның замандашлары күбрәк гарәп, фарсы, төрек телләрендә язганнар. Ерак барасы түгел, Ш. Мәрҗанинең дә хезмәтләре нигездә шул телләрдә.

Курсавиның берара, Мәчкәрәгә килеп, дәресләр дә биргән булуы мөмкин. Ник дигәндә, Минзәлә янындагы Симак авылы имамы Мелла Шаһиәхмәд бине Рәфикъның биредә укуы һәм Мхәммәдрәхим ахун, Мелла Габденнасыйр әл-Курсавидан дәресләр алганлыгы теркәлеп калган икән [1, б. 288]. Бу кеше 1835 елда Симакта вафат булган. Димәк, Мәчкәрәдә 1812 елга кадәр укыган була, чөнки Г. Курсави, әйтелгәнчә, шул елда вафат булган.

Ш. Мәрҗани үзенең бабасы Мелла Собхан бине Габделкәрим әл-Мәрҗанинең да Мелла Мөхәммәдрәхим бине Йосыфтан белем алганлыгын әйтә [1, б. 238]

Күренекле мөгаллимнәрнең икенчесе – Мелла Габдулла бине Яхъя. Ул үзе Чистай ягындагы Чиртуш авылыннан. Башта биредә, ягъни Мәчкәрәдә Мөхәммәдрәхим ахун мәдрәсәсендә укый. Бохарага барып, зур галимнәрдән белем ала. 1812 елда Мәчкәрәгә кайта. Остазы Мөхәммәдрәхимнең кызы Рабигага өйләнә. Кайнатсы белән биредә имам, хатыйп һәм мөдәррислек итә. Үз заманындагы мөдәррисләрнең иң шөһрәтлеләренән була. Вафаты 1858 елда. Димәк, Мәчкәрә мәдрәсәсендә 46 ел буе хезмәт куя. Ул кимендә мең шәкертем булды,

дип әйтә торган була. Шуларның берсе – Гатаулла бине Габденнасыйр – Мәмәшир авылы мулласы. Ш. Мәрҗани Габдулла бине Яхъяга карата тәнкыйть сүзләре дә әйтә [1, б. 264, 319].

Шунысы да бар, эшләмәгән кешенең генә гаебе булмый. Габдулла бине Яхъя әзерләгән күп санлы күренекле шәхесләр булуы – аның эшчәнлегенә бирелгән олы бәя булып кабул ителә. Әйтик, чыгышы белән Байлар Сабасыннан булган Мөхәммәд Әмин бине шәйх әс-Сабавый Мөхәммәдрәхим ахуннан һәм Габдула бине Яхъядан берьюлы укыган. Бохарада да булган, шунда Габденнасыйр Курсави белән дуслашкан, аңардан хакыйкатьне эзләү юлларын өйрәнгән, карашларын хуплаган. Хаҗ сәфәре вакытында 1833 елда Каһирәдә вафат булган [1, б. 284-285]. 1829-1874 еллар арасында, ягъни 45 ел Түнтәрдә имам, хатыйп һәм мөдәррис Мелла Гали бине Сәйфулла эт-Түнтәри дә аларның уртак шәкерте.

Мелла Исмәгыйль бине Муса әл-Мәчкәрәви, тәхәллүсеннән үк күренгәнчә, шушы авылныкы, ягъни Мәчкәрәнеке. Габдулла бине Яхъя шәкерте. Аның элгәр нәселдәшләре Мелла Фаяз, Мелла Якуб та гыйлем затлар булалар. Исмәгыйль бине Мусаның гыйльми әзерлеге аеруча көчле була. Шулай да ул үзенең остазы Габдулла бине Яхъя белән көндәш булырга теләми, эшкә Кышкарга китә. Ул анда имам, хатыйп һәм мөдәррис була. 1887 елда бакыйлыкка күчә, Кышкарда җирләнә.

Мелла Гыясетдин бине Хәбибулла бине Рахманколый Казанда Шиһабетдин Мәрҗанинең үзендә укый. Мәрҗани аны бик тырыш иде, олы гыйлем иясе булды, ди. Ул да, Мәчкәрәгә килеп, Габдулла бине Яхъя янында өч ай, хәзергечә әйтсәк, фәнни-гамәли практика узып, аны тыңлап кайта. Бу зат Казанның дүртенче мәчетендә хатыйп һәм мөдәррис була [1, б. 332]. Мондый мисалларны тагын да күпләп китерерә мөмкин булыр иде.

Шул рәвешле, Шиһабетдин Мәрҗани һәм, аннан үрнәк алып атаклы “Асәр” дигән хезмәт язган Ризаэтдин Фәхертдиннәр бездә шәҗәрә җанрын барлауда, шуларны кыйммәтле фәнни чыганаклар итеп әверелдерүдә гаять зур хезмәтләр кадырганнар. Аларның мирасының кирәклеге һәм кадере безнең бүгенге көннәрдә тагын да артты. Чөнки хәзер авылларның тарихын барлауга, бер уңайдан хәзерге кешеләрнең үзләренең ерак буыннарын өйрәнүгә игътибар нык артты. Шушы Кукмара районында гына да инде берничә авыл тарихы китап хәлендә дөнья күрде. Алар арасында без Уразай, Балыклы, Ятмас Дусай, Янсыбы һәм башка авылларга багышланганнарын күрәбез.

Йомгак ясап шуны әйтергә кирәк, бабасының күпмедер биредә укып алганлыгын исәпкә алмаганда, Ш. Мәрҗанинең Мәчкәрә авылы һәм мәдрәсәсе белән турыдан-туры бәләнеше юк кебек. Әмма ул үзенең хезмәтендә әлеге авыл, уку йорты, аның мөгаллимнәре, шәкертләре турында бик күп мәгълүматлар бирә, күңел җылылыгы белән искә ала. Шулардан чыгып, без әйтәбез: Мәчкәрә мәдрәсәсе үз заманында халкыбызның рухи тормышында, дини белем һәм тәрбия бирүдә, ислам тәгълиматын үстерүдә, халкыбызның иманлы, затлы, кешелекле булуын тәэмин итүдә гаять әһәмиятле хезмәт башкарчы үзәкләрнең берсе булган.

**Әдәбият**


1. Әмирханов Ф. Безнең хыялларда Мәрҗани күләгәсе // Ф.Әмирханов. Сайланма әсәрләр. – 2 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. – 462 б.
2. Мәрҗәни Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар.-Казан:”Татарстан китап нәшр.” -1989. - 305 б.
3. Шиһабетдин Мәрҗани / Төз. Р.Мәрданов, Р.Миңнуллин, С.Рәхимов. – Әлмәт: Рухият, 1998. – 175 б.

УДК 821.512.145

# СТИЛИЗАЦИЯ ПОД ВОСТОЧНЫЕ ЖАНРЫ В СОВРЕМЕННОЙ ТАТАРСКОЙ ПОЭЗИИ (НА ПРИМЕРЕ ЖАНРА ГАЗЕЛЬ)
# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ПОЭЗИЯСЕНДӘ КӨНЧЫГЫШ ЖАНРЛАРЫНА ОХШАТЫП СТИЛЬЛӘШТЕРҮ (ГАЗӘЛ ЖАНРЫ МИСАЛЫНДА)

***Гарифуллина Эльвина Фларисовна***
Казанский (Приволжский) федеральный университет,
г. Казань, Татарстан, Российская Федерация
*e-mail: ilvina1996@rambler.ru*

**Аннотация.** *В статье раскрывается возрождение восточных традиций в современной татарской поэзии, жанр которого напоминает стилизацию под восточную лирику. В ходе исследования акцентируется внимание на выявление жанрово-стилевого своеобразия и трансформацию жанра газель и его жанровых форм.*

**Ключевые слова:** *современная татарская поэзия; стилизация; восточные жанры; газель; жанр.*

# STYLIZATION OF EASTERN GENRES IN MODERN TATAR POETRY (ON THE EXAMPLE OF THE GAZAL GENRE)

***Garifullina Elvina Flarisovna***
Kazan (Volga region) Federal University, Kazan, Tatarstan, Russia

**Abstract.** *The article reveals the revival of Eastern traditions in modern Tatar poetry, the genres of which resemble the stylization of Eastern lyrics. In the course of study, attention is focused on identifying the genre-style originality of orientalgazal genre and genre forms.*

**Keywords:** *modern Tatar poetry; stylization; Eastern traditions; gazelle; genre.*

XX–XXI гасыр чиге татар поэзиясендә жанр өлкәсендә экспериментлар Урта гасыр Шәрык әдәбияты традицияләренә йөз тоту, көнчыгыш жанрларына охшатып стильләштерү күренешләренең активлашуы белән дә аңлатыла. Хәзерге татар поэзиясе жанр трансформациясе, яңарышы ягыннан гаять колачлы, масштаблы эзләнүләр алып бара. Узган гасыр ахырында иҗтимагый-сәяси вазгыятьнең алышынуы үзенчәлекле идеологик мәйдан буларак формалашып җиткән татар шигъриятенә көчле борылыш ясый, сүз сәнгатендә яктыртылган проблемалар гомумкешелек югарылыгына күтәрелеп, поэзия үзгә фәлсәфи-әхлакый, эстетик, сәяси кыйммәтләрне һәм аларны җиткерүнең үзгә юлларын, алымнарын, калыбын эзли башлый. Бу исә татар шигъриятендә жанрлар үзгәрешенә, трансформациясенә йогынты ясый [8, б. 295].

Мондый эзләнүләр газәл жанры кысаларында да алып барыла һәм, нигездә, ике шагыйрь – Р.Гаташ һәм М.Мирза иҗатлары белән бәйләнә. М.Мирзаның татар поэзиясендә соңгы чорларда онытылып торган шигъри формаларга мөрәҗәгать итүе һәм бу юлдагы уңышлы иҗат үрнәкләре, кыю тәҗрибәләре җитди игътибарга лаек: бу төр шигъри әсәрләре фәлсәфи фикеренең тирәнлеге, теленең байлыгы һәм үткенлеге, халыкчан образлылыгы белән аерылып тора. Нигездә, шагыйрь Урта гасырлар көнчыгыш жанрларына охшатып стильләштерә [9, б. 159], шигърияте жанрларын хәтерләтә торган “икенчел текстлар” белән эш итә. Татар әдәбиятында шәркый жанрларга охшатып иҗат ителгән әсәрләрнең “икенчел текстлар” дип аталырлык сыйфатлар алуы озак вакытлар дәвамында һәм урау юллар аша бара [3: 116]. Шәркый шигъри жанрлар нигезендә икенчел текстлар язылу мәсъәләсендә “чыганак-текст” белән бәйләнеш урнаштырырлык “текст төзелешенең уртак бер моделе булу” шарты турындагы фикергә нигезләнергә кирәк. [2, б. 43]. Мондый күренеш Рәдиф Гаташның өченче

чор иҗатына да хас. Ул традицион жанрга яңа алымнар кертеп, бүгенге җәмгыять алдында торган проблемаларны күтәрә. Әсәрләренең теле метафорик, шул рәвешле лексиканың төрле катламнары бербөтенгә оеша.

М.Мирза әсәрләрендә еш кына стильләштерү алымы дини жанрлар материалында чагылыш таба. Дога жанры нигезендә "өч яклы" код ята дип билгели әдәбият белгече Перевалова О.А. Дога эчтәлегендәге беренчел (символик) мәгънәләр сакланган хәлдә, текст башта авторның шәхси иҗади аңы аша уздырыла, аннары башка кешеләрнең кичереш-мөнәсәбәтләре рәвешендә гомумиләштерелә. [7, б. 102] Мәсәлән, "...Фатихасыз бер көнем дә торалмам..." шигыре изге текстларга охшатып, шуларның бер төрен хәтерләтә: формасы ягыннан дога рәвешен алып, жанрлык ягыннан Урта гасырлар дини-суфичыл әдәбиятындагы дога шигыре кебек кабул ителә:

Фатихасыз бер көнем дә торалмам,
Ил-көнемә иминлек бир, Бер Аллам [5, б. 225].

Элгәреге дини-суфичыл әдәбият белән интертекстуаль бәйләнеш шигырьнең эчтәлеген киңәйтә: адәм баласына һәрвакытта да иман кирәклеген һәм нәкъ менә ышаныч-өметнең барлык авырлыкларны кичеп чыгарга ярдәм итүен белдерә. Борынгы жанрны тергезү сиздерми генә элек гомер иткән кеше белән бүгенге арасында бәйләнеш җебе суза [3, б. 12].

Урта гасырлар дини-суфичыл мәдәнияттә "зөһед" (дөнья байлыкларына битараф булу) дип аталган хәл-халәт, суфи әдәбиятта исә жанр формасы яшәп килә. Суфилар мистик юлының бер этабы буларак, зөһед кичерү бу юлга аяк баскан суфи өчен мәҗбүри халәт санала: ул күңелне һәм йөрәкне дөньялык "пычракларыннан" арындыра, "чистарта", кешене дини хакыйкатьне кабул итергә әзерли. Урта гасырларда бу жанр формасы еш кына лирик "мин"нең үз күңеле белән сөйләшүе рәвешен ала. Мәсәлән, "Дөнья гел алыш-бирештә, аңла син..." шигырендә лирик герой рөхсәт ителмәгән байлыкларга битараф булу кирәклеген белдерә:

Гел алырга күнеккән куллар булыр,
Эзләренә эзләрең һич ятмасын [5, б. 244].

Зөһед шигырьләре нәсыйхәт шигырьләре белән структур яктан бик якын. "...Холыксызлар кемнедер гел битәрләр...", "Килгәнсең дә төпләнгәнсең бу якта", " Бәләкәй булсаң бул, тик син вак булма" шигырьләре үгет-нәсыйхәтчелекнең якты мисалы булып тора:

Холыксызлар кемнедер гел битәрләр...
Нидер кылып, хәтта хөкем итәрләр.
...
Якын йөрмә, шайтан орган – шулардыр,
Үтмәс чирләрен йоктырып китәрләр...[6, б. 234]

Яктыртмакчы булсаң халык күңелен,
Якынай һәм бул олы мәхәббәттә[5, б. 235].

Ялтыраган бар да түгел лә алтын,
Ятлар бәхетенә кызыкмак булма[5, б. 250].

Бер яктан, көнчыгыш поэзия жанрларына охшатып стильләштерү урын алса, икенче яктан, эчтәлек ягыннан трансформация чагылыш таба: иҗтимагый-сәяси максатларда – көн кадагындагы сәяси проблемаларга мөрәҗәгать иткәндә – цензур чикләүләрне узу өчен кулланыла:

Әйте, кардәш, һаман түзеп торыйкмы,
Суын сыккан каен кебек корыйкмы?

Җаһил җилләр җелекләрне өикәндә,
Бөкерәеп артка куеп торыйкмы? [5, б. 248]

Коллык беткән, имеш, калган ихтыяҗ,
Димәк, хаҗәт юк бетереп атарга...

Качып китмәс, баш күтәрмәс эш аты.
Мәскәү кулында алтатар – татарга!..[5, б. 231]

Көнчыгыш жанрларының матур мисалы булган газәлнең төп сыйфатлары Рәдиф Гаташ шигъриятендә дә урын ала. Х.Миңнегулов фикеренчә, ул Көнчыгыш шигъриятенең закончалыгын аеруча яхшы белеп эш итә [7, б. 208]. Гаташның газәлләре, Р.Ганиева билгеләп үткәнчә, Хафиз һәм Нәсими газәлләрен татар теленә тәрҗемә иткән кебек аларның шигырьләрен хәтерләтә. Нәкъ менә Хафиз газәлләре аша Гаташ иҗатына мәхәббәт–шатлык, мәхәббәт–хәсрәт / үлем мотивлары керә.

Газәл төзелешенә хас булганча, Гаташның шигырьләре лирик әсәр темасын билгели торган матланы (башлангыч бәетне) һәм гомуми кәефне билгели торган мактаны – ахыргы бәетне дә үз эченә ала. Әйтик, “Гашыйклар яше ашлаган гөл кыры” газәлендә башлангыч бәеттә сорау яңгырый, ә ахырында – җавабы:

Гашыйклар яше ашлаган гөл кыры! –
Мәйданың гыйбрәт өченме чакырды?
...
Гөлнең яшьсез керфеген үптем, дидем:
– Күкләр дә ишетсен, Гаташ, антыңны[1, б. 126]!

Гаташ өчен мәхәббәт – күкләр бүләге. Гаташ мәхәббәтне традицион шәркый символлар – гөл, күз яшьләре, ут аша җиткерә:

Буш чәчәк атса Хыялым агачы?
Һаман да илдә шәп исем-атым юк?
Билгем – Кучкар, фигылем – Ут...Балыкка
Йөзәр дәрья – яшем... Ник юк якынлык [1, б. 153]?

Лирик герой әлеге табигый образлар белән тәңгәлләштерелә һәм әлеге образлар вакыйгаларның турыдан-туры катнашучылары буларак кабул ителә.

Хатын-кызга карата мәхәббәт хисенә нигезләнгән Гаташның мәхәббәт лирикасы шәхси кичерешләр кебек тоелса да, ахыр чиктә ул үз эченә әхлак мәсьәләләре, Ватанга мәхәббәт кебек уй-фикерләрне дә сыйдыручы катлаулы эмоциональ һәм иҗтимагый бердәмлек булып укыла. “Миңгазәлгә газәлләр” моның ачык дәлиле булып тора.

Мисал өчен, “Узды бу яз..” шигыренә мөрәҗәгать итик. Эчтәлегендә кеше һәм табигатьнең бердәмлеге, дөнья шаукымы белән керешеп киткән ике өлкәнең синкретик бөтенлеге ачыла. Гаташ газәлгә хас булмаган мотивларны да кертә. Ул, дөнья малы артыннан чабып, мәхәббәткә дан җырлаучы кардәшеннән көлүчеләрне ирониягә дучар итә. Шулай итеп, газәлнең эчтәлеге, формаль билгеләрен саклаган хәлдә, социаль яңгырашны көчәйтү аша трансформация кичерә. Рифмалашуы тулысынча газәлнең формаль билгеләренә туры килә: биш бәеттән тора, рифмалашуы аа,ба,са,да,га. Ахырда – тәхәллүс килә:

Узды бу яз...Гөрләде, тынды сулар,
Басылмый ник җаныңдагы ярсулар?

Җирдәге бар сил-ташкыннар шундамы?
Ул ил-халык гаменнәнме борчулар?

Сәясәткә сәясәт иткән җан –тиз
Тынлык сорар: туйдыра шул шау-шаулар!

Мөхитме? Күр: күпме көнче, гайбәтче,
Хөсетлектән “илһам”, ямь табучылар...

Ә Гаташның көтә көн-төн язганың –
Юләрдер ул: “Яңа китап... – ди, – шулар ...” [1, б. 168]

Шул рәвешле, көнчыгыш жанрларына охшатып стильләштерү күренеше лирик герой концепциясенең үзгәреше ярдәмендә алып барыла. Моннан тыш, бүгенге поэзиядә газәл жанры классик, канунлашкан тематика белән генә чикләнми, аңарда традицион эчтәлек фәлсәфи уйланулар, уен мотивлары, этика һәм әхлак проблемалары белән баетыла яки тулысынча алыштырыла. Әнә шулай стильләштереп иҗат ителгән жанр формалары бүгенге әдәби барышта шәркый традицияләрнең дәвам ителеше, трансформацияләнеп тергезелүе хакында сөйли. Тикшеренү барышында ясалган нәтиҗәләр көнчыгыш шигъри традицияләренең хәзерге чор татар шигъриятен баетуда зур роль уйнавын тагын бер кат дәлилли.

**Әдәбият**


1. Гаташ.Р.К. Гөлтуран: шигырьләр, газәлләр, робагыйлар, төрки шигыйрьләр иҗатыннан үрнәкләр / Рәдиф Гаташ; [кереш сүз авт. Н.Хисамов]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 399 б.
2. Жанрологический сборник. Вып. 1. Елец, 2004. - С.43-48.
3. Заһидуллина Д.Ф. Мөхәммәт Мирза шигърияте: жанр өлкәсендә яңалыклар // Сайланма әсәрләр: 2 том. – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2018. – 383 б.
4. Заһидуллина Д.Ф Татар әдәбиятына хас үзенчәлекләр: икенчел эчтәлек тудыру // Tatarica.2014. №1. С.115-1266. Мирза М. Сайланма әсәрләр: 2 том. – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2018. – 383 б.
6. Мирза М. Сайланма әсәрләр: 2 том. – Казан: Мәгариф –Вакыт, 2018. –383 б.
7. Миңнегулов Х. Газәл жанры һәм Гаташ иҗаты // Гаташнәмә. Рәдиф Гатауллин-Гаташ иҗаты турында сәхифәләр. Мәкаләләр, эсселар, шигырьләр. Казан: Матбугат йорты нәшрияты, 2009. – 440 б.
8. Перевалова О.А. Стихотворная молитва в русской поэзии 19 века: жанровая динамика и типология: дисс. Канд. филол. наук. Екатеринбург, 2015. 207 с. http:// lib.urfu.ru Мөрәҗәгать итү вакыты – 27.03.2022
9. Юсупова Н.М. Хәзерге татар поэзиясендә шәркый жанрлар яңарышы // Жанрово-стилевое развитие национальных литератур в XX–XXI вв.: материалы Международной научно-практической конференции (4 декабря 2020 г., г. Казань). – Вып. 2 / сост.: А.Ф. Ганиева, Ф.Х. Миннуллина, Л.Р. Надыршина. – Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 2020. - Б. 295-302.
10. Юсупова Н. М. Идейно-художественные и жанрово-стилевые особенности поэм М.Мирзы / Н.М. Юсупова // Филология и культура. Philology and Culture. – 2020. - №1(59). – С. 159.


УДК 82(091)

## МАТРИЦА ЭСХАТОЛОГИЧЕСКОГО МИФА В СЮЖЕТОПОСТРОЕНИИ: АНТИУТОПИЯ М. КАБИРОВА «САГЫНДЫМ, КАЙТ ИНДЕ»

***Давлетшина Лейла Хасановна***
Институт международных отношений Казанского (Приволжского) федерального университета, г. Казань, Татарстан, Российская Федерация
*e-mail: leyla.davletshina@yandex.ru*

**Аннотация**. *В статье рассматривается сюжетопостроение антиутопии М. Кабирова «Сагындым, кайт инде» в аспекте матрицы эсхатологического мифа, которая структурируется на основе универсальных схем мировой мифологии, наполняясь содержанием, обусловленным представлениями и верованиями национальной мифологии.*

**Ключевые слова:** *мифология; эсхатология; матрица; сюжет; образ; структура.*

# THE MATRIX OF ESCHATOLOGICAL MYTH IN PLOT CONSTRUCTION: M. KABIROV'S DYSTOPIA «MISSED YOU, COME BACK ALREADY »

***Davletshina Leila Khasanovna***
Institute of International Relations of the Kazan (Volga region) Federal University,
Kazan, Tatarstan, Russia

**Abstract.** *The article examines the plot-building of M. Kabirov's dystopia "Sagyndym, Kite Inde" in the aspect of the matrix of eschatological myth, which is structured on the basis of universal schemes of world mythology, being filled with content conditioned by ideas and beliefs of national mythology.*
**Keywords**: *mythology; eschatology; matrix; plot; image; structure.*

Матрица эсхатологического мифа программирует жанровое пространство антиутопии в целом. Даже если в тексте нет явных отсылок к мифологическим дефинициям, отсутствует опосредованное воспроизведение мифологических образов и сюжетов, структура мифа о конце света просвечивает сквозь сюжетную структуру произведения. Одним из таким произведений является антиутопия *М. Кабирова «Сагындым, кайт инде...»* («Соскучился, вернись уже...», 2008), где «средствами постмодернистской поэтики и эстетики (фрагментарность, двойное кодирование, цитатность, описание потока бессознательного и т.д.) и фантастики писатель предупреждает о возможности исчезновения человека вообще, которое начинается с уничтожения книг, установления тотального контроля за людьми, превращения их в роботов» [2, б. 229]. Повествование строится на пересечении нескольких временных пластов, объединяемых образом главного героя Искандера (детство Искандера, его юность, приход к профессии писателя, составляющие прошлое; события, связанные с его арестом, арестом жены, с приключениями его детей, уничтожением человечества, характеризующие настоящее общества, в котором они живут). Главного героя антиутопии – писателя Искандера Д.Ф. Загидуллина называет автобиографическим героем-повествователем, образом типического автора в татарской литературе [2, б. 215], который становится свидетелем факта истребления народа Высшим Правительством и объединяет в себе несколько повествовательных линий. В событиях прошлого он предстает под конкретным именем Искандер как талантливый мальчик, воплотивший свои мечты и ставший писателем, а в событиях настоящего фигурирует под отвлеченным именем Язучы, что указывает на его расширительную функцию в контексте реализации матрицы эсхатологического мифа.

«Эсхатологический миф не санкционирует существующий социальный и космический порядок в том его понимании, которое свойственно данной культуре, а отрицает существующий порядок, поскольку он *неправилен.* Объявляя, что сейчас все происходит, как оно *не должно* происходить, эсхатология взывает к обновлению с целью создания нового мира, когда все будет происходить так, *как должно*» [1, б. 304]. В исследовательской практике эсхатологические представления, прогнозирующие будущее, сводятся к набору нескольких крупных семантических элементов и наиболее распространенных мотивов [4, б. 28].

Первый мотив эсхатологического мифа описывает эпоху хаоса и активизации сил зла, когда господство зла считается нормой, но на самом деле таковым не является. В повести «Сагындым, кайт инде…» данный мотив проявляется на уровне следующих характеристик:

– деградация нравов (проявление хищнических качеств в человеке при виде денег, отказ от культурного и исторического достояния прошлого, превращение смертоубийства из-за незначительной причины в норму, всеобщее распространение алкоголизма и других вредных привычек и т.д.);

– прежние сферы деятельности становятся вредоносными (сжигание книг, объявив их прежде ненадобными и вредными для современного человека, поощрение безропотно подчиняющихся людей наградами и высокими титулами; запрет на литературную деятельность, уничтожение науки и свободы слова, поощрение рабочих профессий);

– прежние сакральные локусы теряют свою святость (вымывание веры во Всевышнего и религиозных воззрений из сознания обывателей, их замена на искусственно сформированного нового бога – Золото, и как следствие, разрушение религиозных сооружений и институтов);

– праведные подвергаются гонениям (истребление тех, кто пытался противостоять надвигающейся катастрофе, карательными органами);

– переворачивание общественной иерархии (власть становится незаконной и устанавливает свои порядки, которые разрушают существующий общественный и политический строй; спасательные службы превращаются в карательные (пожарники отстраняются от своей основной функции, занимаются сжиганием книг и неподчиняющихся правительству людей, основная цель медицинских работников – соблюдение своевременного приема «роботизирующих» таблеток); общество расслаивается по иному приниципу в соответствии со степенью подчинения Высшему Правительству – достойные (*лаеклы кешеләр*), прежняя интеллигенция, отвергнутая обществом, но сохранившая «человеческую» суть (*мәмкәләр*); люди, потерявшие себя под влиянием новых общественных ориентиров – денег (*комаклар* – в переводе с татарского «крыса»).

Второй мотив эсхатологического мифа – *катастрофа*, к которой приводит предшествующая ей ситуация, ведущая население к всеобщей гибели. Для реализации этого замысла всех граждан под предлогом того, что прививают от рака, заставляют сделать укол и постоянно употреблять таблетки, из-за которых человек теряет способность мыслить и чувствовать. В результате спланированных действий Высшего Правительства происходит всеобщая гибель и исчезновение «людей» как биологического и социального вида и превращение их в бездушных роботов. «В конечном итоге живых людей на земле должны будут заменить роботы, которые смогут выполнить любую прихоть Великого Царя, Высшего Правительства, не задавая никаких вопросов. Этот замысел напоминает жене главного героя Таңсылу / Таңчулпан (в тексте имя героини постоянно меняется, что акцентирует внимание на ирреальности событий, происходящих в воображении главного героя, также говорит об условности героев) ужасающее племя, которое мечтало стать правителем всего мира» [5, б. 160]. *“Без фәннең алга кискен сикереш ясавы нәтиҗәсендә үзебезнең яшәү рәвешен тәэмин итәрлек роботлар булдырырбыз, ә аңа кадәр бу вазифаны мәмкәләр башкарып торыр. Без аларны ни кушсак шуны үти торган ихтыярсыз һәм надан, әмма тырыш һәм җитештерүчән колларга әйләндерербез”* [3, б. 57](“В результате резкого развития науки мы сделаем роботов, которые будут обеспечивать наше существование, а до этого момента делом будет заниматься интиллигенция (*мәмкәләр*). Мы превратим их в безвольных и необразованных, но трудолюбивых и производительных рабов, которые будут выполнять все, что мы пожелаем”. Государство проявляет себя на всех уровнях общественного устройства, полностью контролируя жизнь, мысли, действия и будущее человечества.

Катастрофа приводит к актуализации следующего мотива эсхатологического мифа – *спасение немногих людей*, которое связано с *убежищем* – местом, пригодным для жизни, но замкнутым и скрытым. В повествовании важное место занимает топологическое пространство Центрального Рынка, на котором обитают низшие элементы нового общества – «настоящие» люди, гении, вынужденные притворяться «обезьянами», так как за пределами этой тюрьмы им грозит сжигание от рук пожарников. *“Асылда монда җәмгыятьнең иң түбән элементлары, яшәр йорты, ашар ризыгы, эшләр эше булмаган элекке артистлар, сәнгать әһелләре, фәйләсүфләр һәм башка шундый әтрәк-әләмнәр хакимлек итә, монда аларны ашаталар да, иске-москы киемнәр дә бирәләр, ләкин шәһәрнең башка урыннарына чыгып йөрергә рөхсәт итмиләр”* [3, б. 39]. (“По сути, здесь правят низшие элементы общества, бывшие артисты, деятели искусства, философы и т.п., у которых нет дома, еды, работы, здесь их кормят и одевают в старье, но не разрешают выходить на территорию города”). Однако это только верхний слой, видный невооруженным глазом, на самом деле в подземном городке живут спасенные от тотального контроля люди, которые сохраняют прежнее историческое, культурное и научное достояние человечества и готовятся к установлению нового мира. Существование убежища предполагает наличие *ведущего туда потаенного пути*, который и

преодолевают сыновья Искандера. Образ убежища и пути к нему возникает дважды: как место проживания «людей», спасенных от Высшего Правительства, но не сумевших совершить переворот, и как поляна в далеком уединенном лесу, на которой дети, спасшиеся от захвата мира после уничтожения человечества роботами, читают книгу Писателя.

В процессе развития сюжетного повествования образ Искандера раскрывается в нескольких направлениях, в нем совмещаются и успешный писатель, и любимый муж, и отец двоих сыновей. Однако через всю свою жизнь он несет тоску об отце, которая кровоточит незаживающей раной в его сердце. В образе Искандера проявляются качества мессианского персонажа, приход которого неизбежен при установлении нового порядка. Именно ему по канонам эсхатологического мифа уготовано одержать победу над хаосом. Слова предводителя оппозиционеров Высшего Првительства указывают на то, что именно книги Писателя были для них путеводной звездой, способом сохранить свою личность. *"Болар барсы да сезнең иҗат. Алар безнең кешеләргә рух ныклыгы бирде, өметсезлеккә батмаска ярдәм итте. Теге дәверләрдә, бәлки, бик сизелмәгәндер дә, ә безнең чорда, язма сүзгә, бүгенге әдәбиятка кытлык кичергәндә, аларның әһәмияте әйтеп бетергесез зур булды. Мин сезне хәтта революциянең төп идеологы дип атар идем. Нинди генә сынаулар булса да бирешмәдегез. Рәхмәт. Үз шәхесен, рухи югарылыгын саклап кала белгән талантлар халыкның таянычы ул"* [3, б. 78.] ("Все это ваше творчество. Они дали нашим людям крепость духа, помогли не отчаиваться. В те времена, может быть, и не было заметно, а в наше время, когда ощущается дефицит письменного слова, современной литературы, их значение было неописуемо велико. Я бы даже назвал вас главным идеологом революции. Какие бы испытания вам мне выпали, вы не сдались. Спасибо. Таланты, умеющие сохранять свою индивидуальность, духовность, являются опорой народа"). Спаситель человечества – мессия, воплощенный в типологизированном персонаже Искандере – Писателе, должен явиться и спасти человечество в соответствии с матрицей эсхатологического мифа, но автор убивает своего персонажа, тем самым оставляя человечество в состоянии ожидания. Слова «Сагындым, кайт инде» звучат рефреном на протяжении всей повести и возвращают нас каждый раз к начальной точке отсчета, когда мессия приходит на землю, но умирает, не выполнив свою миссию, что приводит к постоянному перерождению различных форма хаоса.

Таким образом, закрытая модель антиутопического понимания мира формирует сложноорганизованную структуру, которая, с одной стороны, реализует в своем составе матрицу эсхатологического мифа, с другой, обращается к «исходному» материалу национальной и религиозно-мифологической традиции. В центре авторского мифа находится главный герой, который несет на себе разные функциональные роли, обобщаясь в типологизированном персонаже – мессии, который должен построить новый упорядоченный мир, но антиутопическая модель действительности по определению жанра отрицает подобную концовку. Интересным является мотив о всесильности человека. Ответственность за настоящее и будущее, за судьбу Земли, Вселенной, общества возлагается на Человека. Глубокий психологизм, эмоциональность подобных произведений объясняется желанием писателей наиболее полно раскрыть духовный мир, ментальность, характер и мировоззрение идеализированного героя.

## Литература


1. Ахметова М.В. Конец света в одной отдельно взятой стране: Религиозные сообщества постсоветской России и их эсхатологический миф. – М.: ОГИ; РГГУ, 2010. – 333 с.
2. Загидуллина Д.Ф. Татарская литература XX – нач. XXI вв.: «мягкость» модернизма-авангарда-постмодернизма (к постановке проблемы). – Казань: ИЯЛИ, 2020. – 256 с.
3. Кәбиров М. Сагындым, кайт инде. – «ЛитРес: Самиздат», 2019. – 82 б.
4. Неклюдов С.Ю. Мифологическая традиция и мифологические модели // Вестник РГГУ. – 2011. –№ 9 (71)/11. – С. 11–33.
5. Юзмухаметова Л.Н. Новые явления в татарской прозе рубежа XX–XXI веков: постмодернизм. – Казань: Изд-во Казанского ун-та, 2016. – 220 с.

УДК 821.0.

# НАЦИОНАЛЬНЫЙ ДУХ В ТВОРЧЕСТВЕ ГАЯЗА ИСХАКИ
# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ИҖАТЫНДА МИЛЛИ РУХ

***Даутов Гумар Фильгизович***
Елабужский институт Казанского (Приволжского) Федерального университета,
г. Елабуга, Татарстан, Российская Федерация
*e-mail: dautovgumar@mail.ru*

**Аннотация.** *Гаяз Исхаки – один из самых талантливых татарских писателей начала XX века. Каждое его произведение посвящено описанию татарского бытия, а также раскрытию его прекрасных качеств. Произведения писателя различной тематики объединены одной особенностью – духом народа.*

**Ключевые слова:** *литературный прогресс; общественно-исторические события; татарское бытие; джадидизм и кадимизм.*

# THE NATIONAL SPIRIT IN THE CREATIVE ACTIVITY OF GAYAZ ISKHAKI

***Dautov Gumar Filgizovich***
Elabuga Institute of the Kazan (Volga region) Federal University,
Elabuga, Tatarstan, Russia

**Abstract.** *Gayaz Iskhaki is one of the most talented Tatar writers of the early XX century. Each of his works is devoted to the description of Tatar life, as well as the disclosure of its beautiful qualities. The works of the writer of various subjects are united by one feature – the spirit of the tatar people.*

**Keywords:** *literary progress; sociohistorical events; Tatar life; Jadidism and Kadimism.*

Билгеле булганча, XIX йөзнең I яртысында формалаша башлаган татар буржуазиясе, гасыр ахырында шактый гына күпсанлы һәм яхшы гына матди байлык туплаган социаль төркемгә әверелә. XX йөз башында ул чәчәк ату чорын кичерә, Россия күләм капитал әйләнешендә сизелерлек роль уйный башлый. Буржуазия табигате белән интернациональ булса да, XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар сәүдәгәрләрендә, эшмәкәрләрендә милли үзаң көчле була. Монда Россия хөкүмәтенең татар сәүдәгәрләренә төрле икътисади чикләүләр куюы да, кайчандыр дәүләт булып яшәгән халыкның дәүләтчелек хисе көчле булуы да, ислам динендә булганлыктан, мөселманлыкны милләт белән тәңгәлләштереп кабул итү дә роль уйнагандыр. Ничек кенә булмасын, татар буржуазиясе һәм татар зыялылары милли яңарыш хакында уйлана, нindидер чаралар күрү хакында уйлана башлыйлар.

Татарлар компактлы яшәгән төбәкләр Россиянең үзәгендә үк булганлыктан, нindидер аерым территориаль үзбилгеләнеш турында сүз дә була алмый. Татарларның тулысынча ил яшәешенә интеграцияләнүен, үзләрен тулысынча Россия гражданнары дип исәпләүләрен һәм тоюларын да әйтергә кирәк. Милләт яшәешенең һәр йөрәк тибешен, сулышын тоеп яшәгән Тукайның сүзләре:

Иң бөек максат безем: хөр мәмләкәт – хөр Русия!

Тиз генә кузгалмыйбыз без, и гөруһе русияһ! – моңа мисал.

Киң катлам халыкның милли үзаңын уяту, алгарышны тәэмин итү өчен укымышлыларыбыз мәгариф өлкәсен алалар. Барысы да диярлек укый-яза белә, ягъни грамоталылык гадәти күренеш булган татарларда мәгърифәтчелек идеяләре мул уңыш бирә. Тарих өчен чагыштырмача кыска вакыт аралыгында мәгърифәтчелек әдәбияты формалаша, татар мәктәп-мәдрәсәләре яңача укыту программасына күчә, алай гына да түгел, "... хәтта кадими ысул мәдрәсәләрендә дә белем бирүнең сыйфаты сизелеклек яхшыра".

Югарыда әйтелгәннәр татар әдәбиятының “Алтын чор” дип аталган дәверен тууга җирлек булалар. 1905 ел революциясе нәтиҗәсендә туган демократик үзгәрешләр, татар телендә вакытлы матбугат барлыкка килү, типографияләр санының кискен артуы, әдәбиятның һәм сан, һәм сыйфат ягыннан яңа баскычка күтәрелүенә китерә.

1905-1917 еллар аралыгын колачлаган татар әдәбияты чын мәгънәсендәге милли әдәбият булып формалаша, милли мәнфәгатьләргә хезмәт итә, халык яшәешен аның, бары татарның тормышына гына хас булган аспектларын, сыйфатларын тикшерә. Аерым вәкилләренең тормышы, психологиясе аркылы ул милләтнең рухын, яхшы якларын, тайпылышларын тикшерә. Бу ноктадан караганда бигрәк тә Г. Исхакый иҗаты кызыклы. Аның кайсы гына әсәрен алып карама, татар менталитетының бер ягын аяуга багышланган.

Әдип татар тормышының иң өстә яткан, гадәти булган, һәм шул гадәтилеге белән игътибардан читтә калып килгән, ләкин татарны татар иткән үзенчәлекле сыйфатларны тотып алып, гаять зәвыклы һәм кызыклы итеп укучыга җиткерә белә.

Яңалык, алгарыш аркылы милләтне алдынгы халыклар дәрәҗәсенә күтәрергә омтылучы җәдидчеләр һәм искечә, элеккечә яшәү аркылы урбанизация шартларында телне, динне саклап калуны максат иткән кадимчеләр көрәшне XX йөз башы татар иҗтимагый тормышының эчтәлеген билгели. Ул яшәешнең бар өлкәләрен дә колачлый һәм әдәбиятта турыдан туры да, аның нәтиҗәләре булган күренешләр аркылы да чагылыш таба. Ул Г. Исхакый иҗатында да чагылыш таба.

Бу чор Г. Исхакыйның гына түгел, бөтен татар зыялыларының эзләнү чоры. С. Рәмиев: “Мин!” димен мин, “мин” дидисәм,

Миңа бер зур көч кирә,

Аллалар, шаһлар, кануннар

Булалар бер чүп кенә” дип күтәрелеп бәрелеп гыйсъянчылыкка кереп китә. Г. Ибраһимов беренче психологик роман булган “Яшь йөрәкләр”е белән рәттән: “Бөтен хәят, бөтен тарих безгә бер хакыйкатьне тәкрар итә: Сәнгать – яңа заманның дине, бөек сәнгатькярләр ул диннең пәйгамбәрләредер”, – дип игълан итә. [1]

Г. Исхакый әдәби эшчәнлеген “Тәгаллемдә сәгадәт, яки Гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер” (1899), “Кәләпүшче кыз” (1900) кебек мәгърифәтчелек рухындагы әсәрләр язып башлый. 1900 елда ул татар тормышына зур зыян китерә дип уйлаган күпхатынлылыкка мөрәҗәгать итеп “Өч хатын берлән тормыш”ны мәйданга куя, 1903 елда сөю хисен үзәккә алган “Очрашу, яки Гөлгыйзар”ны иҗат итә. 1904 елда Ф. Мусин тарафыннан: “... әсәр татар әдәбиятындагы үзгәрешләр өчен борылыш ноктасына әверелә” дип бәяләнгән “Ике йөз елдан соң инкыйраз” повестен укучыга тәкъдим итә. Иҗтимагый-сәяси карашлары белән эсерлар партиясендә торган чагында шул карашлары чагылыш тапкан “Теләнче кыз”ын (1907) яза. [2]

Күргәнебезчә, әдип игътибарын күп нәрсә җәлеп итә. Ләкин, әдәбият фәнендә “Таңчылык” дәвере дип билгеләнгән чорда да ул милли аспектны калдырмый, ә инде иҗатының “Миллилек” дип исемләнгән этабында халкының рухын алгы планга чыгарып язу әйдәп баручы факторга әверелә. Сәнгатьнең көчен билгеләп Г. Ибраһимов болай ди: “Милләтнең, милли рухның җимгә аумас, суга батмас, утка янмас мәртәбәдә куәт алуы һәм дә мәдәни бер калыпта корычка әйләнүе өчен – ул үзенең сәнаигы нәфисә (матур сәнгатенә) мохтаҗ” [2].

Татарның яшәеше ислам дине белән билгеләнә. Әгәр Европа цивилизациясе беренче планга матди байлыкны куйса, кешенең фани бик үк матур булмаган рәхәтлекләрен татуына беркадәр бармак аша гына карса, Ислам биш вакыт намаз аша һәрдаим бәндәнең Аллаһ тарафыннан яратылган булуын, аның бу дөньяда кунак кына икәнлеген, дөнья нигъмәтләренең бары Илаһтан гына икәнлеген искәртеп тора. Гыйбадәтне үз вакытында үтәп баручы мөселман бозыклык тудыруны хәмер, зина кебек гөнаһлардан азат һәм рухи, һәм физик яктан сәламәт булуның ямен-тәмен тоеп, табигый яшәешкә шөкер итә белә. Шундый тыныч, күктән йолдыз чүпләмичә яшәүнең һәм, безгә калса, татар халык массасының яшәү урынын Г. Исхакый “Сөннәтче бабай” повестендә бирә. 1911 елда язылган бу әсәрнең нindидер күзгә күренмәгән эчке самимилеген Ф. Мусин: “Сөннәтче бабай”да татар тормышының традицион билгеләре –

Татар әдәбиятында илаһилыкка мөрәҗәгатьнең, илаһи диалогның борынгыдан хәзерге вакыткача актив кулланылуы төрле тарихи чорларда татар әдәбиятында сакраль диалог бирелеше үзенчәлекләрен тикшерү өчен уңдырышлы җирлек булып тора. Мәгълүм булганча, Борынгы һәм Урта гасыр чорларына караган әдәбият синкретик характерда булып, ул бер үк вакытта әдәби, мәдәни, педагогик, дини, фәлсәфи, тарихи һәм башка характерларны үзендә берләштерә алган. Безне бигрәк тә әдәбият һәм теология кушылмасы кызыксындыра. Татар әдәбиятында ул борынгы төрки-татарларның ышанулары, дини күзаллаулары белән бәйләнештә каралырга тиеш.

Табигатьтән өстен торып, Җиһандагы бөтен җанлы һәм җансыз затлар, күренешләр, вакыйгалар, шул исәптән кешенең дә язмышы, һәрбер адымы, фикере-уйлары белән идарә итә торган көчләрнең, мәрхәмәтле яки явыз затларның булуына ышану, аларга табыну, шуларга багышлап, дога кылу, йолалар уздыру, кешенең үзен һәрвакыт шул илаһи көчләрнең колы дип сизүен дин дип таныйлар [7, б.16]. Кешелек тарихының иң борынгы баскычларында ук диннең булуы билгеле. Диннең иң борынгы формалары кешегә аңлашылмаган һәм хәтта билгеле булмаган көчләргә ышану, кайдандыр һәм кемнәндер ярдәм сорау, табигатькә ниндидер йогынты ясау теләге нигезендә барлыкка килгәннәр. Иң борынгы диннәр дип, тотемизм, фетишизм, анимизм һәм магияне атыйлар [2, б. 19]. Без эшебездә башлыча сакральлекне ислам дине белән бәйләнештә карарбыз.

Болгар чорының күренекле ядкяре “Кыйссаи Йосыф”та сакраль диалогның татар әдәбиятындагы төп үзенчәлекләрен күзәтергә мөмкин. Ул ике юнәлештә тормышка ашырыла: язучының, шагыйрьнең үзенә көч-куәт, тормыш, илһам биргән чыганакка – Аллаһыга, Тәңрегә мөрәҗәгате, үтенеч белдерүе, рәхмәт әйтүе һәм пәйгамбәрләр нәселеннән булган Йосыфның фәрештәләр аркылы Аллаһы белән аралашуы. Шагыйрьнең Аллаһыга мөрәҗәгате үз чоры әдәбияты өчен әсәрләрнең традицион характеры белән аңлатыла:

*Өмет багълыйм мин гөнаһлы Син тәңрегә,*
*Шәфкатьле һәм мәрхәмәтле Син вәлигә,*
*Кыл мәрхәмәт-шәфкать миңа – Кол Галигә,*
*Кайгылы бу күңлемне син шат кыл имди.*
*Ходавәндә, бар хаҗәтем сиңа мәгълүм,*
*Мин зарлының мөнаҗәте сиңа мәгълүм,*
*Мин колыңны рәхмәтеңнән кылма мәхрүм, –*
*Соң сулышта иман бүләк кыл Син имди [4].*

Йосыфның Аллаһы белән аралашуы нигездә фәрештәләр аша тормышка ашырыла. Ул тормышының иң авыр мизгелләрендә аңа сыена, сабырлык сорый, Ул биргән тормышның һәр ягы белән риза булуын белдерә. Аллаһының җаваплары я төш күрү мотивы, я Җәбраил фәрештә аша адресатка килеп җитәләр. Моннан кала Аллаһыга бирелгән сорауларга җавапны Коръәндә табу мөмкинлеге дә ассызыклана:

*Коръәнендә Халикъ шундый киңәш биргән:*
*“Алла рәхмәтеннән өмет өзмә! – дигән, –*
*Моңа инанмаучы кяфер була икән, –*
*Рәхмәтеннән, өмет өзмәү кирәк имди” [4].*

Сакраль диалогның “Кыйссаи Йосыф” әсәрендәгечәрәк корылышы озак гасырлар буена татар әсәрләрендә сакланып килә. Бары XIX йөзнең икенче яртысы – XX йөз башында ул яңа төсмерләр белән баеп, яңа мотивлар белән баетыла. Шунысы кызык: мондый диалогларның бер ишләре ризасызлык, дәгъва кылу, сыкрау хиссиятләре белән характерланса, икенчеләре,

киресенчә, Җирдәге тормыш белән канәгатьлелек белдерү, алдагы тормышны да, Аллаһы ярдәме белән, тыныч-имин уздыруларына өмет белдерәләр.

Канәгатьсезлек һәм дәгъва белдерү XX йөз башында халыкта революцион хисләр, инкыйлаби рух уяну, Җирдәге гаделсезлекне аңлау һәм кабул итмәү белән турыдан-туры бәйләнгән. Бу яктан М.Гафури иҗаты күрсәткеч булып тора. Аның лирик герое "Тәңрене искә төшерү" шигырендә Алла белән эчке диалог кора. Ул кешеләрнең Аллаһны авыр минутларыбызда гына искә төшерүе турында уйлана, шул ук вакытта аның Аллага да сораулары юк түгел: нигә явыз кеше яхшы яши, ә яхшы кеше начар яши?

*И Ходай! Яхшы кешең... юк, кем керер оҗмахыңа?*
*Кайда ул чын яхшылар?.. Кайда чын ихсанчылар? [4]*

Шагыйрь, явызлыкка каршы торган бер генә көч бар, ул да булса Алла дисә дә, 1915 елдагы шигырьендә "Юктырсың ла Алла", дип, үзенең икеләнүен белдерә:

*Юктырсың ла, Алла! Әгәр булсаң,*
*Сабыр итмәс идең бу эшкә [4]*

Хәтта "Гомернең иң читен, җайсыз, уңайсыз бер минутында" Коръән алып юануы турында язган Г.Тукай да Аллаһыга турыдан-туры мөрәҗәгать итеп, ризасызлык белдерә:

*Я Ходай! Ни өчен кешеләрне төрле-төрле кылдың?*
*Нилектән соң мин бөтен түбәннәрдән дә түбән булдым? [6, б.240].*

Ризалык, шөкер итү һәм киләчәккә якты өметләр баглау мотивын Ф.Әмирханның "Хәят" повестендә күрәбез. Ике дин, ике менталитет йогынтысын тоеп үскән Хәят әсәр ахырында ныклы карарга килә: аның бәхете, киләчәге рус милләтле Михаил түгел, татар егете белән бәйле булырга тиеш. Шул саф татар гаиләсенә мәхәббәт һәм иминлек сорап, ул бар өметләрен Аллаһыга юнәлтә.

Совет чоры әдәбиятында сакраль диалог, сакраль пространство һәм образлар әдәбиятта сизелерлек кимесә дә, 80-90 елларда бу мотивлар әдәбиятта яңадан үзенең көчле тавышын күрсәтә. Биредә дә ризасызлык, гасабилану мотивлары да, рәхмәтле булу мотивы да урын ала. Мәсәлән, шагыйрь Зөлфәтнең 1989 елда язылган "Шик" шигырендә катгый дәгъва белдермәсә дә, Җир һәм Күк тормышы серләре, үзенең Җирдәге вазифасы турында Аллаһыдан сорарга тели:

*– Сүзең кызганмачы, Ходаем!*
*Беләсең бит, юкса, барлык серне. –*
*Мәңгелекнең, мәлнең серләрен!*
*Шуны белгән килеш, Хак Тәгаләм,*
*Нигә мине Җиргә җибәрдең? [3, б.8]*

Сакраль диалог мотивлары Ф.Бәйрәмова әсәрләрендә еш очрый. Документальлеккә тартым "Караболак" романы да, реалистик юнәлештә язылуга карамастан, мистик эпизодларга ия. Шуларның берсе төп героиня Гөлҗиһанның авыруы белән бәйләнештә бирелә. Яшәү белән үлем арасында тартышып яткан героиняны бу дөньяга Илаһи затның ярдәме генә кайтара: "Ул, Гөлҗиһан янына тезләнеп, нидер укый башлады... Нәкъ карттае, картнәе Коръән укыган кебек... Ә тавышы Таһирҗан бабасына охшаган... Ул укыган саен, Гөлҗиһанның хәле җиңеләя бара, күкрәген басып торган авырлык юкка чыга, ул тагы иркен сулыш ала башлый... Менә озын карт, аның өстенә ныграк иелә дә, нидер әйтә... Ә тавышы нәкъ Таһир бабайныкы кебек... "Су эчмә... Ризык ашама... Монда торма...", – ди... Шул сүзләрне әйтә дә, озын бабай юкка чыга... Гөлҗиһан берни аңламый, зәңгәр күккә карап тик ята" [2, б. 52]. Гөлҗиһанның Илаһи тавыш биргән киңәш буенча яшәве, радиация нуры белән агуланган авылда яшәүче милләттәшләренә ярдәм итүе, милли һәм шәхси хокуклар өчен көрәше тормыш максаты итеп сурәтләнеп, Аллаһыдан иңдерелгән вазифаны башкару төсмере ала.

Сакраль дөнья белән кешеләр дөньясы кисешү мотивлары Г.Гыйльмановның фантастик, мистик әсәрләрендә урын ала. Биредә Аллаһы, Тәңрегә мөрәҗәгать итү, илаһи көч ярдәмендә фаҗига, афәттән котылу, борынгы сакраль практикалар кулану кебек эпизодлар очрый һәм болар XXI гасыр башы әдәбиятына хас үзенчәлек – мифологизм, кеше һәм табигать берлеге турындагы идеяләргә нигезләнгән тотемистик карашларны үзәккә алу белән бәйләнгән.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: татар әдәбиятында сакраль диалог нигездә кеше һәм Аллаһының турыдан-туры яки арадашчылар аша аралашуы буларак тормышка ашырыла. Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятында ул тулысынча Илаһыга ышану, аңа сыену төсен ала. XX гасыр башында чынбарлык белән канәгатьсезлек, төрле дәрәҗәдә дәгъва белдерү мотивлары яңгырый башлый. XX гасырның соңгы ике дистәсендә, совет чоры әдәбиятындагы тынлыктан соң, сакраль дөнья белән аралашу әдәби әсәрләрдә яңадан гәүдәләнеш таба башлый. Хәзерге вакытта бу тенденция һаман дәвам итә, аеруча Ф.Бәйрәмова, Г.Гыйльманов кебек әдипләр иҗатында көчле яңгыраш ала.

### Әдәбият


1. Алексеев В.И. Сакральный диалог как структурообразующий принцип в ономатологии божественного // Вестник Новосибирского государственного университета. Серия: лингвистика и межкультурная коммуникация. – 2013. – Т.11. – №1. – С. 64-71.
2. Бәйрәмова Ф. Караболак // Казан утлары. – 2005. – № 11. – Б. 10-58.
3. Борисов С.Н., Оська Я.М. Сакральное в современной культуре // Наука. Культура. Искусство: актуальные проблемы теории и практики. – URL: https://cyberleninka.ru/article/n/sakralnoe-v-sovremennoy-kulture-podhody-k-opredeleniyu-i-granitsy-ponimaniya-1/viewer; (мөрәҗәгать итү вакыты: 15.04.2022).
4. Гафури М. Әсәрләр: 4 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980-. – Т. 1: Шигырьләр һәм мәсәлләр (1902-1917). – 1980. – 535 б.
5. Дәүләтшин Г.М. Борын-борын заманда... Миф, дин, сәнгать. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 51 б. 8
6. Зөлфәт. Тылсым (шигырьләр) // Казан утлары. – 1994. – Б. 3-10.
7. Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. – URL: https://belem.ru/node/5531; (мөрәҗәгать итү вакыты: 17.04.2022)
8. Лазареску О.Г. Мотивы и образы сакральных практик народов Сибири как фактор поэтики произведений русской литературы // Вестник Томского гоударственного университета. Филология. – 2019. – №60. – С.183-194.
9. Тукай Г. Әсәрләр. Дүрт томда. 1 нче т.: шигырьләр. – Казан: Таткнигоиздат, 1955. – 325 б.
10. Урманче Ф. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 т. – Казан: Мәгариф, 2009. Т.2.– 343 б.


УДК 37.013

## РОЛЬ ЭПИЧЕСКИХ ПРОИЗВЕДЕНИЙ В ВОСПИТАНИИ ПОДРАСТАЮЩЕГО ПОКОЛЕНИЯ

***Кыдырова Бурул Абдыкадыровна***
Ошский государственный педагогический университет,
г. Ош, Кыргызская республика
*e-mail: kerben1996@mail.ru*

**Аннотация.** *В статье описываются источники эпических произведений - мифов, легенд, сказок, басен, рассказов, повестей, былин, которые являются сокровищницей воспитания в развитие нравственности подрастающего поколения. В статье представлены основные идеи эпических произведений. В сказках, несравненных по гениальности народного образования, одном из ценнейших сокровищ, доставшихся от наших предков нынешним поколениям, легендах, баснях и аллегорических образах, былинах, которые учат подрастающее поколение мудрости, патриотизму, дружбе, человеческим качествам.*

*Эпические произведения развивают характер вежливого, скромного, чистого, патриотичного, смиренного, гуманного, сострадательного и побуждают ребенка быть гармоничным и патриотичным через духовно-эпические произведения в воспитании будущих поколений. В них описываются благородные педагогические идеи, многовековая мудрость нашего народа, качества умственности.*

**Ключевые слова:** *духовные ценности; воспитание; эпос; духовное сокровище; народная история.*

## THE ROIE OF EPIC WORKS IN THE UPBRINGING OF THE YOUNGER GENERATION

***Kydyrova Burul Abdikadyrova***
Osh State Pedagogical University, Osh city, Kyrgyz Republic

**Abstract.** *The article describes the sources of epic works - myths, legends, fairy tales, fables, short stories, stories, epics, which are a treasure trove of education in the development of the morality of the younger generation. The article presents the main ideas of epic works. In fairy tales, incomparable in the genius of public education, one of the most valuable treasures inherited from our ancestors to current generations, legends, fables and allegorical images, epics that teach the younger generation wisdom, patriotism, friendship, human qualities.Epic works develop the character of polite, modest, pure, patriotic, humble, humane, compassionate and encourage the child to be harmonious and patriotic through spiritual epic works in the education of future generations. They describe the noble pedagogical ideas, the centuries-old wisdom of our people, the qualities of intelligence.*

**Keywords:** *spiritual values; education; epic; spiritual treasure; folk history.*

Духовное наследие от старшего поколения к потомкам, наше вечное неиссякаемое сокровище, наше сокровище - устные народные произведения. Народная школа в воспитании молодого поколения. Роль эпических произведений в воспитании народных ценностей для будущих, обладающих здравым смыслом, нравственности, доброты и логическим мышлением, сохраняющими ясность, чистоту и вечность языка. Воспитание имеет большое значение для умов, накопленных на протяжении веков нации. Долгая жизнь человечества на протяжении веков означает цель, сущность в жизни личности, прошлое, будущее, литература, культура, воспитание, всестороннее развитие, забота за ребенком, развитие, направление, адаптированное к обществу. Основная функция человеческого общества-воспитание. Это передача духовных богатств и материальных ценностей от предков к потомкам посредством воспитания. Наследие, переданное следующему поколению, дает материальную устойчивость, основанную на критических взглядах на воспитание в семье, дошкольном образовании, школе и в студенческие годы. Несмотря на то, что кыргызский народ издревле думал о будущем своего поколения и жил кочевым образом жизни, воспитывая ребенка в соответствии с законодательством Кыргызской Республики, он воспитывал нравственные, скромные, гуманные, добрые, патриотические, нравственные качества, любовь к народу, согласие, крепкую дружбу. На протяжении тысячелетий народ в национальном воспитании и популяризации молодого поколения устное народное творчество было основным источником воспитания, а эпические произведения-ядром воспитания. Внутреннее содержание, основные идеи эпических произведений раскрывают развитие событий, действия, образы, личности персонажей, излагают события в жизненных ситуациях, передаются заветные желания потомкам, старшее воспитание является средством педагогики, воспитывающей молодое поколение. История кыргызского народа и знания по воспитанию поколений взаимосвязаны и глубоко укоренились в истории человеческой культуры и литературы. Еще до того, как была создана письменная литература, наш народ был искусным народом, устно сохранявшим необходимые знания, знания о воспитании потомков через старшие поколения в искусстве

художественного самовыражения. Сущность, истоки основных понятий, связанных с содержанием воспитания ребенка, уходят корнями в давние времена, историю народа. В сокровищнице воспитания детей хранятся образцовые уроки жизни предков. Эпические произведения играют большую роль в воспитании нравственных, честных, стойких, терпеливых, формировании умственной интуиции, развитии логического мышления, овладении народным искусством, воспитании подлинного человека. Принимая во внимание, что традиционная педагогическая идея, система воспитательных практик — это духовные ценности, встречающиеся в сказках, легендах, баснях, рассказах, романах. Феномен, включающий в воспитание подрастающего поколения, систему образования закваску мысли, веры, народную практическую, народную педагогическую деятельность.

В истории народа есть задача сохранить чистоту, святость, вечность родного языка. Наследие предков, средства воспитания, сказки, выражающие взаимосвязь духовного мира молодого поколения ,отношение к природе, к внешней природной среде, басни, легенды ,связанные с природой и знанием животных, волшебные сказки, связанные с обычной жизнью, рассказы, наполненные неисчислимыми размышлениями, рассказы с подробным описанием человеческой жизни, романы, подробно описывающие жизнь человека, жизнь человеческого общества, эпос "Манас", океан духовного мира нашего народа, эпос "Манас" являются примерами основных народных дисциплин в воспитании подрастающего поколения.

Например, великий русский педагог К.Д. Ушинский: "сказки-самое раннее новшество народной педагогики. Таким образом, никто не может сравниться с педагогическим гением народа". [1, с. 33] духовные богатства народной культуры, сказочные слова всегда творчески живут в сознании ребенка. Сказка-кладезь мудрости, школы воспитания, духовного наследия народа, укоренившаяся в смысловом смысле под понятием народное воспитание. он великий педагог века В.А.Сухомлинский также говорит, что сказки-это "духовное достояние народной культуры, когда ребенок осознает сказку и всматривается в жизнь народа"[1, с. 35] такие удивительные сказки, как "Мальчик и Волшебник"," Волшебная сака", "Золотая рыбка","мудрый ребенок", "Золотая птица", "Ребенок-сирота", "Мальчик-царь", учат ребенка быть трудолюбивым, образованным и дорожить своими родителями. Например, в сказке "Мальчик и Волшебник" давным-давно мальчик был единственным сыном старика, из-за нехватки, старик искала место, чтобы пристроить своего сына, и вот в один день он встречает волшебника, говоря ему:

-Мы голодаем и, хотя бы, чтобы мой сынок не умер сголоду, ходим с ним по разным местам

- Хорошо, отдай мне своего ребенка. Позволь мне научить, вы приедете в это время в следующем году! - говорит волшебник. Его держали на расстоянии одной руки, и, как только он схватил ребенка, они оба ушли из поля зрения. [7, с. 73]. Старик приезжает каждый год в течение шести лет и не знает своего сына. Потому что волшебник-то превращает юношу в чёрную кошку, то в лису, то в красивого мустанга-старается не передать сына отцу. Умный ребенок, который учится искусству, побеждает волшебника с мудростью и служит своим родителям. Будущее ребенка в сказке, судьба, связанное с воспитанием потомков, воспитанием, которое преодолевает жадность, воспитывается в мужестве, чести, любви к родителям, служении народу, трудолюбии. Легенды-одно из самых ценных сокровищ, которые наши предки унаследовали от своих потомков сегодня. Исторические повествования об исторических личностях, исторических событиях, явлениях, происходящих на основе событий жизни, ближе к истине о происхождении названий земли и воды. "Различные явления древнего человека, природы, законы преображения, возникновения животного мира объяснялись фантастическими рассуждениями"[8, с. 533].

В кыргызском фольклоре "дочь Уркара пушистая красавица","Тоотай охотник и три аркара","мать-олень","девушка на Луне", "Джети-Огуз". Есть легенды, такие как "Легенда о хлебе". "Легенда о хлебе" давным-давно называлась мельница. Хлеб выпекался сам по себе. Дети, привыкшие к праздности, делали из хлеба мячи, играли в них, иногда топили в грязь. Это возмутило бы всех зерновых. Пшеница рекомендует в один прекрасный день собрать все

зерна и отправиться куда-нибудь, где их никто не увидит. Все соглашаются и говорят, что пойдем к озеру и пойдем на дно воды. Непослушные дети просыпаются ото сна и ничего не находят в кладовой с хлебом. Тогда бабушка детей:

- Этого бы не случилось, если бы вы не игрались с хлебом. «А теперь найдите хлеб», — говорит она [4, с. 34].

Когда их просят совета у дедушек, они сердито жалуются. В этот момент голубой холм преследует сбежавшие зерна и сохраняет пригоршню зерен. С тех пор люди стали заниматься сельским хозяйством, чтобы делать хлеб из муки. Они бережно сохранили хлеб, не допустили его расточительства. От этого молодое поколение будет трудоустроено.

Басня-самая древняя литературная форма. Произведения проповеднического значения, написанные в форме стихов, а иногда и в форме прозы, украшенные аллегорическими образами. Басни в устной форме издал великий поэт кыргызского народа Т. Молдо превратил его в свои оригинальные произведения. Например, в одной из басни:

- Зимний мороз,
Я вою, не подавляя голоса.
Это не о прогулке,
Эта работа не для меня.
Если весна веселая,
Давай, помещик, буду тебе служить.
Возвращение к богатству,
Позвольте мне надеть одно пальто- собака, которая замерзает на морозе, ждет весны [9, с. 436]. С наступлением весны Чепмен выходит из головы, опускает язык и прячется в тени. "Хлеб труда сладок, душа ленивого сладка" - может быть, не пословица. При этом ребенка воспитывают на честный труд, а не на лень. Жизненное событие, описанное в этой басне, образно изображает характер ленивых, тщеславных, уклоняющихся от труда и не уставших от обещаний.

Богатая великими педагогическими ценностями, энциклопедия Кыргызской жизни, история, наследие, вершина кыргызского духа эпос "Манас" считается феноменом уникального народного воспитания, который является сокровищницей богатств в воспитании молодого поколения, сокровищницей ценностей, сохранением кыргызского народа как нации и отданием его потомкам старшего поколения как священного Табера. Эпос-неиссякаемая, нескончаемая духовная держава нашего народа. Педагогические национальные ценности в эпосе начинались с вопля и вопля Иакова хана до рождения Манаса, и эти ценности стали центральной идеей эпоса. Эпос богат наследием, национальными духовными ценностями.

Жакып:
Владелец мира-ребенок,
Когда за тобой нет ребенка,
Построить свой мир,
Это был разрушенный город. [5, с. 149]. Жизнь человеческого общества не зависит от богатства, власти, карьеры, человек зависит от рода, от того, чтобы быть преемником, чтобы оставить след, от того, чтобы люди жили как люди. Интересно также воспитание Манаса. Воспитывая ребенка, чтобы он был трудолюбивым, гуманным, патриотичным, любящим Родину, отдает в Ошпур очень озорного ребенка, чтобы он стал ребенком, обученным в животноводстве, закаленным в горечи и горечи жизни. Он говорит: "дабы он был близок к тому, чтобы говорить, чтобы кости его созрели, чтобы он знал цену скота и богатства". Это слово относится к умственному развитию молодого поколения, становлению человеком в традиционной Малании народа. Манас с детства привил качества храбрости, героизма, гуманности, чести и прощения. Приехав на Алтай, мы высоко ценим любовь, святое чувство места рождения, ностальгию, честь, великодушие, единство и мир народа. Поколения, следующие за эпосом, будут воспитаны великодушными, гуманными, снисходительными, сохраняющими внутреннее единство, выходящее из одного воротника и одного рукава.

Мастер художественного слова, выдающаяся духовная гордость человеческой жизни, великий символ кыргызского народа, духовная Вера, провозглашает во всем мире имя кыргызского лотоса, является гигантом Вселенной. Творчество Айтматова тоже берет свое начало в эпических произведениях, начиная с эпоса" Манас". Воспитательные уроки произведений Айтматова многогранны и глубоки. Человек, который читает произведения великана с педагогической точки зрения, является мудрым учителем, наставником человечества в каждом из его рассказов, романов. Можно ощутить живой импульс чаяний и переживаний Айтматова, направленных на то, чтобы сделать человека человеком. По образцу тиражных идей произведений писателя тысячи читателей усвоили духовный урок и изменили мировоззрение. В основе многообразия художественного мышления, будь то произведения искусства, статьи и интервью мастера, лежат фольклорные духовные богатства, глубоко укоренившиеся в национальной истории. Исследование творческой уникальности, человеческого величия, силы великого писателя, решение общечеловеческой проблемы. По своему социальному мотиву, идейной содержанию, повесть "Белый пароход" можно назвать педагогической. Повествование— это произведение, четко написанное в политико-социальном плане. Сюжетная линия повести" Белый пароход" переплетается с такими идеями, как мир мальчика, воспитанного под влиянием воспитательной программы верующего, борьба трагических снов против нечистоты и злости. Скромный народный педагог, представляется последним представителем народной педагогики. Он посеял в душу ребенка благородные зерна целомудрия и нравственности через могущественные добродетели сказки. Он не принял нечистоту и беззаконие, потому что его душа была лишена сказок, унаследованных от старшего поколения. Оставив урок справедливости, целомудрия живым, он погрузился в воду с чистым детским чувством, чистым сердцем. Из произведений великого писателя, проповедующего человечеству о славе, высоте человека, доброй совести, нравственности, молодое поколение воспитывается в патриотизме, святом соблюдении имени человечности, нравственности.

Итак, в заключение, эпические произведения — это мощное, вечное духовное сокровище художественного самовыражения, которое вдохновляет на высокие идеалы человечности в воспитании ребенка. Сохранились жемчужины слов, которые ценят произведения искусства. Воспитательная значимость мыслей народа, благородные пожелания в эпических произведениях, обладающих высшими личностными качествами, великое воспитание является педагогическим средством воспитания подрастающего поколения.

## Литература


1. Алимбеков А. «Художественно-педагогические концепции произведений Айтматова (Научная статья), 2009. – С. 48-52.
2. Айтматов. Ч. Мы изменяем мир, мир изменяет нас: ст. интервью, выступления / Чингиз Айтматов; сост. С. Тургунбаев. - Фрунзе: Кыргызстан, 1988. - 399 с.
3. Собрание сочинений: В 7 т. / Чингиз Айтматов; [Сост. и ред. собр. соч. Р. Рахманалиев; Ин-т мировой лит. Рос. акад. наук, Междунар. калифорн. акад. искусств [и др.]. - М.; Бишкек: Туркестан, 1998.
4. Абдалиева. Г.К. «Дай мне знать», 2017. – 160 с.
5. Асанбекова. Н.Эпос «Манас — это эпос кыргызской истории, языка, культуры источник», 2017. – 240с.
6. Книга «Детский фольклор», 1998. – 320 с.
7. Книга «Кыргызские народные сказки», 2016. – 380 с.
8. Книга «История кыргызкой литературы», 1 том. - 2004. - 616 с.
9. Книга «Антология Кыргызской поэзии», 1981. – 400 с.
10. Максутов.Т. Ильхабеков.А. «Основы национальной педагогики» 1996. – 240 с.
11. Укубаева Л. «Художественный мир персонажей Айтматова», 2008. – 1208 с.

УДК 821.512.145

# ОБРАЗ КОНЯ В СОВРЕМЕННОЙ ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЕ
# АТ ЯЗМЫШЫ – ИЛ ЯЗМЫШЫ (ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА АТ ОБРАЗЫ)

***Мансурова Зульфия Ямиловна***
МБОУ «Каранская СОШ», Буздяк,
Республика Башкортстан, Российская Федерация
*e-mail: man.zul2014@yandex.ru*

**Аннотация**. *В данной статье рассматривается образ лошади в современной татарской литературе, изучение роли и значения коня в развитии и становлении героев.*
**Ключевые слова:** *образы; типизация; эпическое повествование; психологизм; системность.*

# THE IMAGE OF A HORSE IN MODERN TATAR LITERATURE

***Mansurova Zulfiya Yamilovna***
MBEI «Karanskaya secondary school»,
Buzdyak, Republic of Bashkortstan, Russian Federation

**Abstract**. *This article examines the image of a horse in modern Tatar literature, the study of the role and significance of a horse in the development and formation of heroes.*
**Keywords**: *images; typification; epic narrative; psychologism; consistency.*

Ат – безнең төрки халкыбызның тугры юлдашы, гомумән, безнең яшәешебез аның белән аерылгысыз бәйләнгән. Ат образы, ат культы кардәш төрки халыкларның да рухи мәдәниятләрендә үзәк урын биләп тора. Ат борынгыдан килгән төрки дастаннарда төп каһарманның аерылгысыз юлдашы. Бәйгеләр, бәйрәмнәр, йолалар атсыз узмаган. Ат белән бәйле күп төрле ышанулар, йолалар татар тормышында зур урын тоткан. Борын-борыннан халкыбыз атка изге хайван дип караган, аны үзенең иң якын дусты, уң канаты дип санаган. Европа илләрендә ат иң бай кешеләрдә булса гына, безнең төрки бабаларыбызның ул тормыш таләбе булган. Көнкүреш - яшәешне атсыз күз алдына китерергә дә мөмкин түгел. Кырда, өйдә, төрле күңел ачу бәйрәмнәрендә дә ат мөһим рольне уйнаган. Милли йолаларыбыз чагылдырылган Ә.Еникинең “Җиз кыңгырау” әсәрендә дә туй күренеше, кунакка йөрү, килен алып кайту җигелгән атларда бара. Хәтта татар халкының милли бәйрәме – Сабантуй да ат чабышларыннан башланып киткән һәм бу традиция әлеге көнгәчә дәвам итә. Атларның кешегә китергән файдасын бизмәнгә салып кына үлчәрлек түгелдер, мөгаен. Башка йорт хайваннары белән чагыштырганда, кеше тормышында аларның роле бигрәк зур. Тарих битләренә данлыклы атларның кушаматлары алтын хәрефләр белән язылган: Александар Македонскийның – Буцефалы, Наполеон Бонапартның – Маренгосы, Бөек Фридрихның – Конде кушаматлы аты. Мөхәммәт пәйгамбәрне Мәдинә шәһәреннән Иерусалимга алып баручы легендар ат Бурак кушаматлы булган. Ат образы халык авыз иҗатында да зур урын алып тора. Күп санлы мәкальләр, легендалар, җырлар шул хакта сөйли.

Татар әдәбиятына килгәндә, Г.Ибраһимовның “Алмачуар” хикәясе, Г.Тукайның “Пар ат” поэмасы, И.Юзеевның “Йолдыз кашка турында баллада”сы, М.Галиевнең “Ат рухы”, А.Хәлимнең “Өч аяклы ат” әсәрләре дә язучыларыбыз бу образга битараф булмаулары хакында сөйли. Күз алдыбызга иксез-чиксез болыннарда утлап йөргән атлар, шул атларны кичкырын сакларга чыккан малайлар, янып торган учак күз алдына килә. Ул гына түгел, ирексездән, авыз эченнән генә “ниләр генә күрми бу дөньяда ир-егеткәй белән ат башы”, дип көйли башлыйсың. Бу әсәрләр үткән гасырда калса да, алар атка мәдхия җыры булып яңгырый.

XX гасыр азагы – XXI гасыр башында ат образы традицион героик-романтик яссылыкта буыннар, шәхес язмышы белән бәйләнештә ачылу белән бергә фәнни-техник революция тудырган рухи-әхлакый югалтулар яссылыгында яңача сурәтләнә башлады. Ат язмышы ил язмышы символына әверелде. Ат һәм башка йорт-кура малы үзләрендә халык язмышын, кеше һәм табигать мөнәсәбәтләрен гәүдәләндерде [ 1, б. 33].

Татар язучысы өчен кешелек һәм табигать дөньясының бәйләнеше аерылгысыз. Язучылык эшенә соң гына керешүеннән карамастан, бүгенге көн татар әдәбияты мәйданында үз урынын тапкан, үз аудиториясын булдырган Хисаметдин Исмәгыйлев иҗатына күз салсак, югарыда әйтеп киткән фикерләрем бик урынлы. Беренче тапкыр Хисаметдин Исмәгыйлевның иҗаты белән танышуым “Тулпар” журналы аша, “Ат һәм без” повесте булды. Эчтәлеге буенча, автор үзе билгеләмәсә дә, мин автобиографик повесть дип әйтер идем. “Ат...Ике хәрефтән генә торган гап-гади сүз. Барлыгы ике хәреф. Һәм бу сүз берничә төрле мәгънәгә ия”, – дип башлый автор үзенең әсәрен [5, б. 4]. Повестьта Х.Исмәгыйлев ат сүзенә иң беренче чиратта тирән мәгънә салып куя. Авыл хуҗалыгында хайваннар күп булуына карамастан, ул “Миңа ат кадерлерәк”, – ди [5, б. 4].

Төп герой (автор үзе) безне 60нчы елларга алып китә. Авыл һәм урман хуҗалыгында барган вакыйгалар безне төрле кешеләр белән очраштыра. Геройның әтиссе Шәрәфи авыл Советы рәисе булып эшли. Бик итагатьле, тырыш һәм кешелекле кеше. Бервакыт урманда рөхсәтсез агачлар киселә. Акт төзиләр, акт буенча берникадәр штраф тиеш була. Тик икейөзле кешеләр актны үзгәртеп, биш төп урынына унбиш төп дип үзгәртеп куялар. Урман түрәсе үзе үк урман кистереп, барча булган гаепне күрше колхоз рәисе өстенә тагарга уйлаган була. Шәрәфинең үткенлеге һәм игътибарлылыгы аркасында, кеше гомере сакланып кала. Ләкин шушы кешлеклеге аны һәм аның гаиләсен бик озак эзәрлеклэп бара, автор үзе әйтмешли “нужа күрүләре” яңа гына башлана [5, б. 7].

Авыл җирендә мал азыгы әзерләсәң дә, чүп түгәргәме, яки күрше авылга барып килүме – иң мөһим транспорт булып ат санала. Шәрәфи дә беркөнне аксак булса да ат алып кайта. “Чатанласа да ат, ат инде” [ 5, б. 9]. Автор авыл җирендә яшәвенең бөтен матурылыгын да, авырлыгын да шушы ат образы аша безгә китереп җиткерә алган. “Татра” кушаматлы ат машинадан да кадерлерәк була ул вакытта. Ул кушаматны да юкка гына бирмиләр, “атның галәмәт көчле һәм акыллы булуын (безнең бригадта андый гәүдәле һәм көчле ат юк та иде әле) исәпкә алып, “Татра” дип исем куштык” [5, б. 10]. Бу кушаматта ниндидер яшерен мәгънә дә салынган кебек. Әгәр хәрефләрнең урынын алыштырсак, Татар дигән исем килеп чыга. Бу халкыбызның ат кебек эшчән, тугры, тырыш кебек сыйфатларны үз эченә алган символик образ булып тора.

Атлы кешенең эше күбәйсә дә, дөнья көтүе дә бераз җиңеләя. Урман аланында төп геройның әтисе белән бергәләп печән чабу мизгелләре, печән чабуның тәме, тирә-яктагы кошлар сайравының моңы, үлән арасында сибелеп калган кып-кызыл җир җиләкләре дә, әлбәттә, ат белән бәйле. Чөнки авыл агаеның авыр хезмәтенә нигезләнгән яхшы, мул, имин тормышны, бәхетле тормышны да аттан башка күз алдына китереп булмый. Печән чабулар, атка утырып җырлы-җырлый кайтулар, кичен ат саклаулар, атлы кешедән авылдашларының көнләшүе – барысы да әсәрдә чагылыш таба. Беркөнне атлары Шәрәфиләрнең югала. Эзли торгач, күрше авылда казакъларда табалар. Алар “чегәннәр урлап китеп барганда, ташлап калдырдылар”, – дип алдаша. Еллар үткәч кенә урман кисеп байый алмаган урман хуҗасының үч алу нияте белән эшләнгән икәне билгеле була.

Әсәрдә ат образы янындагы барган вакыйгалар безгә гореф-гадәтләрне генә түгел, шул чорда барган совет хакимиятенең гади халыкка булган мөнәсәбәтләрен, налог җыюлар, гади халык ничек булса да рәхәт яшәмәсен дигән кебек, мал исәбен алулар, артык булса, колхоз абзарына төшерүләр тасвирланган. “Шәрәфи законсыз ат асрый. Атын гомум хуҗалык файдасына тартып алырга” дигән карар чыгарып, эзәрлекләүләрен дәвам итәләр. Сугыш ветераны булган, инвалид Шәрәфи гаепсезгә гаепле булып, авыр вакытлар кичерә. Һәр җыелышта куркыныч җинаятьче кебек эшен тикшерәләр, янәсе “законсыз ат асрый”. Атын бирмәгән өчен “Шәрәфигә баллонлы газ бирмәскә”, “электр чыбыгын өзергә”, “морҗа төбенә

кадәр тикшерәләр” [5, б. 13]. Шәрәфи абыйга “партбилетыңны өстәлгә куй” дигәндә дә ул үзенең тугры дусыннан ваз кичми. Шушы юлларны укыганда сорау туа: ни өчен шулкадәр эзәрлекләүләргә дә түзеп, атыннан баш тартмый ул? Чөнки аты башка бик күп татар халкының тамагын туйдыручы, эшчәнлек, җаваплылык, тугрылык кебек сыйфатларны булдыручы. Шәрәфи карт та, аның улы да (автор үзе) атның кадерен белә. Әсәрдән күрүебезчә, кешелек дөньясы бер генә түгел, икейөзлеләргә дә, намуслы кешеләргә бүленгән. Алар арасында һәрвакыт көрәш. Шушы әсәр аша үзенең идеалларына ышанган Шәрәфи карт кара эчле кешеләр алдында көчле булуын, балаларын да дөрес итеп тәрбияләвендә күрәбез. Автор ачынып, “Соңгы вакытларда ат асраучылар бетте. Яшьләр ялкауланды. Яшьләр авылда калмый”, – дип яза. Димәк, ат образы – ул безнең үткәнебез һәм бүгенгесе белән бәйләнеш. Автор үзенең әтисе һәм аты “Татра” белән ул халкыбызның аянычлы хәленә, авылыбызның бетүенә ишарә ясый.

Ат образы Айгөл Әхмәтгалиеваның “Ул югалмады” хикәсендә икенче яссылыкта ачыла. Аның әсәрләрен укый башласаң, җырлап торган сөйләме үзенә тарта. Аның әдәби телендә Фатих Хөсни аһәңнәре яңгырап китә. Әмма бу – лиро-эпик тел, нәсер, шигъри проза теле түгел. Матур әдәби телне заманча хәрәкәттәге тормыш вакыйгаларын тергезү белән куша алган эпик хикәяләү бу. Урынлы һәм уйлап сайланган һәр сүз тирәлекнең матур сурәтен тудыра, шул сурәт күз алдына килеп, сине олы җанлы, матур күңелле кешеләр дөньясына алып кереп тә китә. “Ул әле югалмады” хикәясе бүгенге тормышка хас булган актуаль проблемаларны үз эченә алып тасвирлаган әсәрләрнең берсе. Гаилә кыйммәтләре, эчкечелек, хатын-кызның гаиләдәге роле, ана һәм бала мөнәсәбәләре бик ачык чагылган. Язучы әсәрдә дөньяда булган вакыйгаларны гомумиләштереп, образларны типиклаштырып, геройларга исем дә бирмәгән. Без бары тик тормышны сөйрәргә тырышкан әтине, исерек әнине һәм кечкенә генә булуына карамастан, дөньяның ачысын-төчесен татыган малайны күрәбез. Малайның тугры дусты аның аты – Карлыгач. Бөтен уйларын, кайгы-хәсрәтләрен, мәктәптәге хәлләрне атына сөйли малай. “Әле дә син бар, Карлыгач”, – дип әйтеп куя малай [2, б. 198]. Аты Карлыгач, малайны кызганудан: “Мин нишли алам?” – дигән сыман күзләрен тутырып карый гына ала [2, б. 197]. Айгөл Әхмәтвәлиева бала күңеленеңниләр кичергәнен ат образы аша китереп җиткерә. Шушы юлларны укыганда, шундый сабые була торып, ана булган кешенең тормыш баткаклыгына тәгәрәвенең сәбәбен эзлисең, йөрәкнең иң нечкә кылларына ук кагылып, баланың киләчәктә бәхетеле булуын, ананың туры юлга басуын тели башлыйсың.

Автор милләтебезнең йөзек кашы булган Сабантуй бәйрәмен дә читтә калдырмый, ат образы булган әсәрдә ул һичшиксез булырга тиеш итеп кабул ителә. Малайның “Әни, син эчмә!Әни, китмә!”, – дип өзгәләнүләре ат чабышы вакытында Карлыгачның тояк тавышларына үрелеп бара. Малайның тырышуы бушка китми, әнисенә вәгъдә иткән бүләген дә ота. Ләкин әнисе генә һаман эчкелек баткаклыгыннан чыгу юлын тапмый. Кешенең табигате шундыйдыр күрәсең, үлем белән йөзгә йөз очрашмыйча, аның якынлыгын тоймыйча, ал-ялны белми ялган кыйммәтләргә табынып яшәүдән тартынмаган ана кешене менә шул кискен фаҗига генә айнытып җибәрә. Улы үлемнән калгач кына, әни кеше акылына килә.

Бу әсәрдә малай үзенең тирә-ягында кешеләргә ышанычын югалтканда табигать җаны – атта таба. Язучы монда образларны паралель куеп сурәтләп, бик уңышлы килеп чыккан дип әйтә алабыз.

Айгөлнең Әхмәтгалиеваның сөйләм теле шулкадәр йөгерек һәм сыгылмалы – кызганудан күзләрдән яшьләр килә, кеше күңеленең олылыгына карата горурлык уяна – хисләр бәйләме кичерәсең. Әмма, тормыш нинди генә авырлыклар китерсә дә, бәхетле, шөкер итеп яшәгән кешеләр тарихының ышандыру көче зур түгел. Әкиятләрдәгечә уңай һәм тискәрегә аерылган геройлар, шушы ак һәм карага бүлеп бәяләнгән дөнья схематик тоела. Нәтиҗәдә, төп геройларга карата кулланылган психологизм, укучыны көчле кичерешләргә дучар итә. Психологизм да, фәлсәфә дә, иҗтимагый-сәяси бәя дә бер үремтәдә килеп, әсәрне көчле бер әдәби яңгырашка алып чыга: аны кат-кат укырлык әсәр ясый.

Сүзне йомгаклап, шуны әйтәсе килә: XX гасырның икенче яртысында башланган техник революция атның тормышыбыздагы ролен бик нык кыскартты. Ат хәзер безнең тормышта бер

экзотик җан иясе дәрәҗәсенә төште. Хәзер атны авылларда да бер күрергә зар булырсың. Дөресен әйткәндә, без үзебезне кеше иткән тарихи юлдашыбызны ташладык. Ләкин менә югарыда әйтеп үткән язучыларыбызның әсәрләре шуны исбат итә: ат образы яңадан үзенең ролен үти башлады, аңа рухи халәтебезнең үзеннән килеп чыккан яңа мәгънә салынды.

**Әдәбият**


1. Әмиров Р.К. “Җиктереп пар ат...” Тукай иҗаты һәм Башкортстандагы татар шигърияте // Тулпар. – 2012. - № 6. – Б.32-35.
2. Әхмәтгалиева А.Г. Кичке таң: повестьлар, хикәяләр. – Казан: “Идел-Пресс” нәшр., 2020. – 224 б.
3. Булатова Д. Язучының күңел дәфтәреннән.// Тулпар. – 2019. – №.6. – Б.22-25.
4. Заһидуллина Д. Ак читек // http://www.xn--80aaa0anjn0apj6g.xn--p1ai/news/jehet-tenkyjt/ajgol-ehmetgalieva-ak-chitek
5. Исмәгыйлев Х.Ш. Ат һәм без.// Тулпар. – 2018. – № 2. – Б.4-23.
6. Сәгыйдуллина Л.Р. Мифны җимерүче роман. //Тулпар. – 2018. – №5. – Б. 32-33.



УДК 821.512.145


## ИСЛАМ ДИНЕ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ


***Миннегулов Хатип Юсупович***
Институт филологии и межкультурной коммуникации Казанского (Приволжского) федерального университета, г. Казань, Татарстан, Российская Федерация
*e-mail: metodika.ksu@mail.ru*



**Аннотация**. *В статье Х. Ю. Миннегулова кратко освещается длительный процесс проникновения и распространения ислама в Поволжье и Приуралье, среди предков современных татар, выявляются его место и роль в судьбы многовековой истории татарской литературы. Имеются также высказывания о характере использования коранических сюжетов, мотивов, образов в творчестве отдельных писателей.*



**Ключевые слова:** *религия; «Коран»; татары (хазары, болгары, кипчаки); история татарской литературы; классика Востока.*


## ISLAM AND TATAR LITERATURE


***Minnegulov Hatip Yusupovich***
Institute of Philology and Intercultural Communication of Kazan (Volga Region) Federal University, Kazan, Tatarstan, Russian Federation



**Abstract.** *The article by H. Y. Minnegulov briefly highlights the long process of penetration and spread of Islam in the Volga region and the Urals, among the ancestors of modern Tatars, reveals its place and role in the fate of the centuries-old history of Tatar literature. There are also statements about the nature of the use of Quranic plots, motifs, images in the works of individual writers.*



**Keywords:** *religion; "Koran"; Tatars (Khazars, Bulgarians, Kipchaks); history of Tatar literature; classics of the East.*


Әлеге язмага исем итеп куелган тема гаять зур һәм киң. Аңа мөнәсәбәтле чыганаклар һәм хезмәтләр дә шактый гына. Без фәкыйрегез дә бу мәсьәләләр белән күптәннән кызыксынып килә. Безнең хезмәтләрдә, аеруча “Татарская литература и Восточная классика (Вопросы взаимосвязей и поэтики)” монографиясендә, IX, X сыйныфлар өчен язылган әдәбият

дәреслекләрендә (1994, 1998, 2005,...; 1996, 2000, 2006) меселман дине һәм аның татар сүз сәнгате белән багланышлары хакында күп төрле факт-мәгълүматлар, күзәтү-фикерләр урын алган. Шулай ук Хатыйп Йосыф угылының әлеге теманы махсус яктырткан берничә мәкалә-язмасы да бар [4,5,6]. Шуңа күрә без бу язмабызда куелган проблеманың тик кайбер якларына кыскача гына тукталып китәрбез.

Кешелек тарихында мәҗүсилек, буддизм, зәрдәшт (зороастризм), яһүди, манихей, христиан, тәңречелек һәм кайбер башка диннәрнең яшәве мәгълүм. Аларның туу, кулланылу вакытлары, таралу урыннары да төрле. Бер өлеше билгеле бер чорда, аерым төбәкләрдә гамәлдә йөргәннән соң, тарих сәхнәсеннән төшеп кала, икенчеләре гаять киң таралыш табып, меңәр еллар буе яшәвен, кулланылуын дәвам итә. Әнә шундый диннәрнең берсе — ислам. Мәгълүм ки, ул VII гасыр башларында Гарәп ярымутравында оешып, тиз арада күп кенә җирләргә (илләрдә, халыкларда, кыйтгаларда) таралып, хәзерге вакытта ике миллиардка якын кешене (ягъни дөнья халкының чиреген) үз эченә ала, берничә дистә мәмләкәттә рәсми дәүләт дине булып хисаплана.

Ислам, — кайбер башка диннәр кебек, яшәешнең, рухи һәм иҗтимагый тормышның төрле күренешләрен теге яки бу дәрәҗәдә үз эченә алган, җәмгыять белән тыгыз бәйләнешле идеологик система, тәгълимат. Аның төп асылын Алланың барлыгын һәм берлеген тану, Мөхәммәд пәйгамбәрнең “рәсүл”легенә иман-ышаныч тәшкил итә. “Коръән” рухи яшәешнең нигезе итеп хисаплана.

Яңа эрага кадәр үк тарих мәйданына чыгып,дөньяга үз сүзен ишеттергән, үзенең барлыгын таныткан татар кавеве — әби-бабаларыбыз соңгы ике меңъеллыкта гаять катлаулы, каршылыклы, данлы да, фаҗигале дә юллар үтеп, дистәләгән дәүләтләр төзеп, бер-бер артлы аларны югалтып гомер кичергән. Тормышның төрле сәбәпләре аркасында аларның шактый өлеше күченгән, яшәү урыннарын алыштырган. Шуның нәтиҗәсе буларак, Ерак Шәрыктан Дунай-Балкангача сузылган гаять зур мәйданнарда һәм гомумән Евразия тарихында татар тирән эз калдырган. Гасырлар агышында әкренләп Идел-Урал, Идел-йорт аның төп яшәү урынына әверелгән.

Шунысы мөһим: безнең әби-бабаларыбыз катлаулы язмыш кичереп, төрле этник үзгәрешләргә дучар ителсә дә, аның табигатенә — татар-төркилегенә тугры калган.

Халкыбыз, аның составына кергән этник төркемнәр үзләренең күпгасырлык яшәү дәверендә, чорына һәм җирлегенә карап, иман-ышанычның төрле формаларын үз иткәннәр. Борынгырак чорда аеруча мәҗүсилек, бераздан тәңречелек чагыштырмача киң тарала. Будда, яһүди, зәрдәшт, христиан һәм кайбер башка диннәрне тотучылар да була. Әмма бездә иң киң таралганы — ислам. Халкыбызның мең елдан артык тарихы, тереклеге мөселман дине белән аерылгысыз бәйләнгән. Ул татарның даими юлдашына, ышанычлы, тотрыклы таянычына әйләнеп, аның бөтен күзәнәкләренә сеңгән, бар вөҗүден сугарган. Халкыбызның соңгы мең елдан артык тереклеген, рухи дөньясын мөселман диненнән башка гомумән күз алдына да китереп булмый.

Еш кына Идел-йортта исламның кабул ителешен, тарала башлавын 922 елдагы мәгълүм вакыйга-хәлләр белән бәйләп кенә карыйлар. Билгеле ки, шушы елда Багдад хәлифе Идел-йортка составында Ибне Фадлан да булган зур делегация җибәрә. Болгар ханы Алмуш гарәп илчеләре катнашында тантаналы рәвештә мөселман динен рәсми төстә кабул итә. Бу — тарихи яктан дөрес, реаль факт. Әмма ул шактый гына ачыклык кертүне сорый.

Тарихи чыганаклар, аерым фәнни хезмәтләр Коръән тәгълиматының Мөхәммәд пәйгамбәрдән (570-632) соңгы тәүге хәлифәләр чорында, ягъни VII гасырның урталарында һәм икенче яртысында ук Идел-йортка керә башлавын күрсәтәләр. Мәгълүм ки. безнең әби-бабаларыбыз элек-электән үк гарәпләр һәм мөселман дине орбитасына кергән Иран, Урта һәм Үзәк Азия, Кафказ халыклары, шулай ук кайбер башка кавемнәр, төбәкләр белән сәүдә, мәгърифәти, иҗтимагый-сәяси мөнәсәбәтләрдә торганнар. Бер-берсенә килеп-китүчеләрнең дә шактый булуы билгеле.

Хәзәрләр, болгар, кыпчак, татар, кимәк һәм кайбер башка кавемнәр кебек, татарлар составындагы бик тә мөһим бер этник компонент. Якынча 632—970 елларда яшәгән Хәзәр

каганлыгы — татар дәүләтчелегенең бик тә әһәмиятле бер баскычы, буыны. Болгар, хәзәр, кыпчак кавемнәренең кардәшлеге, бер-берсе белән керешеп, кушылып китүе бәхәссез хакыйкать. Бу хакта Ш. Мәрҗани, В. Бартольд һәм кайбер башка гыйлем әһелләренең дә кыйммәтле фикерләре бар. Хәзәр каганлыгында ислам киң таралыш таба. Илнең җитәкчелеге 737 елда мөселман динен рәсми рәвештә кабул итә. Идел-йортта бу чорда ук шактый гына мәчет-мәдрәсәләрнең булуы билгеле. Ибне Хәүкаль (X йөз) язуынча, Хәзәр мәмләкәте башкаласы Итилдә генә дә 30 мәчет эшли [5].

Азов буйларында VII гасырның икенче чирегендә һәм урталарында яшәп алган “Бөек Болгар” дәүләтендә дә инде мөселман динен тотучылар була. Урта Иделгә күченгән болгарларда 922 елга кадәр үк ислам дине шактый киң таралыш таба. Гарәп авторы Ибне Рустә X гасыр башларында ук болай язып калдырган: “Большая часть (болгар) исповедует ислам, и есть в их селениях мечети, начальные училища с мудзэнами и имамами” [3].

Кыскасы, халкыбызда мөселман диненең кабул ителешен 922 ел белән генә бәйләү чагыштырмача шартлы. Ул моңа кадәр үк Идел-йортта исламның берничә гасыр буена таралу, кулланылу процессының бер мөһим рәсми акты, баскычы гына. Чынлыкта безнең әби-бабаларыбызның мөселман дине орбитасына керә башлауларына якынча 1400 ел! Шунысын да искә төшереп үтик: ислам динен безнең халкыбыз мәҗбүри төстә, көчләү-кысулар нәтиҗәсендә түгел, үз ихтыярлары белән, ирекле рәвештә кабул иткән.Моңа, бер яктан, күпчелек әби-бабаларыбызның, нигездә, бераллачылыкка өстенлек биргән тәңречелек тарафдарлары булуы ярдәм итсә, икенче яктан, ислам диненең гаҗәеп бай Шәрык әдәбияты, фәлсәфәсе, фәне, мәгарифе белән табигый керешүе, күп кенә гарәп-фарсы рухи кыйммәтләренең синкретик характерда булуы да уңай шартлар тудырган. Хәзәр, Болгар, Дәшти-кыпчак, Алтын Урда мәмләкәтләрендә, татар ханлыкларында динара мөнәсәбәтләрдә толерантлык, вөҗдан иреге булуы да күп нәрсә хакында сөйли.

Дин һәм әдәбиятның үзләренә генә хас хосусиятләре, максат-бурычлары булса да, алар гомумән шактый якын, еш кына үзара керешеп, кушылып та китә. Боларның һәр икесенең дә үзәгендә кеше, аны рухи яктан тәрбияләү, үстерү. Юкка гына мөселман диненең төп китабы — “Коръән” бер үк вакытта дөнья классик әдәбиятының да бөек бер ядкяре итеп хисапланмый. Чөнки анда исламның төп канун-мәсьәләләре, асылы, яшәеш, тормыш турындагы күзаллаулар үтемле тел-стиль, образ-сурәтләр ярдәмендә гәүдәләнеш таба. Шунысын да искә төшерик: бу Изге китапны безнең күп кенә әби-бабаларыбыз оригиналда — гарәп телендә укыган. Аның шактый гына тәфсир-тәрҗемәләре дә бар. Казан ханлыгы чорында ук бу ядкярнең саллы гына татарча нөсхәсе дә барлыкка килә. “Коръән”нең Ногмани, Морад Рәмзи (1855—1934), Муса Бигиев (1875—1949), Батулла һәм кайбер башка милләттәшләребез тарафыннан эшләнгән тәфсир-тәрҗемәләре дә укучыларга билгеле. Бу Изге китап инде менә мең елдан артык безнең әдәбиятыбызны сугарып, азыкландырып, аның асылын, төп үсеш-юнәлешләрен билгеләүдә хәлиткеч факторларның берсе булып тора.

Әдәбиятның төп элементы — сүз, тел. Шуңа да аны еш кына сүз сәнгате дип йөртәләр Моңа кадәр туран (һун), рун, уйгур һәм кайбер башка графикаларны кулланган халкыбыз ислам дине белән бергә гарәп язуын да кабул итә һәм аны соңгы дәверләргә кадәр куллана. Шунысы да гыйбрәтле: эчтәлекләре нинди булуына да карамастан, гарәп графикасындагы язмалар гомумән бездә шактый дәрәҗәдә изгеләштереләләр дә. Аларны кадерсезләү гонаһ та хисаплана. Мөселман тәгълиматының таралуы Идел-йортта, әби-бабаларыбыз арасында гарәп телен өйрәнү, үзләштерү белән бергә бара. Октябрь инкыйлабына кадәр бездә гарәп-фарсыча белү зыялылык, укымышлылыкның төп билгесе итеп тә каралган. Ислам дине, Коръән теле, бераздан фарсы, төрки телләре безгә Шәрык, Мөселман цивилизацияләрен кабул итәргә, үзләштерергә юл ача. Шуның тәэсирендә татар теленә күпләгән гарәп-фарсы сүзләре, шәкел-формалары керә һәм алар гасырлар дәвамында тәмам үзебезнең тел хәзинәсенә әверелә. Бу уңай белән бер хакыйкатьне дә искә төшерү урынлы булыр. Кайвакыт соңгы дәвер укучыларыннан “элеккеге әсәрләрнең теле тиешенчә аңлашылып җитми” дигән сүзләр ишетергә туры килә. Чыннан да болай әйтү өчен билгеле бер нигез бар. Элеккеге авторлар гарәп-фарсы сүзләрен шактый мул кулланалар, хәтта аерым юлларын, әсәрләрен шул телләрдә

дә язып китәләр ((Мәхмүд Болгари, Габдерәхим Утыз Имәни, Шәмседдин Зәки). Әмма шуны хәтергә төшерү зарури: ул каләм әһелләре үз әсәрләрен шул чор аудиториясен күздә тотып иҗат иткәннәр. Ә ул дәвер укучыларының күпчелеге исә иске татар телен, гарәп-фарсыны, “төрки”не яхшы белгән. Кызганыч ки, соңгы гасыр укучыларының төп өлеше ул сыйфатлардан мәхрүм. Хәтта үзенең туган телен — газиз татар телен белмәүчеләр дә арткannan-арта бара.

Ислам диненең әдәбиятка тәэсире Йосыф Баласагунлының “Котадгу белек” (1069), Әхмәд Йүгнәкинең “Һибәтел-хәкаик” (XII) кебек гомумтөрки ядкярләрдә үк күзәтелә. Мәшһүр Әхмәд Ясәви (вафаты 1166 елда), Сөләйман Бакырганый (үлеме 1186 сәнәдә) иҗатлары инде тулысы белән мөселман дине рухында. Авторлар Алланың берлеген, бөеклеген данлыйлар, үз укучыларын “Коръән” тәгълиматы, Мөхәммәд пәйгамбәр өйрәтмәләре нигезендә тәрбияләргә омтылалар.

Мәгълүм ки, ислам кешеләрнең, күп кенә халыкларның рухи кыйммәтләренә, инсаннарның тормыш тәҗрибәсенә таянып туган һәм формалашкан. Каләм әһелләре өчен бу кыйммәтләр таяныч, төп терәк булып хезмәт иткән. Диннең бу төр гуманистик табигатенә мөнәсәбәттә әдипләр үз кавемнәренең, төбәкләрнең дә инсани, әхлакый тәҗрибәсен, идеалларын үз әсәрләренең тукымасына табигый, мантыйкый рәвештә кертеп җибәргәннәр.

Шәрык сүз сәнгатендәге кебек, бездәге күләмлерәк әсәрләр еш кына Аллага, пәйгамбәргә багышлаулар, аларга мактау (“хәмдү-сәналәр”) уку белән башланып китә. Бу Йосыф Баласагунлы, Кол Гали, Котб, Мөхәммәдьяр кебек авторларның поэмаларында ачык күзәтелә.

“Кыйссаи Йосыф”тагы төп сюжетның, образларның “Коръән”нән алынып, автор тарафыннан эшкәртелүе гавамга яхшы таныш. Шушындый ук күренеш кайбер башка әсәрләр өчен дә хас. Мәсәлән, Алтын Урда чоры әдибе Рабгузыйның “Кыйссасел-әнбия” исемле күләмле китабы (1310) тулысы белән диярлек “Коръән”дәге сюжет-кыйссаларга корылган; андагы төп образ персонажларда да дини чыганаклар аркылы укучыларга билгеле.

Урта гасыр һәм XIX йөздәге күпчелек каләм ияләренең эшчәнлеге өчен күпкырлылык, күпвазыйфалылык хас. Алар, әдип-шагыйрь генә түгел, бер үк вакытта дин әһеле, галим, мәгърифәтче һәм җәмәгать эшлеклесе дә. Мәхмүд Болгари (1297—1360), Кол Шәриф (?—1552), Г. Утыз Имәни (1754—1834), Таҗеддин Ялчыгол (1768—1838) һәм башка бик күпләр — моның күркәм мисалы. Шунысы мөһим: алар язган әсәрләр еш кына төрле вазыйфаларны үти. Мәсәлән, ислам динендәге күп кенә гыйбрәтле факт-мәгълүматларны, сюжет-мотивларны, шул исәптән аять-хәдисләрне үз эчләренә алган “Нәһҗел-фәрадис” (1358), “Рисаләи Газизә” (1806) китаплары бер үк вакытта киң катлам укучыларның һәм әдәби-эстетик, һәм дини-әхлакый ихтыяҗларын да канәгатьләндерәләр. Таҗеддин Ялчыгол әсәренең Октябрь инкыйлабына кадәр күп тиражлар белән 40 мәртәбә басылуы, мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укыту әсбабы буларак өйрәнелүе үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли.

Мөселман галәмендә элек-электән Алланы мәдехләгән, “Коръән”не зурлаган, Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормышын һәм эшчәнлеген тасвирлаган күпләгән әсәрләр иҗат ителә. Алар шактый дәрәҗәдә татар укучыларына да таныш була. Мәсәлән, Мөхәммәд Чәләбинең госманлы телендә язылган гаять күләмле “Мөхәммәдия” китабы (1449) безнең әби-бабаларыбыз тарафыннан бик тә яратып укыла. Ул Казанда күп мәртәбәләр басылып чыга. Бу төр язмалар татар дөньясында да шактый иҗат ителә.XIV—XV гасырларга нисбәт ителүче “Кыйссаи авык” дастанының үзәгендә Мөхәммәд пәйгамбәр образы. Аның игелек-шәфкатьлелеге аркасында хәтта тоткынлыкка эләккән ауык-кыр кәҗәсе дә ирекке чыгарыла, балалары белән кавыша.

Әлеге мәкаләбезгә исем итеп куелган проблема хакында сүз барганда, суфыйчылык мәсьәләсе дә үзенә игътибар сорый. Билгеле булганча, Урта гасыр мөселман дөньясында киң таралган, ислам диненең бик тә мөһим бер тармагын, өлкәсен тәшкил иткән бу идеологик күренеш төрки-татарларның иҗтимагый-социаль, аеруча рухи-мәдәни тормышында тирән эз калдырган. Авыр елларда, бигрәк тә милли-колониаль, чукындыру сәясәте котырынган чорларда ул халкыбыз өчен бер рухи терәк, туплану факторы да булып тора. Суфыйчылык белән сугарылган әсәрләрдә адәм баласының эчке дөньясына, уй-кичерешләренә, психологик

халәтенә, иман-ышанычына аеруча игътибар итеклә, теге һәм бу дөнья мөнәсәбәтләре, яшәү мәгънәсе, үз-үзеңне әхлакый һәм инсани яктан камилләштерү, байлыкка, хакимияткә кызыкмау кебек мәсьәләләр үзәккә куела. Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакырганый, Хисам Кятиб һәм Өмми Кәмал, Колшәриф һәм Мәүла Колыйларның тирән эчтәлекле, уй-кичерешләргә бай, сәнгати яктан камил әсәрләре — төрки-татар дини-суфыйчылык әдәбиятының гүзәл сәхифәләре. Алардагы тел-стиль чаралары, образ-сурәтләр, фикри байлык соңгы дәвер әдипләре тарафыннан да иҗади рәвештә файдаланылды, дәвам ителде. Бу аеруча Дәрдемәнд, Мәҗит Гафури, Габдулла Тукай һәм күп кенә башка каләм әһелләренең әчәрләрендә ачык күренә.

Мөселман дине безнең әби-бабаларыбызны киң дөньяга чыгарга, үзләрен бай Шәрык галәменең тулы хокуклы әгъзалары итеп тоярга, гаҗәеп бай гарәп-фарсы рухи казанышлары, алар аркылы антик Грециянең, Һиндстанның рухи байлыклары белән танышырга мөмкинлек бирә. Ислам халкыбызның аерым милләт буларак оешуында, үсешендә, саклануында да гаять иөһим роль уйнаган. Юкка гына аны татарның бер канаты дип әйтмиләрдер.

Тарих шуны күрсәтә: безнең татарга беркайчан да җиңел булмаган. Дәүләтчелеген җуйганнан соңгы аның берничә гасырлык яшәеше — аеруча газаплы, афәтле чор. Әмма шуңа да карамастан, гаять зур югалтулар бәрабәренә булса да, ул үзенең барлыгын, милли асылын саклап кала. Кабатлап әйтәм: монда да без, иң беренче чиратта, мөселман диненә, ислам рухлы хәзинәләребезгә, әдәбиятыбызга бурычлы.

Кызганыч ки, Совет чорында дингә, милли асылга һөҗүм гаять көчәйде. Атеизм байрагы астында күп кенә рухи байлыкларыбыз юкка чыгарылды, йөзәрләгән иҗат әһелләребез шәхес культы корбаны булды, иҗтимагый-мәдәни тормыштан читләштерелде. Мең елдан артык кулланылган гарәп графикасы әүвәл латин, аннан кирилл язуына алыштырылды. Бу исә бай рухи мирас, буыннар арасындагы бәйләнеш күперләрен утка ягу кебек булды. Совет җирлегендәге рәсми сәясәт нәтиҗәсендә халкыбызда милли нигилизм көчәйде, туган телгә, милли мәгарифкә игътибар бик нык кимеде, имансызлык, башка милләт сафларына күчү киң колач алды.

Әмма, нинди генә кыенлыкларга да карамастан, халкыбызның шактый гына асыл уллары һәм кызлары үз милләтенә тугры калдылар, бу юнәлештә фидакарьләрчә көрәштеләр. Элекеге дини-милли яшәеш кануннарын һәм традицияләрен саклауда, буыннар арасындагы элемтәләрне дәвам иттерүдә аеруча мөһаҗирлектәге милләттәшләребез зур тырышлык күрсәттеләр. Финляндиядә, Кытайда, Төркиядә, Алманиядә һәм кайбер башка мәмләкәтләрдә нәшер ителгән китаплар, гәҗит-журналлар — моның ачык дәлиле. Бу юнәлештә бигрәк тә Гаяз Исхакый, Хәсән Хәмидулла, Әхмәд Ләбиб Каран, Хөсәен Габдүш, Сания Гыйффәт һәм кайбер башка мәшһүр затлар фидакарҗләрчә хезмәт куйдылар.

Узган гасырның азаклары — XXI йөзнең башлары милләтебез тарихында янә бер күтәрелеш, Яңарыш чоры булды. Халкыбыз үзенең аянычлы хәлдә икәнлеген аңлый башлады. Үзгәртеп кору хәрәкәтенең көчле дулкыны нәтиҗәсендә милли мәгариф, рухи мирас мәсьәләләре үзәккә куелды һәм бу юнәлештә мөһим генә кайбер адымнар да ясалды. Шунысы аеруча әһәмиятле: халкыбыз үзенең мөселманлыгын ныклап тоя башлады. Мәчет-мәдрәсәләр ачылды, күп төрле дини, милли-мәдәни чаралар уздырылып тора.

Болгар дәүләтендә ислам диненең рәсми рәвештә кабул ителүенә быел, ягъни 2022 елда 1100 ел тула. Аңа хәзрлек шактый киң планда алып барыла. Ул халкыбызны туплауда, кавемара бәйләнешләрне ныгытуда, милли үзаңны үстерүдә бик тә мөһим чара булсын иде!

Бу уңай белән янә бер хакыйтьне искә төшерү зарури. Болгар дәүләтенең 922 елда исламны кабул итүе мөселман диненең Идел-йорттагы берничә гасыр буена таралу процессын тарихи-сәяси-иҗтимагый яктан ныгытуның әһәмиятле бер баскычы. Янә шунысы да бар: әйткәнебезчә, халкыбыз хәзәр, кыпчак, татар һәм кайбер башка этник элементлар кушылуыннан барлыкка килә. Болгарлар исә алар арасында мөһим бер компонент. Кызганыч ки, безнең кайбер “болгарчы”ларыбыз шул тарихи хакыйкатьне бик күрергә теләми. Халкыбызның татар буларак оешкан, аны бөтен дөньяга таныткан дәверен — Алтын Урда чорын күләгәдә калдырырга омтылалар. Ә бит бу кодрәтле татар дәүләте Евразиянең зур

мәйданнарын биләгән. Идел-йорт, Урал-Җаек буйлары, Көнбатыш Себер киңлекләре — бу мәмләкәтнең тарихи җирләре. Болгар дәвере, XIII гасырның урталарына кадәрге чорлар — халкыбызның татар булып оешуына хәзерлек процессының мөһим бер этабы. Элеккеге Болгар, Казан ханлыклары, хәзерге Татарстан җирләре күп гасырлар буе безнең әби-бабаларыбыз яшәгән гаять зур мәйданнарның аерым төбәкләре генә.

**Әдәбият**


1. Греков Д., Якубовский А.Золотая Орда и ее падение. – М.-Л., 1951. – 27 с.
2. “Ислам на европейском Востоке” энциклопедик сүзлек. – Казан: - 2004. — 383 с.
3. История Татарии в материалах и документах. – М., 1937. – 394 с.
4. Миңнегулов Х. “Коръән” һәм татар әдәбияты // Мәгариф. —1993. — № 3. — Б.15—17.
5. Миңнегулов Х. “Татарлык ислам белән көчле” (Ислам дине һәм татар әдәбияты) // ”Иман нуры” журналы. — 1994. — № 1. — Б.26—35 .
6. Миңнегулов Х. “Дөньяда сүземез бар...”. - Казан: - 1999. — Б.111—126.


УДК 821.512.145

## О КНИГЕ «СТРАНИЦЫ НАШЕГО ДУХОВНОГО НАСЛЕДИЯ» «РУХИ МИРАСЫБЫЗ СӘХИФӘЛӘРЕ» КИТАБЫ ТУРЫНДА

***Миннегулов Хатип Юсупович***
Институт филологии и межкультурной коммуникации Казанского (Приволжского) федерального университета, г. Казань, Татарстан, Российская Федерация
*e-mail:metodika.ksu@mail.ru*

**Аннотация**. *В конце марта 2022 года опубликована очередная книга профессора Х. Ю. Миннегулова (Казань, - 488 с. - 344 п. л. На татарском и русском языках), написанная, в основном, за последние два года. Она охватывает различные периоды и явления многовековой истории татарской литературы. Ей присуще тематическое разнообразие. Значительную часть данного труда занимает исследование творчества С. Сараи, Кутба, Мухаммедьяра, Мавля Кулыя, Ш. Заки, Г. Исхаки, Г. Ибрагимова, Р. Гаташа, Ф. Галимуллина и других представителей татарского словесного искусства. В нем также анализируется творческая деятельность более десяти авторов татарской литературы Зарубежья, помещены поэтические произведения их. Есть материалы об актуальных проблемах национального образования, культуры, науки. В одном разделе сборника представлены статьи, выступления, освещающие деятельность Х. Миннегулова. Книга снабжена богатой иллюстрацией, а также материалами биобиблиографического характера.*

*В данной статье делается краткий обзор книги, выявляются ее содержательные и структурные аспекты.*

**Ключевые слова**: *Х. Миннегулов, татарское словесное искусство, межлитературные взаимосвязи, татарская литература Зарубежья, С. Сараи, Кутба, Мухаммедьяр, Ш. Заки.*

## ABOUT THE BOOK «PAGES OF OUR SPIRITUAL HERITAGE»

***Minnegulov Hatip Yusupovich***
Institute of Philology and Intercultural Communication of Kazan (Volga Region) Federal University, Kazan, Tatarstan, Russian Federation

***Abstract.*** *At the end of March 2022, another book by Professor H. Y. Minnegulov (Kazan, - 488 p. - 344 pp. In Tatar and Russian) was published, written mainly over the past two years. It covers*

*various periods and phenomena of the centuries-old history of Tatar literature. It is characterized by thematic diversity. A significant part of this work is devoted to the study of the works of S. Sarai, Kutb, Mukhammedyar, Mavl Kuly, Sh. Zaki, G. Iskhaki, G. Ibragimov, R. Gatash, F. Galimullin and other representatives of the Tatar literary art. It also analyzes the creative activity of more than ten authors of Tatar literature Abroad, their poetic works are placed. There are materials on topical issues of national education, culture, and science. One section of the collection contains articles, speeches covering the activities of X. Minnegulova. The book is provided with a rich illustration, as well as biobibliographic materials.*

*This article provides a brief overview of the book, identifies its content and structural aspects.*

**Keywords:** *H. Minnegulov, Tatar verbal art, interliterary interrelations, Tatar literature Abroad, S. Sarai, Kutba, Mukhammedyar, Sh. Zaki.*

Гәҗит-журнал битләрендә, төрле җыентыкларда, академик басмаларда даими рәвештә дөнья күргән язмаларыбыздан тыш, ел саен безнең аерым китапларыбызда нәшер ителеп тора. Соңгы өч елда гына да Хатыйп Йосыф угылының 5 китабы басылып чыкты. Болар арасында шактый күләмле һәм саллы басмалар да бар. Мәсәлән, 2020 (чынлыкта — 2021 елның февралендә) дөньякүргән “Озын гомерем хатирәләре” (II кисәк) 408 биттән, 27,5 басма табактан гыйбарәт.

Соңгы вакытта гына нәшер ителгән “Гомерләр уза икән ул ... (А годы проходят...)” [1] китабына күзәтү рәвешендә рус телендә әзерләнгәня змабыз Алабугада 2020 елның 25нче декабрендә уздырылган X Халыкара тюркологик конференциягә доклад итеп тәкъдим ителгән иде. Ул “Автор о своей книге “А годы проходят....” исеме астында “Актуальные проблемы тюркологии: Россия и тюрко-мусульманский мир. Материалы X Международной тюркологической конференции” җыентыгында басылып та чыкты [2]. Шул традицияне дәвам итеп, без бу язмабызда әле яңа гына — 2022 елның мартында нәшер ителгән “Рухи мирасыбыз сәхифәләре” җыентыгыбыз турындагы материалны Алабугада уздырылачак чираттагы XI Халыкара тюркологик конференциягә доклад рәвешендә тәкъдим итәргә булдык. Монысының шул типтагы элеккеге материалдан билгеле бер аермасы да бар. “Автор о своей книге...” мәкаләсе урыс телендә авторецензия, күзәтү рәвешендә махсус язылган. Ә монысы “Рухи мирасыбыз сәхифәләре” җыентыгының тәүге өлешеннән алып бирелә. Ул гомуми күзәтү, тасвирлама бирү рәвешендәрәк. “Әлеге җыентык турында алгы сүз” дип исемләнгән бу текст китапка кереш вазыйфасын да үти.

Гыйльми-тикшеренү нәтиҗәләренең зур өлешен без, гадәттә, монографияләр рәвешендә бастырып киләбез. Аларның саны, мөгаен, инде ике дистәдән артып киткәндер. Унга якын коллектив монографияләрдә дә автор буларак катнашканым бар. Бу төр китапларның шактые — татар, урыс телләрендә. Инглиз, төрек, казах телләрендә дә хезмәтләр бар. Без — берничә дәреслек авторы да.

Монографияләрдән тыш, күпләгән мәкалә, докладлар да язылып, сөйләнелеп тора. Алар, нигездә, төрле гәҗит-журналларда, күмәк җыентыкларда басылып килә. Минем андый язмалар элегрәк бик тупланмыйча, тараурак, беренче басмаларында калды. 90 нчы еллардан мин бу төр мәкалә-язмаларны, чыгышларны бергә туплап, аерым җыентык рәвешендә нәшер итә башладым. «Дөньяда сүземез бар...» (1999), «Гасырлар өнен тыңлап» (2003), «Гасырлар арасында уйланулар» (2012), «Записи разных лет» (2016), «Иҗади гамәлле шәхесләр» (2014), «Әдәбиятны өйрәнү юлында» (2018) һәм кайбер башка җыентыкларның да шактый өлешен төрле (аеруча көндәлек, вакытлы) басмаларда, күмәк җыентыкларда дөнья күргән мәкалә-чыгышлар тәшкил итә. Ул төр материалларның берничәсе безнең 2020 елда нәшер ителгән «Гомерләр уза икән ул...» («А годы проходят») (480 б.), «Озын гомерем хатирәләре. II кисәк. Университетта эшләү еллары (1967—2020). Сәфәр-сәяхәтнамәләр” (408 б.) китапларында да урын алган. Соңгы җыентыкларга, нигездә, 2020 елның башларына кадәр язылган, басылган мәкалә-чыгышлар кергән. Ә инде аннан соңгы елдан артык вакыт эчендә Хатыйп Йосыф угылы күп кенә мәкаләләр язды, җыелыш-конференцияләрдә дистәләгән чыгыш ясады. Аларның бер өлеше инде гәҗит-журналларда дөнья күрсә, икенче бер кыйсме кулъязма

рәвешендә кала килә. Бу җыентыкка, нигездә, инде соңгы 1—2 елда язылган мәкаләләр урнаштырылды. Элегрәк чорда кәгазьгә төшерелгән берничә язма да бар.

Әлеге җыентыктагы материалларның зур өлешен татар мөһаҗирлек әдәбияты һәм матбугаты белән бәйле язмалар тәшкил итә. Биредә шунысын да искәртеп китү урынлы булыр: мөһаҗирлек проблемалары белән без фәкыйрегез инде 90 нчы еллардан бирле шөгыльләнеп килә. Бу юнәлештә, аеруча Г. Исхакый иҗаты буенча язылган берничә китап-монографиябез дә бар: "Исхакый мөһаҗирлектә" — Монография (К., 1999. — 84 б.), "Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты". Монография (К., 2004. — 368 б.), «Чит илләрдәге татар әдәбияты". Монография (К., 2007. — 349 б.) һ. Б. Бу төр китапларда, күпләгән җыентыкларда, гәҗит-журналларда мөһаҗирлек әдәбияты һәм матбугаты буенча йөзләгән язмалар нәшер ителгән. Аларның шактые гыйльми, фәнни-популяр характерда. Гаяз Исхакый, Хөсәен Габдүш, Хәсән Хәмидулла, Сания Гыйффәт, Минһаҗ Исмәгыйли, Шаһвәли Келәүле Илдәр һәм кайбер башка мөһаҗир әдипләрнең күп кенә язмалары безнең тарафтан әзерләнеп, киң катлам укучыларга җиткерелде. Болар арасында Г. Исхакыйның атаклы «Ислам мәмләкәтләрендә» сәяхәтнамәсе дә бар. Ул аерым китап рәвешендә кереш мәкалә, тиешле шәрех-аңлатмалар белән 2003 елда нәшер ителгән иде. Татар мөһаҗирлек әдәбияты, бигрәк тә Г. Исхакыйның илдән читтәге иҗаты, эшчәнлеге хакында без фәкыйрегезгә халыкара конференцияләрдә (Төркестан, Хельсинки, Астана һ. Б. Калаларда) докладлар да сөйләргә туры килде. Мөһаҗәраттәге татар сүз сәнгате хакында Хатыйп Йосыф угылы Казан университетының татар филологиясе һәм журналистика бүлекләрендә шактый еллар махсус курс та алып барды.

Мәгълүм ки, чит мәмләкәтләрдә яшәргә мәҗбүр ителгән милләттәшләребез, китап-дәреслекләрдән тыш, төрле гәҗит-журналлар да чыгаралар. Мәсәлән, «Яңа милли юл» (Берлин), «Яңа япун мөхбире» (Токио), «Азат Ватан» (Мюнхен), «Kazan» (Төркия), «Шималь очкыннары» (Финляндия») һ. Б. Журналлар. Болар хакында да безнең дистәләгән мәкалә-язмалар, публикацияләр бар. Соңгырак дистә елда мөһаҗирлек тематикасы белән шөгыльләнү бераз читтәрәк калды. Моның объектив сәбәпләре дә бар иде.

2010 нчы елларда без фәкыйрегез Астанадагы «Төрки академия», Төркестандагы Халыкара казах-төрек университеты һәм кайбер башка гыйльми оешмалар белән хезмәттәшлек итте, күп кенә проектларны гамәлгә ашыруда катнашты. Шушы бәйләнеш-элемтәләрнең нәтиҗәсе буларак, берничә җитди монографиям дә дөнья күрде: "Этапы развития тюрко-татарской, античной и русской литератур" (К., 2014. — 288 с.]; "Тюркское словесное искусство" (К., 2014); "Казанско-татарская тюркологическая школа" (К., 2016)]; "Идея государственность в тюрко-татарской литературе VII—XVI вв. (К., 2016); "Восточная классика и татарская литература" (К., 2014. — 292 с.). Бу хезмәтләребезнең шактый өлеше халыкара басмаларда урыс, инглиз, казах һәм кайбер башка телләрдә дә нәшер ителде. Мәсәлән, 2016 елда Алматыда «Тюркология. История Всемирной тюркологии» дигән коллекив монография дөнья күргән иде. Ул һәрберсе 500 биткә якын өч китаптан гыйбарәт: Алар урыс, казах, инглиз телләрендә. Бу дәрәҗәле басмада Хатыйп Йосыф угылының «Казанско-татарская тюркологическая школа» хезмәте дә, бераз кыскартылып, өч телдә нәшер ителгән.

Билгеле булганча, бездә 90 еллардан бирле рухи мирасыбызны өйрәнүгә, пропагандалауга багышланган махсус журнал чыгып килә. Күптән түгел арабыздан киткән Әхмәт Сәхапов шактый еллар «Мирас» журналының баш мөхәррире булды, файдалы, нәтиҗәле генә гамәлләр кылды. Аннан бераз вакыт журнал белән шагыйрь Мөхәммәт Мирза җитәкчелек итте. «Безнең мирас» исеме белән чыгып килүче бу мәҗмуганың баш мөхәррире хәзер — Ләбиб Лерон. Әйтергә кирәк, журнал бай эчтәлекле. Аның хезмәткәрләре үз эшләренә җаваплы карыйлар. Моннан ике еллар элек баш редактор урынбасары, тәҗрибәле журналист Фирдәвес Зариф журналда мөһаҗирлек әдәбияты буенча махсус рубрика алып баруны үтенде. Мин риза булдым. Инде менә Шиһаб Нигъмәти, Гәүһәр Туганай, Әхмәд Ләбиб Каран, Әхмәд Гәрәй һәм кайбер башка әдипләр, мөһаҗәраттә нәшер ителгән аерым китаплар хакында язмаларым басылып килә. Табигый ки, гәҗит-журналларда автор текстлары теге яки бу дәрәҗәдә кыскартыла, аеруча әдәби текстлар. Нәшер ителгән бер-ике мәкалә инде безнең 2020

елда «Гомерләр уза икән ул...» китабына да кертелгән иде. Шуңа күрә бу җыентыкта без ул язмаларның үзебез әзерләгән чагыштырмача тулы тәүге текстларын бирергә тырышырбыз (Алла боерса!). Искәртеп үтим: «Безнең мирас»та дөнья күргән («Гомерләр уза икән ул...» китабына да кертелгән иде). 2020 ел башларында мөһаҗир шагыйрь Шиһаб Нигъмәтинең әсәрләрен туплаган «Әй, татарым, Әй син — җаным» исемле җыентыгын да (К.— 84 б.) чыгарып өлгергән идек. Анда шактый бай эчтәлекле кереш мәкалә дә бар. Шуңа күрә бу авторга әлеге җыентыкта максус урын бирмәскә булдык. Әмма бу шагыйрьгә, аның китабына мөнәсәбәтле бер-ике язма укучыга тәкъдим ителә. Янә кабатлап әйтәм: безнең бу китапта мөһаҗирлек әдәбиятын тулы, эзлекле яктырту бурычы куелмый. Андагы язмалар тик аерым авторлар, чит илләрдәге татар басма сүзенең кайбер күренеш-фактларны хакында. Әлеге җыентыктагы мөһаҗирлек тематикасына нисбәтле язмаларны безнең элегрәк алып барылган тикшеренүләрнең, китап-публикацияләрнең бер дәвамы рәвешендә генә карарга кирәк.

Истәлекле вакыйга-хәлләрне, аеруча шәхесләребезнең түгәрәк даталарын билгеләп үтү, төрле юбилейлар — безнең хәзерге тормыш өчен гадәти күренеш. Аларга нисбәтән төрле мәкаләләр дә язылa, китаплар да чыгарыла. Шул традицияне дәвам итеп Хатыйп Йосыф угылы да соңгы берничә ел вакыт эчендә матбугатта, радио-телевидениедә, төрле җыелыш-конференцияләрдә күп мәртәбәләр чыгышлар ясады. Рәдиф Гаташ, Фоат Галимуллин, Илдар Кыямов һ. Б. Хакында язмаларым дөнья күрде. XIX йөзнең мәшһүр шагыйре (Әхмәд Йүгнәки, Әхмәд Үргәнчи кебек сукыр әдип) Шәмседдин Зәкинең тууына 200 ел тулу да безнең игътибардан читтә калмады. 2021 елдагы юбилейларның берсе — Алтын Урда чоры шагыйре Сәйф Сараиның (1321—1396) тууына 700 ел тулу иде. Дөрес, ул үз эшчәнлегенә, әдәбиятта тоткан урынына туры килешле югарылыкта узмады. Әмма аңа мөнәсәбәтле берничә чара үткәрелүен хупларга кирәк. Болар арасында аеруча Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих Институтында 2021 елның 15 нче июнендә «Татарларның Урта гасыр язма мирасы (Сәйф Сараиның 700 еллык юбилее уңаеннан)» исеме астында уздырылган Халыклара конференцияне билгеләп үтү урынлы булыр. Аны оештыруда Институтның Алтын Урда бүлеге мөдире, бик тә тырыш, җаваплы Илнур Миргалиев күп көч куйды. Бу гыйльми мәҗлес матбугатта да, җәмәгатьчелектә дә җитди яңгыраш тапты. Конференция материалларын туплаган фәнни җыентык та чыгып килә.

Табигый ки, без фәкыйрегезгә С. Сараиның юбилей чараларында ярыйсы гына катнашырга туры килде. Халыкара конференциянең пленар утырышында доклад сөйләдем. «Мәдәни җомга», «Безнең мирас» кебек гәҗит-журналларда мәкаләләр дә бастырдым. С. Сараиның аерым әсәрләре укучыларга да тәкъдим ителде. Сентябрь башларында «Азатлык» радиосында бу шагыйрьнең юбилее уңае белән минем интервью да тыңланды. «Бизнес-онлайн»да урнаштырылган безнең интервью да киң җәмәгатьчелектә зур кызыксыну тудырды. Минем чыгышлар гомумән хуплау тапты, әмма арада тәнкыйть фикере әйтүчеләр дә булды (Анысы да, һичшиксез, кирәк!). Бу җыентыкка без С. Сараиның 700 еллыгына мөнәсәбәтле язмаларны да урнаштырабыз. Шунысын да искәртеп үтик: тема, үзәккә куелган шәхес бер булгач, ул язмаларда аерым кабатланулар да бар. Алар инде шул рәвештә көндәлек матбугатта басылып чыккан. Шуңа күрә бех ул язмаларга кабат кул тыкмадык. Һәм, гомумән, аерым кабатлаулар, бер үк мәсьәлә хакында сөйләүләр әлеге җыентыгыбызда урын алган кайбер башка язмалар да күзгә ташлана. Укучы, шәт, гафу итәр: андыйларны да без, нигездә, башлангыч, тәүге вариантта калдырдык. Бу җыентыкның эчтәлек-структурасында янә бәйләнерлек нәрсә бар: ул да булса мәкалә-язмаларның бүлек-бүлекчәләргә бүленүендә. Мәсәлән, мөһаҗирлек тематикасы, махсус бүлектән тыш, башка урыннарда да теге яки бу дәрәҗәдә кузгатыла. Кыскасы, материалларны төркемләү, урнаштыруда шактый гына шартлылык та бар.

Мөһаҗирлек, юбилей материаллары белән бергә, соңгы елда аз булса да башка темаларга да берничә мәкалә язылган. Болар арасында Котб, Мәүла Колый һәм кайбер башка авторлар хакында да язмалар бар. Аларны һәм элегрәк дөнья күргән янә аерым публикацияләр дә җыентыкка тәкъдим ителде.

Яшь арта, картая-өлкәнәя, гомер уза барган саен үткәннәр турында, вакыт чоңгылында калган эш-гамәлләрең хакында ныграк һәм ешрак уйланасың икән. Быел (2021) җәй ахырында теге коронавирус зәхмәте шаулатып, чабып йөргән Хатыйп Йосыф угылын да эләктереп алды. Бер айга якын хастаханәдә, аннан өйдә дәвалану вакытында үткән гомер, яшьлек хакында уйланулар тагын да көчәйде. Шундый халәттә мин шәхси архивымны, китапханәмне, тупланган кәгазь-кульъязмаларны барлый, теге яки бу дәрәҗәдә тәртипкә китерә, системалаштыра башладым. Мактану дип кабул итмәгез: минем шәхси китапханәм шактый бай. Китап-журналлар, кульъязмалар белән өй тулган. Бераз арыну өчен мин инде үземнең күп кенә басмаларны, материалларны библиотека-музейларга тапшырып киләм. Университет китапханәсендә, Милли музейда, Болгар академиясендә. Татарстан Фәннәр Академиясе библиотекасында, Республика Милли китапханәсендә без биргән кульъязмалар, басма китаплар саны, мөгаен, меңгә якындыр, Г. Ибраһимов исемендәге институтның «Мирасханә»се белән хезмәттәшлегебез аеруча тыгыз һәм дәвамлы. Мин инде аңа күп кенә материаллар бирдем. Соңгы көннәрдә шәхси архивымның зур өлешен «Мирасханә»гә махсус фонд рәвешендә кабул иттеләр (Рәхмәт үзләренә!). Республика Милли китапханәсенә дә инде берничә йөз китап тапшырдым. Аларның күпчелеген мөһаҗирлеккә мөнәсәбәтле китап-журналлар тәшкил итә. Шәхси архив, «Мирасханә»гә, Милли китапханәгә тапшырылган материаллар хакында язылган «Мирасханә»гә — «шәхси мирас» һәм «Мирасханә» мәкаләсенә гыйлавә» язмалары да яңа җыентыгыбызда урын алды.

Әгәр дә синең шәхесеңә (эшчәнлегеңә, юбилееңа, хезмәтләреңә, бүләк алуыңа) кагылышлы нинди дә булса чара уздырылса, гәрчә ул башкалар инициативасы белән үткәрелсә дә, барыбер үзеңә йөгерергә, үзең оештырырга туры килә. Бу, кагыйдә буларак, хәзерге тормыш-яшәешебез өчен хас күренеш. Ә инде үзең башлап кузгаткан чараларны оештырганда табаннарың сызлый башлый, хәлдән таясың. Әмма бу гомуми сыйфаттан, күренештән чыгармалар да була икән. Күптән түгел мин шуның икесенә тап булдым. 2018 елда миңа 80 яшь җәмәгатьчелек тарафыннан шактый киң планда билгеләп үтелде.

Зур кичә үземнең төп эш урыным — университетта, аның конференц-залында булды. Анда студентлар, хезмәттәшләр, җәмәгатьчелек вәкилләре, рәсми затлар катнашты. Зәй һәм Сарманның мәдәният йортларында, Әлмәтнең С. Сөләйманова исемендәге Үзәк китапханәсендә һәм кайбер башка урыннарда да Хатыйп Йосыф угылына багышланган махсус чаралар үткәрелде. Тукай клубында Язучылар Берлеге оештырган юбилей кичәсен дә тамашачылар бик яратып кабул итте. 2019 елның 6 нчы декабрендә һич көтмәгән, искәрмәгән җирдә Дәрвишләр бистәсендәге 11 нче татар гимназиясенә конференциягә чакырдылар. Баксаң, Казан шәһәре һәм Совет районы мәгариф бүлекләре, Казан университетының журналистика, Шәрыкны өйрәнү һәм халыкара мөнәсәбәтләр институтлары без фәкыйрегезгә багышлап республикакүләм махсус фәнни-гамәли конференция оештырганнар икән. Бу чараны гамәлгә ашыруда 11 нче гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Зөләйха ханым Хафизова һәм Дәрвишләр бистәсендәге «Балалар иҗат Үзәге» методисты Ләйсән Антонова төп йөкне тартканнар (Зур рәхмәт бу фидакарь затларга!). Конференция бик матур, оешкан төстә узды. Анда галимнәр, республика укытучылары, журналистлар, белән бергә, Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчеләре, рәсми хакимият вәкилләре дә катнашты. Бу чараны оештыручылар конференция көненә аның махсус җыентыгын да чыгарып өлгергәннәр иде [3]. Бу саллы җыентыкта 80 гә якын доклад-чыгыш тексты урнаштырылган. Авторлары — укытучылар, галим-голяма, студентлар, журналистлар һ. Б. Материаллар татар, урыс, инглиз телләрендә. Хәтта Хатыйп Миңнегуловның бер язмасы япунчага да тәрҗемә итеп бирелгән. Ел ярымлап вакыт үтүгә шушы ук оешма-учреждениеләр, 11 нче гимназия, Зөләйха һәм Ләйсән ханымнар янә безгә сиздермичә, әйтмичә генә фәнни-гамәли конференция оештырганнар. Ул инде Республика күләмендә генә түгел, Бөтенроссия масштабында. Анда чыннан да Рәчәйнең башка төбәкләреннән дә докладлар кабул ителгән. 2021 елның 9 нчы июнендә шул Дәрвишләр бистәсендәге 11 нче гимназиядә узган бу чара да бик тә җылы, мавыктыргыч узды. Концерт номерлары да тәкъдим ителде. Конференция кысаларында гимназиядә Хатыйп Йосыф угылына багышланган махсус музей ачылу да бу чараны бизәде.

Конференциядә Фоат Галимуллин, Рәдиф Гаташ кебек күренекле әдип-галимнәр дә чыгыш ясады. Бу гыйльми мәҗлеснең элеккесе кебек, шул ук исем белән җыентыгы да дөнья күрде. Анда төрле сфера (мәгариф, фән, иҗат, хакимият…) вәкилләренең 70 кә якын доклады урнаштырылган. Аларның зур күпчелегендә без фәкыйрегезнең эшчәнлеге, шәхесе төрле яктан анализлана, аванс белән әйтелгән фикер-күзәтүләр дә күзгә ташлана. Һәр ике конференция эшчәнлеге дә радио-телевидениедә, матбугатта шактый тулы яктыртылыш тапты. Тәүге (ягъни 2019 елгы) конференция материалларының кайберләрен без «Гомерләр уза икән ул…» дигән китабыбызда урнаштырган идек. Шул традицияне дәвам итеп быелгы (2021 елгы) гыйльми чараның җыентыгыннан да берничә мәкалә-чыгыш укучыларга тәкъдим ителде.

Әлеге китабыбызда да без, элеккеге җыентыкларыбыздагы кебек, Хатыйп Йосыф угылы эшчәнлегенә, хезмәтләренә кагылышлы аерым язмаларны, материалларны урнаштырабыз. Алар, нигездә, 2020—2021 елларга карый. Арада элегрәк елларга мөнәсәбәтле берничә язма, материал да бар.

Китапка билгеле бер күләмдә фоторәсемнәр, иллюстрацияләр урнаштыруны да кирәк таптык. Син үзең язганнарны, синең китапларыңны укучылар тулысынча укый дип уйлау беркатлылык (наивность). Берәүләр актарып чыга, икенчеләре тоташтан укый, өченчеләре рәсем-иллюстрацияләре белән генә таныша.

Моңа кадәр басылган хезмәтләр, укылган доклад-чыгышлар без фәкыйрегез турында язмалар моңа кадәрге китапларыбызда даими рәвештә бирелеп барыла. Бу төр библиографик материаллар, мәсәлән, безнең «Бер елда — биш илдә» (2018). Биобиблиографик мәгълүматлар (К., 2019. — 192 б.), «Гомерләр уза икән ул…» (К., 2020. —480 б.), «Озын гомерем хатирәләре. II кисәк...» (К., 2020. — 408 б.) китапларында шактый тулы гәүдәләнеш тапкан. Бу җыентыкта исә, нигездә, соңгы елларга мөнәсәбәтле басмаларны урнаштыру белән чикләнәбез.

Әлеге җыентык, гәрчә андагы материаллар соңгы 1—2 елда язылсалар да, Хатыйп Йосыф угылының гомуми эшчәнлеген, татар әдәбиятының, фәненең торышын теге яки дәрәҗәдә күзалларга ярдәм итәр дип уйлыйбыз. Анда аерым җитешсезлекләр, кабатланулар, бәхәсле яклар булуын да һич тә кире какмыйбыз. Шәт, хөрмәтле укучы бу китапка игътибар итәр, андагы плюс-минусларны үзе аңлар дип ышанабыз.

### Әдәбият


1. Миңнегулов Хатыйп “Озын гомер хатирәләре”. II кисәк Университтета эшләү еллары (1967-2020). Сәфәр-сәяхәтнәмәләре – Казан: “Ихлас” нәшр., 2020. – 408 б.
2. Сборник “Актуальные проблемы тюркологии: Россия и тюрко-мусульманский мир материалы X Международной тюркологической конференции”, изд. Казан. ун-та, 25 декабря 2020 года.
3. «Дөньяда сүзебез бар..»: Хатыйп Йосыф угылы Миңнегулов исемендәге I фәнни-гамәли республика конференциясе материаллары. 2019 елның 6 нчы декабре. - К., 2019. - 347 б.

УДК 821.512.145

# ПРОСВЕТИТЕЛЬСКИЕ ИДЕИ В РАСКРЫТИИ ПРОБЛЕМЫ «ОТЦОВ И ДЕТЕЙ» В ТАТАРСКОЙ ПРОЗЕ XIX ВЕКА
# XIX ГАСЫР ТАТАР ПРОЗАСЫНДА «АТАЛАР ҺӘМ БАЛАЛАР» ПРОБЛЕМАСЫНЫҢ АЧЫЛЫШЫНДА МӘГЪРИФӘТЧЕЛ ИДЕЯЛӘР

***Мухаметзянова Айгуль Хабибзяновна***
Елабужский иниститут Казанского (Приволжского) федерального университета
г. Елабуга, Татарстан, Российская Федерация
*e-mail: bak-aigul@yandex.ru*

**Аннотация.** *В данной статье на примерах из творчества татарских просветительских писателей, таких как М. Акъегет, Ф. Карими, З.Бигиев, Р. Фахретдин и З.Хади рассматривается постановка проблемы“отцов и детей” в татарской прозе XIX века.*
**Ключевые слова**: *татаская литература, татарская литератураXIX века, проблема «отцов и детей», просветительство.*

# EDUCATIONAL IDEAS IN THE DISCLOSURE OF THE PROBLEM OF «FATHERS AND CHILDREN» IN TATAR PROSE OF THE XIX CENTURY

***Mukhametzyanova Aygul Khabibzyanovna***
Elabuga Institute of the Kazan (Volga Region) Federal University,
Elabuga, Tatarstan, Russia

**Abstract.** *In this article, using examples from the work of Tatar educational writers such as M. Akyeget, F. Karimi, Z. Bigiev, R. Fakhretdin and Z. Hadi, the formulation of the problem of “fathers and children” in Tatar prose of the 19th century is considered.*
**Keywords**: *Tatar literature, Tatar literature of the 19th century, the problem of "fathers and children", enlightenment.*

Аталар һәм балалар проблемасы, дөньяның үзе кебек үк «карт» темаларның берсе. Ләкин, шуңа карамастан, бу проблема татар әдәбиятында, рус әдәбиятыннан аермалы буларак, өйрәнелмәгән һәм фәнни яктан яктыртылмаган, дияргә кирәк. Яхшымы әллә начармы, әйтүе авыр, әмма ул гадәти бетмәс-төкәнмәс искелек белән яңалык арасындагы көрәшнең бер чагылышы булып тора.

XX гасырда иҗат иткән әдипләребез аталар һәм балалар проблемасына төрлечә якын киләләр. Күзәтүләр һәм тикшеренүләрдән чыгып шуны искәртергә була, әлеге тема һәр әсәрдә яктыртыла: беренчеләрендә бу проблема ап-ачык яктыртылса, икенчеләрендә бу тема образларны ачуда ярдәмгә килә.

Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла» повестенда күтәрелгән мәсьәләләр үз чорының әһәмиятле проблемалары булып, аннан соң да татар әдәбиятының үзәгендә тора. Шундый проблемаларның берсе – аталар һәм балалар проблемасы. М.Акъегет әсәренең үзәгендә куелган кеше азатлыгы темасы нәкъ менә шушы проблема яссылыгында ачыла. «Инсан мәгыйшәтендә бер бәһале вә яхшы шәй хөрриятттер. Без үз хөрриятемези саклый билербез, - ди Хисаметдин менла. Әсәрнең икенче герое Хәнифә дә аның бу карашларын уртаклаша: «Хөрриятсез яшәмәк көч вә зәхмәт идекене бән дә белермен», - ди. Әдип нәкъ менә Хәнифә образы һәм Хәнифә язмышы аша ул проблеманы күтәреп чыга да. Хәнифә, ата-аналарының, үзен чолгаган, ул вакытта чиксез көчле булган, иске тормыш традициясен җимереп, үз язмышын үзе хәл итә. Кыз, аның теләгеннән башка, әтисенең ул яратмаган кешегә, әмма байлыгы һәм дәрәҗәсе ягыннан Габбас ага илә Шәмси абыстайны канәгатьләндергән, кияүгә бирергә теләгәннәрен белеп алгач, үзенең бәхете өчен көрәшә башлый һәм ахыр чиктә үзенең

туган йортыннан качып китәргә була. Әйе, ата-ананы бердән-бер кызыксындырган нәрсә - «кызлары яхшы киенеп, ризыклы улыр». «Габбас ага вә Шәмси абыстай бөек вә бай адәмнәр арасына кереп әкърибалык вә руглык кәсеп итәчәкләреннән мәсрүр иделәр» - ди автор [1, б. 36]. Ата-ана бары бердәнбер нарасыйларыннан мәхрүм кала алуларын аңлап алгач кына кызларының сайлавы белән килешәләр.

Фатих Кәриминең «Мирза кызы Фатыйма» (1901) хикәясенендә күтәрелгән ата һәм бала арасындагы проблема Муса Акъегетнеке белән охшаш, ләкин шул ук вакытта ул башкачарак яңгырый. Әдип әсәрдә социаль тигесезлек шартларында саф мәхәббәт кешеләрен күрсәтә, шәхеснең дәрәҗәсе нәсел-нәсәп белән түгел, ә тырышлык, намуслылык нәтиҗәсендә туа, дигән идея үткәрә.

Хикәянең героинясы Фатыйма – русча, татарча укыган, күп китаплар күргән кыз. Ул, мәгърифәтчел карашларда үсеп, ата-аналарының гади хезмәт халкын түбәнсетүе белән килешә алмый. Нәсел-нәсәп белән мактану – хурлык ул, кеше үз эше белән танылырга тиеш, дип фикер йөртә. Шундый героинясын язучы тормыш сынавы аша үткәрә. Фатыйма гади бакчачыны – Мостафаны ярата, аның турында гына уйлый, ата-аналарының риза булмаячагын күз алдына китереп, борчыла.

Мостафа да аның матур, мөлаем һәм намуслы кыз булуына соклана. Ләкин укымышлы, дворяннардан булган бу кызга күңелен ачырга тартына.

Монда да әсәр ахырында Фатыйманың этисе кызның сайлавы белән килешә, качып киткән яшь парларны үз өенә алып кайта.

Заһир Бигиев реалист художник буларак, әсәрләрендә үз чорындагы буржуа яшьләренең көнкүреш, мәхәббәт өлкәсендәге карашларын шактый дөрес күрсәтүгә ирешә алган. Язучының «Меңнәр, яки гүзәл кыз Хәдичә» әсәрендә Казанның яшь байларыннан Муса Салихов Петебургта Зөләйха исемле кызны очрата һәм аңа үзенең сөйкемелелеге, гимназия бетергән, укымышлы кыз булуы белән ошый. Шул вакытта Муса Зөләйханы аталарыннан үзенә бирүләрен сорый. Ләкин кызның ата-анасы бу никахка риза булмый. Казанда Муса икенче бер «матурны» ярата башлый. Йөз мең сум бирнәсе белән Әхмәди бай кызы Хәдичәне алырга хәзерләнә. Беренче мәхәббәтен оныта гына түгел, элекке вәгдъдәләшүләренә ышанып, туган җирен, бердәнбер анасын ташлап килгән бу яшь кызны Муса авыр шартларда калдыра. Зөләйханы сабыйларча: «Сезгә килдем, шаять Петербургта кылган вәгъдәгезне онытмагансыз?» - дип биргән соравына, салкын гына итеп: «Әхмәди Хәмитовның кызыны йөз мең сумм көмеш акча илә кәләшлеккә алу – максудым», - дип җавап кайтара [1, б. 201].

Героиняның фаҗигагә китергән сәбәпләрне автор мәъгифәтчеләрчә аңлата. Бу Зөләйханың үләр алдыннан әнисенә язган хатында ачык чагыла: «Бән, гасыйя кызыңыз Зөләйха, Муса әфәндея хатын булмак нияте илә, бәлдәи Казанга кәлдем. Сезенең рөхсәтләреңездән башка качып китдекем сәбәбеннән, сәфәрем хәерле улмады: мәгъшукым Муса әфәнде, Казанлы бер бай кешенең кызыны йөз мең сум көмеш акча илә хәлал җефетлеккә алдыгыннан, бәне хатынлыкка алмыйдыр» [1, б. 256].

Димәк, Зөләйха хыялы тормышка ашмауның төп сәбәбе – ата-ана сүзеннән читләшү. Зөләйха мәгърифәтчеләрнең мәгълүм карашларына каршы чыккан. Мәгърифәтчеләр шәхеснең тормыштагы юлын һәм язмышын билгеләүдә гаилә тәрбиясен хәлиткеч фактор итеп карыйлар. Кешелекле тәрбия алган бала ата-анасы күрсәткән юлдан барырга тиеш дигән караштa торалар. Бала шушы юлдан читкә тайпылса, «табигый тәртипне» бозса, мәгърифәтчеләр андый затларны үз әсәрләрендә каты хөкемгә тарталар. Зөләйха да шундый хөкемгә дучар ителә.

Заһир Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» әсәренең төп максаты, үзмаксаты «зур җинаятьчеләр» түрында сөйләү булмаганлыгын галимнәр күп тапкырлар ассызыклыйлар. Билгеле булганча, «җинаять вә мәхкәмә мәгыйшәтеннән» алынып язылган бу әсәрдә З.Бигиев мәгърифәтчеләрне кызыксындырган тәрбия мәсьәләсен яктыртырга омтыла. Әсәрдә тирәлекнең шәхескә мәгърифәтчеләрчә аңланган йогынтысы тәрбиянең хәлиткеч факторы итеп алына. Романның үзәк геройлары Габделгафур белән Маһруй шәхесне тирәклекнең бозуына мисал булып алга басалар. З.Бигиев мәгърифәтчеләрнең ата-ана ничек булса, бала да шулай була дигән карашларын уртаклаша, игътибарын геройның ата-анасын характерлауга бирә. «Нәкәс мелла,

- ди әдип, - хилли заманнан бирү «К» карьясында имам улып хәйләи шәргый вә на хәлаль кәсебләр кылып, ришвәт вә риба тарикыйлә мал казанып, шимдеки хальдә, башка имамнара нисбәтән, малдыр бер углан улып, ике хатына зәвеж вә биш балая атадыр» [1, б.231].

Шундый әхлаксыз һәм кешелексез Нәкәс мулла, табигый, Габделгафурга тиешле әхлакый тәрбия дә бирми, үрнәк тә була алмый. Шуның өчен ул, авылыннан чыгып киткәч, яңа тирәлекнең зарарлы йогынтысында бик тиз бирелә. Яшь геройның киләчәк язмышында хәлиткеч роль уйнаган тирәлек итеп мәдрәсә тормышы күрсәтелә. Габделгафурның мәдрәсәдә укуын тасвирлауга күчкәч, З.Бигиев публицистик чигенеш ясый һәм шул чор мәдрәсәләрендәге хәлләрне ассызыклый: «Нәчә вә нәчә сәнәләрдән бирү мәдрәсәләремез бу хальдә улып, нәчә вә нәчә толәбәләр нәчә вә нәчә җирләрдә улдылар, нәчә вә нәчә хальләрә ирделәр, вә бу хәльләри нәчә вә нәчә кемсәнәләр күрделәр. Кемсә бу хакта бер сүз әйтмәде язмады» [1, б.235].

Автор фикеренчә, Габделгафурны күңелсез язмышка китергән икенче мөһим сәбәп – аның мәгърифәткә, гыйлемгә омтылышы җитмәү. Мондый омтылышны аңарга ата-анасы да, мәдрәсә дә бирә алмаган.

Маһруй икенче төрлерәк тәрбия ала. Аның әтисе Гали Ваһапов – Нәкәс мулланың антиподы. Гали Ваһәпов кешелекле һәм гыйлем сөюче зат булла. Аның хатыны Мәрьям абыстай да «яхшы ата баласы улып, суфия вә намазчы» шәхес. Шундый кешеләр баласы булган Маһруй, табигый, саф күңелле кыз булып үсә. Кешелекле һәм күркәм гаиләдән чыккан Җиһангир дә нәкъ менә Маһруйның «гыйрфанына хәйран вә хөсненә гашыйк» булла бераздан аңа өйләнә. Маһруй җитди генә әхлакый сынауга дучар ителә. Ире Җиһангир сәүдә эшләре белән Себер якларына чыгып киткәч, ул өйдә карт анасы һәм баласы белән генә кала, бозык карчык йогынтысына бирелә. Әлеге карчык аны бозык егет Якуп Галиев белән таныштыра. Алар яшь гомерләрен «гамьсез вәк кәрәк эштә кичермәя» башлыйлар. Сүз уңаенда автор мондый хәлләрнең очраклы булмавын, андый карчыклар сүзенә карап мораль бозыклык юлына баскан яшьләрнең ул заманда еш очравын әйтә. Моның белән З.Бигиев әсәре, объектив рәвештә, шул чордагы буржуаз тормышның әхлаксыз якларын ача.

Габделгафур, ялгыш юлга басып, тормыш төбенә тәгәрәсә, Маһруй, Якуп белән бәйләнеп, зур хата эшләгәнен аңлый. Бала буласын белеп, Якуп баш тарткач, яшь хатын бушка үткәрмәгән «гомеренең нәтиҗә вә сәмәрәсе буш нәрсә улмадыгыны дөшенмәя» башлый. Автор фикеренчә, яхшы ата-ана баласы, төрле сәбәпләр аркасында, вакытлыча буталып калып ялгыш юлга да басарга мөмкин. Әмма ул бөтенләй бозыла алмый: моңа аның балачакта ата-анадан алган тәрбиясе, күңеленә сеңдерелгән әхлаклылыгы юл куймый.

Күргәнебезчә, бу әсәрдә ата һәм бала проблемасы башка методка нигезләнеп яктыртылган әсәрләр белән чагыштырганда үзгәчә куелган.

Ризаэтдин Фәхретдиннең «Әсма, яки гамәл вә җәза» әсәрендә күтәрелгән ата һәм бала проблемасы әдипнең мәгърифәтчел карашларына нигезле яктыртыла. Автор, XIX йөз мәгърифәтче язучыларның традициясен дәвам итеп, яхшылык бүләге – бәхет, начар эшләрнең җәзасы – түбәнлек дигән идеяне күтәрә. Шушы идеянең тукымасында ата һәм бала проблемасы да ята һәм бу мәсьәләне әдип мәгърифәтчел максатлардан чыгып яктырта. Автор ата-аналар алдына яшь буынга дөрес тәрбия бирүне беренчел шарт итеп куя.

Сюжет буенча Әсма үз заманының прогрессив карашлы булган Габбас мулла гаиләсендә дөньяга килә. Әдип Габбас мулла хакында түбәндәгечә яза: «Габбас мелла яшьлегендә гаять тә зирәк вә шат вә һөнәрсәгә һәвәсле вә һәр шәй кулыннан киллер ки мөстәгыйт (сәләтле) бер бала иде исә дә, җан иделдеге кадәр кәмаләт кәсеп идә алмадыгы хәлдә мәдрәсәдән чыгып имам улды…

Мәгълүмдер ки, дөньяда бай балалары мал кадерен вә мөдәррис балалары гыйлем кадерен лазем мәртәбә белмәсләр. Ләкин боның өчен буйлә балалар гаепле улмай, бәлки бу шәйләрнең хөрмәте белерлек рәвеш үзрә тәрбия идә алмадыклары вә буйлә тәрбияләргә игътибар итмәдекләре өчен аталар гаепле улсалар кирәк». Димәк, шул рәвешле, автор баланың әхлаклыгын һәм гыйлемлеген беренче чиратта ата-аналарга кайтарып калдыра. Әсәрен дәвам итеп: «Габбас менла, әгәр кәндесе кеби җиңел фикерле, дөньяга илтифатсыз бер хатынга

тугыры килмеш улса иде, гомерене ахмаклар гадәте үзрә сәфаһәт дөньяларында кичермәк вә бөтен фамилиясенең шәрафәтенә дегет буяп, дөньясына вәдагь идәчәк иде. Ләкин җәнабе илаһенең мәрхәмәте уларак, боңа гакылы, тәкъва, диндар, җөсур, мәрхәмәтле бер хатын мөяссәр улды.

…Гайшә абыстайның тәрбиясе вә төн-көн улан иҗтиһаты сәбәбеннән Габбас менла һәрбер яңа вә иске рисаләләрне, рус, төрки, гарәби җәридә вә мәҗәлләләрне укымага һәм дә бөек бер ихлас вә хирыс илә укымага башлады.

…Гайшә абыстай этрафына нисбәте илә шөһрәтле бер мөдәррис кызы улдыгы хәлдә, ни өчендер мәхдүм вә мәхдүмәләр табигатенә тәмам башка бер гадәттә иде. Мәсәлән, гыйлемлек хөрмәтене белер, укыр һәм язар, иркәлек нәдер – белмәс...», - дип яза [1, б.303].

Күрүебезчә, автор әсәр башында ук ата-ананы идеалаштыра. Алар Әсманың тәрбиясе һәм гыйлемлелеге хакында кайгырталар. Һәм шунсы аеруча мөһим, Габбас белән Гайшә үзләре дә Әсма өчен үрнәк булып торалар. Әсәр ахырында Әсманың тормышның төрле кырыс җилләре аша үтеп, үзенең мәхәббәтен һәм бәхетен табу, автор идеясе буенча аның ата-анадан килгән тугры тәрбиясенең җимеше. Кыз үзенең ата-анасына зур хөрмәт белән карый, чөнки аның өчен алар өлге булып торалар. Нәкъ менә шундый, балаларның тәрбиясенә җитди караган, ата-аналар булганда буыннар арасында «бушлык» барлыкка килмәс, аңлашылмаучанлыклар булмас һәм киләчәк буын, милләт алга китәр, ди автор.

XIX гасыр татар прозасын яңа гасыр әдәбияты белән бәйләп торучы күперчек ролен башкарган Закир Һадиның иҗатында да ата һәм бала арасындагы проблема беренчел планда тора. Ризаэддин Фәхретдиннең Әсма образының каршысы булып торган Хәнифәнең язмышы башкача тәмамлана. Бу хикәядә иң элек без Хәнифәнең эти-әнисе - Әхтәри агай һәм аның хатыны Шәрифә белән танышабыз. Автор Әхтәри агайны сурәтләгәндә аның икейөзлелегенә басым ясый. Карап торырга «таза гына тормышлы», «түгәрәк сакаллы, киң җилкәле» бу карт «галим-голәмәгә бик ихласлы», «суфилыкна дәгъва кылучан» булып күренә. Яшьлек гөнаһларын ташлап, ул хәзер «бер ишанга мөрид булып йөри». Әмма Әхтәринең суфилыгы – тышкы бизәк кенә. Чынлыкта аңа бөтенләй башка «гадәте хасәнәләр» хас: ул «яшь вакытында балны бик яратып эчкән», хәзер исә «кешеләр адында эчүне ташлаган», бик саран: сукалаганда гел кеше җиренә керә, хезмәтчесенең бер-ике тиен булса да, тиешле хакын кысып калырга тырыша; мулла яки шәкерткә «бен тиен ярдәм әйләмәк ихтималы юктыр», үзен юмарт кеше итеп күрсәтергә теләп, кунак җыяр һәм аларны «сырхауланып үлә башлагач суелган хайван ите белән сыйлар.

«Чиләгенә күрә капкачы» дигәндәй, Әхтәри агайның Шәрифәсе дә «изге зат» түгел – ул, «яшь вакытында шаярган бер хатын» булуга карамастан, «Әхтәри агайны агызына караткан, үзенә иман китерткән». Алга таба хикәядән күренгәнчә, аларның кызы, әсәрнең баш героинясы, Хәнифә, намусын саклап кала алмыйча, башында күп михнәт–хәсрәт кичерүендә һәм ахырда үз-үзен үтерүендә иң элек кызның эти-әнисе гаепле. Әхтәри агай кызга чын ата була алмый, аталарча аның тәрбиясе белән кызыксынмый һәм үзе дә аңа терәк, кызга шәхес булып үсеп җитлешүдә үрнәк булмый, бары кире сыйфатларны үзендә булдыру юнәлешендә генә булса. Кызның анасы Шәрифә «яшьлегендә сөю-сөешү» мәсьәләләрендә шактый талымсыз булган бу хатын кызына тиешле тәрбия биреп аны ялгыш адымнан саклыйсы урынына, үзе үк егет белән кызга яшерен рәвештә очрашыр өчен шартлар тудыра.

Шулай итеп, XIX йөз язучылары аталар һәм балалар проблемасын мәгърифәтчел карашларынннан чыгып хәл итәләр. Мәгърифәтче язучылар үз әсәрләрендә шәхес формалашу процессында гаилә ролен, аеруча хатын-кыз, ана кеше ролен беренче планга куялар. Аларның фикеренчә, яшь кешенең киләчәге иң элек ата-анасының белеме һәм әхлак дәрәҗәсенә бәйле, ә «гайлә - тәрбия институты һәм мохит берәмлеге».

XIX - XX йөз башы әдәбиятында аталар һәм балалар проблемасы «яңалык һәм искелек көрәше» формасында ачыла. Бу чор әсәрләрдә аталар һәм балалар проблемасы эчендә феодализм йомыклыгы шартларында көнкүреш, семья өлкәсендә куп еллар буенча урнашып килгән иске мөнәсәбәтләргә каршы фикерләр күтәрелә.

**Әдәбият**

1. Татар мәгърифәтчелек әдәбияты (1860 – 1905) / төз.М.Х. Гайнуллин. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1979. – 415 б.
2. Харрасова Р. Иҗтимагый-мәдәни хәрәкәт һәм әдәби барыш / Татар әдәбияты тарихы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017.- 8 т.– 170 б.
3. Миңнегулов Х. “Татарлык ислам белән көчле” (Ислам дине һәм татар әдәбияты) //”Иман нуры” журналы. – 1994. – № 1. – Б.26-35 .

УДК 82.512.1-131

## ТАТАР ЭПОС-ДАСТАННАРЫНА ИСЛАМ ЙОГЫНТЫСЫ

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы***
Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты,
Казан ш., Татарстан, Россия Федерациясе
*e-mail:lilmuhat@mail.ru*

**Аннотация.** *Статья посвящена обобщению некоторых результатов исследования татарских эпос-дастанов. Рассуждая о роли ислама в формировании и развитии крупного эпического жанра фольклора и литературы в устном и письменном словесном творчестве, автор обращает особое внимание на героико-религиозную и любовно-религиозную тематику в классификации татарских дастанов; характеризует их как стадиально позднюю группу национального эпоса. Возникновение и становление данной группы эпос-дастанов автором рассматривается как результат интенсивного влияния ислама в народную культуру.*

**Ключевые слова:** *татарский эпос; влияние ислама; героико-религиозный эпос; любовно-религиозные дастаны; письменный фольклор.*

## HEROIC-RELIGIOUS AND LOVE-RELIGIOUS DASTANS AS A RESULT OF THE INFLUENCE OF ISLAM ON THE TATAR EPIC

***Mukhametziyanova Liliya Khatipovna***
G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art of the Academy of Sciences
of the Republic of Tatarstan, Kazan, Tatarstan, Russian Federation

**Abstract.** *The article is devoted to the generalization of some results of the study of Tatar epic dastans. Discussing the role of Islam in the formation and development of a large epic genre of folklore and literature in oral and written verbal creativity, the author pays special attention to the heroic-religious and love-religious themes in the classification of Tatar dastans; characterizes them as a stage-late group of the national epic. The emergence and formation of this group of epic dastans is considered by the author as a result of the intense influence of Islam in folk culture.*

**Keywords**: *Tatar epic; Islamic influence; heroic-religious epic; love-religious dastans; written folklore.*

Ислам грамоталылыкны, укымышлылыкны, китапны һәрвакыт пропагандалавы белән мәшһүр, шуңа бәйле, мөселман мәдәниятенә ия халыкларның дөньяга карашлары формалашуга зур йогынты ясаган. Православ динендәге аз санлы керәшеннәрдән кала барлык татарлар – Россиядәге иң эре мөселман халкы. 922 нче елда Идел буе Болгарында Ислам дине рәсми игълан ителгәннән соң, кайбер мәгълүматларга караганда, хәтта аннан да иртәрәк Исламга кайтканның соңында борынгы татар халкының дөньяны танып белүе үсеш-үзгәреш кичергән булу гаять табигый. Хәлбуки ничәмә-ничә гасыр буена татар халкы гомумкешелек рухи кыйммәтләрен ислам аша үзләштерә килгән. Шуңа да татарларның мәкаль әйтем,

табышмак, риваятьләреннән алып, зур күләмле китаби эпос-дастаннарында да мөселманча тормыш рәвеше чагылган булу, алай гына да түгел, әлеге ядкарьләрнең ислам мәдәнияте белән бик тирән сугарылган, керешеп беткән булуы бер дә гаҗәп түгел.

Билгеле булганча, татар эпосы ике зур төркемгә бүленә. Аның беренчесе каһарман батырлыгы турында сөйли торган героик дастаннар булса, икенчесе романик характердагы мәхәббәт сюжетлы әсәрләр. Әлбәттә, бик борынгы дәвердә, әле исламгача чорларга кадәр үк барлыкка килгән татар эпосы тоташтан мөселманлык идеяләренә буйсына дип әйтү дөрес булмас. Татар эпосы формалашуга тәэсир иткән факторлар арасында исламны аерып күрсәтү татар дастаннарының эчтәлегендәге һәм таралу рәвешендә булган үзенчәлекләргә барып тоташа. Татар эпосында архаик катламнардан алып, мөселманлык чорындагы дәвергә кадәрге тормыш чалымлана, ә кайвакыт бер үк әсәр сюжетында әлеге катламнар гармоник дәрәҗәдә кушылып-буталып та киткән була. Ә инде эпосның таралу рәвешенә исламның тәэсире дигәндә татар дастаннарының бик иртә китаби-язма рәвеш алу тенденциясен күздә тотабыз. Халык аңына ислам аша үтеп кергән китапка, язуга хөрмәт татар эпик фольклорына хас дастаннарның язма-китаби формада үсеп китүенә бик нык йогынты ясаган. Шуңа күрә татар халык иҗатында язма әдәбият белән фольклор чигендә тора торган китаби эпос башка төркиләргә караганда ныграк үсеш алган да.

Батырлык темасына багышланган яисә мәхәббәт сюжетына корылган татар дастаннары милләтнең тарихын, көнкүрешен, рухи кыйммәтләрен чагылдыра. Татар дастаннарының героикага нигезләнгәннәрендә курку белмәс батыр көрәшченең яуда зур җиңүләргә ирешүе, гашыйклар тарихына багышланганнарында исә ике гашыйкның мәхәббәт тарихы сурәтләнә. Ләкин әлеге әсәрләрнең әһәмияте батырлык яки мәхәббәт тарихын бәян итү белән генә чикләнми. Татар дастаннары әле Идел буе Болгары чорыннан ук ислам белән, дини идеология белән тыгыз бәйләнештә һәм бу – аларның җитди үзенчәлеге. Алай гына да түгел, гомумән, татар дастаны, бигрәк тә аның китаби төре, гасырлар буена язма мәдәният һәм ислам йогынтысында формалашкан. Идел һәм Урал буйларында гына түгел, гомумән Евразия далаларында таралып яшәүче татарларда киң таралып, татар дастаны халык тормышында эмоциональ-экспрессив дәрәҗәдәге рухи азык, тәэсирле язма укып, күңел юату, вакыт уздыру чарасы гына булмыйча, тарихның халык өчен хәлиткеч әһәмияткә ия бер этабында үзенә күрә бертөрле идеологик функция дә үтәп килгән.

Дөнья, шул исәптән татар, рус һәм башка милләт галимнәренең фәнни-теоретик концепцияләрендә халык иҗатында эпик стиль һәм эпик семантика һәрвакыт конкрет тарихи җирлек белән бәйләп каралырга тиеш дигән фикер уздырыла [2, б. 15]. Эпос стиленә һәм эпос семантикасына хас сыйфатларның төп җирлеген конфессиональ, милли, социаль, географик, хронологик пландагы тарихи нигез барлыкка китерә, татар дастаннарының төп асылын билгеләүдә дә әлеге нигез турыдан-туры роль уйный. Бу шактый катлаулы тоелган фәнни концепцияне аңлау өчен татарларның тарихи тормыш итү рәвешләрен, аларның фольклорында һәм әдәбиятында нәрсәгә өстенлек бирүләрен күзәтү җитә. Татарларның исламда булуы, аларда язмачылык, укымышлылык, мәгърифәтнең югары дәрәҗәдә булуы халыкның эпик иҗатына үз эзен салган.

Как указано в научной литературе, мастера слова пишут стихотворения «здравствуй, о Рамазан» месяцу, которого ждут как гостя, слова с таким содержанием распространялись от сердца к сердцу. А когда наступает обряд, говоря «Прощай, о Рамазан», скорбно читали прощальные стихи. Стихотворением, написанным для священногоРамазана, в частности, является следующее:

***Sən gəlincə***cümlə aləm nur olur,
Ayan olur camilər məmur olur.
Sənə izzət etməyənlər xar olur,
***Əlvəd***a, ya şəhri-ramazan əlvəda.
Sən ***gəldin etdin***kəlami,
***Sən gedənde***birdən eylə salamı.
Əcəl aman veiib birdəxi görsəm səni,
*Əlvida,*ya şəhri-ramazan! əlvida! [9].
***Когда приходишь ты, весь мир светом освещается****,*
*Все мечети и молельни бывают готовы.*
*Те кто не уважают тебя пусть опозорятся,*
*Прощай, о Рамазан, прощай.*
*Ты пришел, промолвил слово*
*Уходя попрощаться не забудь,*
*Если судьбе будет угодно, еще увижусь с тобой*
*Прощай, о Рамазан, прощай! [9].*

Такимобразом, в результате исследования было выяснено, что:

~ обряд жертвоприношения является одним из древнейших ритуальных формул человеческой культуры. Невозможно найти такой народ мира, у которого в его культурной истории не было бы обряда жертвоприношения;

~ Жертвоприношение является событием генетической структуры в истории Азербайджанской культурной истории. Фольклорная память несет в себе следы самых разных форм жертвоприношения. Существующие в Азербайджане многочисленные места поклонения в какой-либо форме связаны с жервтоприношением.

~ Отмечаемый в настоящее время как официальная государственная церемония праздник Курбан непосредственно связан с основами Ислама. Наш народ, поклоняющийся вере в единого Аллаха, исполняя этот прекрасный обряд Ислама веками, превратил его в органичную часть нашей национальной культуры.

~ проведенные наблюдения за фольклорной жизнью во время месяца Рамазан в Азербайджане показали, что этот праздник, связанный непосредственно с Исламской религией, приобрел в нашей стране ряд местных свойств, то есть фольклорную специфику. Согласно полученным из воспоминаний сведениям, эти традиции жили в досоветскую эпоху в проводимом с большим воодушевлением месяце Рамазан. Однако проводимая советским государством беспощадная борьба с религиозными обычаями и традициями стала причиной исчезновения большинства из этих обычаев, превращения в пассивный материал воспоминаний.

**Литература**


1. Бекки С.Курбан в тюркской мифологии //Издание академических исследований. Стамбул: 1996, стр. 16-28 (на турецком языке)
2. Джафарова А. Ордубадская фольклорная среда. Диссертация на соискание ученой степени кандидата филологических наук. Баку (на азерб.языке).
3. Элиаде М. Миф вечного возвращения / перевод Умит Алтуг. Стамбул: издание Имге, 1994 (на турецком языке).
4. ЭрджиласунА.Б. Словарь тюркских диалектов. том 1, Анкара: 1999 (на турецком языке).
5. Гусейнов Р. Новруз - лекало вечной гармонии и равновесия / Новруз в Азербайджане (сборник). Баку: Светильник, 2012, стр. 92-96 (на азерб.языке).
6. Энциклопедия ислама. II т. (на турецком языке).
7. Махмуд Кашгари. Словарь тюркских наречий. ИзданиеБ.Аталая. Анкара: 1992, I т., 530 стр.; II т., 366 стр.; III т., 462 чтр. (на турецком языке)
8. Коран / перевод с арабского языка: З.Бунядов vә В.Мамедалиев. Баку: Азериздат, 1992, 714 стр.(на азерб. языке)
9. Ниязов А. Секты на северо-западе Азербайджана в XIX веке. Баку: 2016(на азерб.языке)
10. Сайылов Галиб. Личный архив.


УДК 372.882

# ОБРАЗ ЗМЕИ В МИРОВОЙ МИФОЛОГИИ И ФОЛЬКЛОРЕ
# ДӨНЬЯ МИФОЛОГИЯСЕНДӘ ҺӘМ ФОЛЬКЛОРЫНДА ЕЛАН ОБРАЗЫ

***Сахабиева Альбина Мансуровна***
МБОУ «СОШ №2 им. Героя Советского Союза, Маршала Советского Союза
Говорова Л.А.» Елабужского муниципального района Республики Татарстан,
г. Елабуга, Татарстан, Российская Федерация
*e-mail: sakhabieva-a@mail.ru*

**Аннотация.** *В статье рассматриваются о том, что и в творчестве народов мира, и в татарской литературе образ змеи выполняет довольно сложную функцию. Змея - хранитель спокойствия, благополучия племени, страны, дома, гармонии на всем земном шаре, приносящий смерть и мудрость.*

**Ключевые слова:** *символические и мифологические значения змеи; противоречивый и многогранный персонаж; сказки; легенды и предания; фольклор разных народов; четыре типа змей; добро и зло.*

# THE IMAGE OF A SNAKE IN WORLD MYTHOLOGY AND FOLKLORE

***Sahabieva Albina Mansurovna***
MBEI "Secondary School No. 2 named after Hero of the Soviet Union, Marshal of the Soviet Union Govorov L.A." of the Elabuga Municipal District of the Republic of Tatarstan, Elabuga, Tatarstan, Russian Federation.

**Abstract.** *The article discusses the fact that both in the creative work of the peoples of the world and in Tatar literature, the image of a snake performs a rather complex function. The snake is the guardian of peace, well-being of the tribe, country, home, harmony all over the globe, bringing death and wisdom.*
**Keywords**: *symbolic and mythological meanings of the snake; contradictory and multifaceted character; fairy tales, legends and legends; folklore of different peoples; four types of snakes; good and evil.*

Елан – төрле халыклар фольклорында иң киң таралган образларның берсе. Барлыкка килүе белән үтә дә борынгы чорларга тоташып, еллар, гасырлар узу белән капма-каршы үзгәрешләр кичергән катлаулы да, каршылыклы да персонаж ул. Еланның символик һәм мифологик мәгънәләренең киңкырлыгы, хәтта полярлыгы аның табигате белән аңлатыла. Билгеле булганча, еланның теле ике якка очлаеп тора – ягъни бер як изгелекне, көчне символлаштырса, икенче якны явызлык дип аңларга җирлек кала. Елан агуының мизгел эчендә кешене үтерә алуы мәгълүм, шул ук вакытта аны искиткеч дару итеп тә кулланырга мөмкин. Бу күренеш тә еланнарны ике төрле көч – изгелек һәм явызлык итеп күзаллрга этәргеч бирә. Моннан кала еландагы күп кенә сыйфатлар кешене сокландырган да, шомландырган да. Мәсәлән, тиресен салып, мәңге яшь калуы; кош һәм ваграк җәнлекләрне гипнозлый алу сәләте һ.б. Бу күренешләр барсы да еланнарга бәйле риваятьләр, легендалар тууга җирлек әзерләгән.

Кайбер мифларда еланның вазифасы тагын да катлауландырыла. Мәсәлән, борынгы һиндларның карашынча, Дөнья Еланы Шеша Җирне үз җилкәсендә тотып тора. Охшаш моментларны Мисыр һәм Скандинавия халыклары мифларында да очратып була. Борынгы Грециядәге дәвалау алласы Асклепий да елан рәвешендә күзалланган. Алай гына да түгел, мифлар буенча, нәкъ менә еланга карап, ул үлеләрне терелтү серләре хакында уйлана башлаган. Борынгы Мисырда табипларны саклаучы алиһә Изиданың гәүдәсе елан белән чорналган рәвештә тасвирланган.

Еланнарның тиреләрен алмаштыра алулары аларны яшьлек, акыллылык символы итеп күзаллауга этәргеч биргән. Борынгы грек мифологиясе буенча, Зевс кешеләргә гаҗәеп бүләк – яшьлекне кире кайтаручы дару-чара бирә. Әмма кешеләр аны үзләре күтәреп барырга теләмичә, ишәк өстенә менгерәләр, ишәк аны еланга бирә. Шуннан соң кешеләр картлык җәфасын кичерергә мәҗбүр булалар, ә еланнар мәңгелек яшьлек белән бүләкләнәләр. Борынгы Африка халыкларында тән тиресен алмаштырып, мәңге яшь кала торган һәм үлемсез кешеләр турында әкиятләр, легендалар яшәгән.

Мифология һәм халык авыз иҗатында урын алган башка җәнлекләр, кошлардан еланнар һәрчак аерылып торганнар. Еш кына мифлар аларны поляр рәвештә аерып куйганнар. Күренекле фольклорчы галим Ф. Урманче, мәсәлән, елан образы белән бәйле түбәндәге мәгълүматларны хәбәр итә: “Евразия сәнгатендә кошлар Күк, Кояш патшалыгын гәүдәләндерәләр. Еланнар түбән дөнья (Җир асты яисә Су асты патшалыклары) вәкилләре буларак күзалла624налар. Индуизм мифологиясендәге гигант кош Гаруданың һәм Еланнарның – нагларның үзара көрәше Борынгы Шәрекъ мифларында киң чагылыш таба” [4, б. 32].

Елан образы Галәм, космос белән бәйле булган мифларда да очрый. Мәсәлән, Евразия һәм Америка мифларында ул – Күкне Җирдән аерып торучы, Җиһандагы гармонияне саклаучы. “Бу җәһәттән Австралия аборигеннары мифларында таралган Елан – салават күпере, Күк еланы образлары игътибарга лаек, – дип яза Ф.И.Урманче. Аның турындагы күзаллаулар уңыш, Җир-ана һәм яңгыр образлары белән бергә йөри. Күк суын эчүче яңгыр

хуҗасы елан – салават күпере образы Көньяк-Көнчыгыш, Көнчыгыш һәм Көньяк Азия халыкларында киң таралган. Төньяк-Көнчыгыш Һиндстанда гомер итүче мунда халыкларында сакланган миф буенча, Елан – салават күпере аллалар тарафыннан кешеләргә каршы җибәрелгән ут яңгырын туктата" [4, б. 35 – 37].

Күп кенә халыклар мифологиясендә еланнар – су, елга, чишмә, хәзинәләрне, гыйлемне саклаучылар. Африка кабиләләренең күзаллаулары буенча, сулыкның сай яисә тирән булуы шунда гомер кичерүче Изге еланнарның кодрәтенә турыдан-туры бәйле. Димәк, бу кабиләләрнең бай яки ярлы булуы да еланнарга бәйле саналган.

Еланнарны ихтирам итү, олылау яисә киресенчә, аннан курку, аны дошман сыйфатында күрү халык авыз иҗатының бихисап күп жанрларында урын алган. Елан образы бирелгән мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар халык мирасында шактый күп. Әмма әкият жанры бу җәһәттән аерым игътибарга лаек. Белгечләр фикеренчә, әкиятләрдә, башкарган вазифаларына бәйле рәвештә, дүрт тип елан хәрәкәт итә: 1) урлаучы елан (Змей-похититель); 2) ришвәтче елан (Змей, занимающийся поборами ("поборы змея"); 3) чикләрне саклаучы елан (Змей – охранитель границ); 4) йотучы елан (Змей-поглотитель) [1, б. 18]. Шулай ук кайбер галимнәрнең әлеге классификациягә "Аздыручы елан" (Змей-соблазнитель) образын да кертүләре мәгълүм. Әмма татар әкиятләренә күчергәндә, бу классификация бик үк туры килеп бетми. Монда күрсәтелгән вазифаларны безнең әдәбиятта елан белән бәйле башка образлар башкаралар. Мәсәлән, урлаучы елан вазифасын еш кына дию башкара, ришвәтче (кыз таләп итүче) елан урынына күбрәк аждаһаны күрәбез. Аздыручы елан ролен татар әкиятләрендә юха елан башкара. Шунсын да искәртеп үтү кирәк, татар халык иҗатына караган кайбер чыганакларда еланнар ак һәм кара төрләргә бүленеп, үзара дошман булып килүләре очрый. Болардан ак еланнар, кайбер очракларда аларның патшасы дип Шаһмара елан бирелә, уңай персонажлар булып киләләр. Кеше белән елан арасындагы туганлык мөнәсәбәтләре дә иң борынгы татар әкиятләрендә, риваятьләрендә уңай бәяләнә. Кеше белән еланның никахка кереп бәхетле гаилә корулары, кешедән елан баласы туу кебек сюжет үстерелеше татар әкиятләре өчен ят күренеш түгел. Соңрак чорга караган юхалар хакындагы әкиятләрдә инде юха образындагы сылу кыз яисә егет, төп герой белән никахлы мөнәсәбәтләргә кереп, аның авыруына, үлеменә сәбәпче булып тора.

Төрки-татар мифологиясендә елан- Алла дәрәҗәсендә торган зат. Мәслән, Алабуга янында булган Шайтан шәһәрлеге турындагы легенда игътибарга лаек. Ул чик, вазифасын башкарыр өчен салынган. Легенда буенча, анда бик зур елан – аждаһа яшәгән, ә тирә-юнь халкы аңа табынган, корбаннар китергән. Шәһәр тормышына куркыныч янаган очракларда алар, ярдәм сорап, аңа мөрәҗәгать иткәннәр. Ләкин монголлар һөҗүме (кайбер версияләр буенча – Явыз Иван Казанны яулап алган вакытларда) алдыннан елан шәһәрдән очып китә, шәһәрнең тиздән дошман кулына төшәчәген хәбәр итә. Саклаучысыз, яклаучысыз калган шәһәр дошман явын җиңә алмый.

Нәтиҗәдә шуны әйтергә кирәк, дөнья халыклары иҗатында да, татар әдәбиятында да елан образы шактый катлаулы вазифа башкара. Ул – кабиләнең, ил-йортның иминлеген, тынычлыгын, бөтен Җир шарында гармония саклаучы да, үлем китерүче дә, зур хикмәт иясе дә.

**Әдәбият**

1. Борынгы татар әдәбияты / Төз. Х.Мөхәммәтов, Х.Хисмәтуллин, Ш.Абилов, Ү.Беляева. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. – 580 б.
2. Кун Н.А. Легенды и мифы Древней Греции. – М.: Олимп, 2000. – 544с.
3. Татар халык әкиятләре / Төз. Х.Ярми, Х.Гатина. – Казан: Раннур, 1999. – 384 б.
4. Урманче Ф. Татар халык иҗаты. – К.: Татар. кит. нәшр., 2005. – 156 б.

УДК 821.512.145

# ОПИСАНИЯ ПРИРОДЫ, СОЗВУЧНЫЕ ЧЕЛОВЕЧЕСКОЙ ДУШЕ В ТАТАРСКОЙ ПРОЗЕ
# ТАТАР ПРОЗАСЫНДА КЕШЕ КҮҢЕЛЕНӘ АВАЗДАШ ТАБИГАТЬ ТАСВИРЛАРЫ

***Смирнова Айгуль Фаниловна***
Детский сад комбинированного вида № 4 “Веселинка”,
г. Набережные Челны, Татарстан, Российская Федерация
*e-mail:aigulfan@mail.ru*
***Салахутдинова Зифа Фаниловна***
Технический колледж имени В.Д. Поташова,
г. Набережные Челны, Татарстан, Российская Федерация
*e-mail: sal-zifa@yandex.ru*

**Аннотация.** *В статье внимание акцентировано на описание образа природы, созвучное человеческой душе, которое является первостепенным в татарских прозаических произведениях. Писатели воспевают явления природы и ее отражение, что помогает раскрыть душевные переживания человека, его мысли, чувства и цепочку событий в жизни.*

**Ключевые слова:** *образ; духовные качества; описание природы; лирические отступления.*

# DESCRIPTIONS OF NATURE CONSONANT WITH THE HUMAN SOUL IN TATAR PROSE

***Smirnova Aigul Fanilovna***
Kindergarten of combined type No. 4 “Veselinka”,
Naberezhnye Chelny, Tatarstan, Russian Federation
***Salakhutdinova Zifa Fanilovna***
V.D. Potashov Technical College,
Naberezhnye Chelny, Tatarstan, Russian Federation

**Abstract.** *The article focuses on the description of the image of nature, consonant with the human soul, which is paramount in tatar prose works. Writers glorify the phenomena of nature and its reflection, which helps to reveal a person's emotional experiences, his thoughts, feelings and the chain of events in life.*

**Keywords:** *image; spiritual qualities; description of nature; lyrical digressions.*

Татар әдипләре табигатьне үзләре кабул иткәнчә, үз күңелләре аша уздырып сурәтлиләр, ә геройларын шул табигать тасвирлары эчендә ачалар. Әдәби әсәрдә табигатьне тасвирлау формалары бик күп.

Пейзаж шуның бер төре булып тора, һәм әсәрдә ул тирән мәгънә эчтәлегенә ия. “Һәр язучы иҗатында пейзажның вазифасы, әсәр структурасына ул сала торган мәгънә төрле. Татар әдәбиятында пейзаж сурәтләре үзенчәлекле әдәби-эстетик вазифа башкара: алар кешене сурәтләүдә катнаша. аның холык-фигыле белән янәшә ниндидер “чиктәш” халәтне ача” [1, б. 135-136].

Элек-электән кешеләр үзләрен табигатьнең бер өлеше дип санаганнар һәм моны сәнгатьчә чагылдырырга омтылганнар. Алар еш кына үзләре яшәгән дөньяны, тирәлекне, йортны пейзаж атамалары белән алмаштырганнар һәм шул юл белән метафорик образлар ясаганнар. Әйтик, күп кенә әдәби әсәрләрдә бик яратып бакча образы кулланыла. Мәгълүм булганча, кешенең эчке дөньясын да күңел бакчасы дип атыйлар. Оҗмах бакчасы, мәхәббәт

бакчасы, белем бакчасы... Табигать предметлары, пейзаж ярдәмендә ясалган мондый рәтләрне бик күпләп тезеп булыр иде. Без, кабатланмас өчен, аларны берәрдән генә саныйбыз: сөю сукмагы, күңел күге, рәхәтлек диңгезе, хисләр карурманы, ачу болыты, белем дәрьясы һ.б.

Татар язучылары пейзажны бик үзенчәлекле тудырырга тырышалар, һәркем күргәнен үзенчә белдереп калырга ашыга. Һәр язучының үз пейзаж поэтикасы бар. Роман һәм повестьларда, кече күләмле әсәрләрдә дә табигать тасвирлары кеше күңеленең мизгелләрен тудыруда бик зур роль уйный. Мәсәлән, Фатих Әмирханның «Хәят» повестенда шәһәр күренешләрен сурәтләүгә бик күп урын бирелгән, чөнки авторга рус һәм татар тормышын каршы куярга да, аларның югары катламнарының яшәү рәвешендәге аерым уртаклыкларны күрсәтергә дә кирәк.

«Майның бер якшәмбесе, көндезге сәгать өчләр иде. Бер сәгать кенә моннан әүвәл явып киткән жиңел яңгыр шәһәр урамнарының тузанын баскан һәм, һавадагы кызулыкны җиңелчә язгы жылылык белән алмаштырып, көнне ямьлелекнең чигенә ирештергән иде. Әле һаман һавадан җуелып бетмәгән яз җиле, кояш батышы ягыннан аерым бер акрынлык вә тынычлык белән исә дә, дөньяга яңару вә яшәрү исләре чәчә һәм бөтен җанлы вә җансыз нәрсәләрне үзләренә бертөрле тереклектә коендыра иде»[3, б. 112], – дип башлана әсәр. Язгы үзгәрешләр кичереп утырган шәһәр күренеше тасвиры белән әнә шулай матур башланган әсәр алга таба да шулай матур дәвам итә, табигатьнең үзе кебек яшь, матур кыз белән танышабыз: “...16-17 яшьлек чандыррак (ябыграк) кына гәүдәле, уртача буйлы, зәңгәрсу күзле, кыскарак, ләкин бик куе сары чәчле бер кыз төште дә җиңел адымнар белән ашыкмый гына капкадан кереп китте”[3, б. 113].

Хәят белән Лиза татарлар күбрәк торган урамнардан да, руслар яшәгән җирләрдән дә бергәләп узалар. Алар Идел ярларынада килеп чыга һәм табигать матурлыгы белән хозурлана. Иделдән күтәрелгән юеш һава, кырлардан килгән йөз төрле чәчәк исләре, күктә очып йөргән вак-вак кошчыклар – болар барысы да Хәят күңелен рәхәтләндерәләр. Күбәләкләр көләч йөзле чәчәкләр белән үбешеп, әйтерсең, Хәятнең мәхәббәт иленә кереп баруыннан безгә хәбәр җиткерәләр.

Безнең фикеребезчә, бу дөньяның мәгънәсе, табигать музыкасының һәр яңгырашы, бәлки, геройларга тулаем аңлашылып та җитми торгандыр. Язучы, бу хакта әйтеп, инде Хәятның үзенә бик үк ачык булмаган хис-кичерешләр дәрьясында каласын да искәртә кебек.

Мясниковлар дачасының тасвиры да бар әсәрдә. Анда бик матур бизәлгән, җыйнак балконнар чыгарып эшләнгән жәйге өй, урманның бер кисәген койма эченә алып ясалган бакча бар. Читләренә чәчәкләр тезелгән юллар, ис аңкыткан топольләр – барысы да кызда яңа хисләр туугa җирлек хәзерлиләр. Сөй дә сөел генә инде! Әлбәттә, шулай булып чыга. Дачада җыелган яшьләр арасында кайберәүләрнең татар кызына, үзе дә табигатьнең бер чәчәге булып тоелган Хәятка, гыйшкы төшә.

Безнең фикеребезчә, аеруча таңга күзен ачкан тәрәзәләрнең, бакча сурәтенең укучыга тәэсире зур, чөнки ул тәрәзәләрнең берсеннән әлеге дә баягы Хәят карап тора. Ф. Әмирхан бу урында, шагыйрьләр каләменәрәк хас булганча, мәхәббәт символларына мөрәҗәгать итә. Сандугач һәм аның сөекле гөле... Кошның моңлы авазларын Михаил кыз матурлыгы хакындагы җыр дип атый.

Әлеге матурлыкны өзмәс өчен, әсәрдәге иң матур урыннарны, күңелне ял иттергән, Хәятның күңеленә аваздаш, аның бәхетле көннәренә туры килгән табигать тасвирларын гына мисал итеп китердек. Билгеле булганча, безне чорнап алган дөнья һәрвакыт үзгәреп тора. Таңда чәчәк аткан гөлләр кичен сулырга, кичтән тынган җилләр иртән давылга әйләнергә мөмкин. Талантлы язучы, табигатьнең шул үзгәрешләрен белгәнгә, пейзажны һәрвакыт мулдан, әмма төче сөйләп туйдырмаслык итеп куллана.

Татар прозасында Г.Ибраһимовның табигать картиналары да мөһим урын алып тора. Аның әсәрләрендәге үзенчәлекләрнең берсе үзе туып-үсеп, канат чыгарган якларының колориты киң колачлы ижатында зур урын алып торудан гыйбарәт. Язучының пейзаж поэтикасы динамик, хәрәкәтчел сыйфатларга ия, психологизм һәм лиризм сферасына үтә нечкә килеп керә. Аның әсәрләрендә табигать тасвирларының гади, ачык һәм эзлекле булуын

язучының табигатьне кеше тормышында бик кирәкле, аннан башка, гомумән, тормыш юк дип каравы белән аңлатырга кирәк.

Шуның беренче матур, тулы үрнәге итеп Г.Ибраһимовның “Яз башы” хикәясен санарга мөмкин. Бу әсәр “кеше рухи дөньясына үтеп керү көчендә, аның фикер һәм хис хәрәкәтен бирү, табигать күренешләрен җанландырып сурәтләү осталыгында, әдәбиятның төп коралы булган тел белән оста эш итүендә, аның һәртөрле төсмерләрен нечкә тоя һәм файдалана белүендә күренде”[3, б. 339].

Табигатьне барлык нечкәлекләре белән тасвирлау – Галимҗан Ибраһимовның характерлы алымнарыннан берсе. Бу осталык һәр күренешкә ия үз буявын таба белүгә һәм сәнгатьлелеккә ирешүдә тел чараларын уңышлы куллануга бәйләнгән. Табигать күренешләрен тасвирлаганда телнең төрле поэтик сурәтләү чаралары ярдәмендә Г.Ибраһимов кабатланмас образлар тудыра. Язучы чагыштыруларны бик уңышлы куллана: “Бу киң вә дулкынлы үлән диңгезенең нәкъ уртасыннан назлы кыз йөреше кеби боргаланып-боргаланып аккан елга үзенең көмештәй ялтыраган төсе белән бөтен тирә-якның күркен әллә ничә кат арттырып җибәрә” [2, б. 7].

Г.Ибраһимовның әсәрләрендә табигать картиналарын – болыт, яңгыр, җил-давылларын тасвирлау һәм моңа бәйле рәвештә психологик контрастлар, параллелизмнар, каршы һәм янәшә куюлар еш очрый. Автор еш кына онтологик күренешне (кешенең эчке халәте белән үзен мөстәкыйль калдыру, яисә табигать, яисә җәмгыять белән калу) чагылдыра. Безнең очракта геройлар табигать стихияләре (көчле җил, буран һ.б.) белән күзгә-күз очраша. Геройларның эчке халәтен ачар өчен автор күк күкрәүләргә, яңгырларга, жил-давылга, йолдызларга һ.б. табигать образларына мөрәҗәгать итә. Табигатьтәге халәт туп-туры кешегә күчерелә.

Язучы табигать хозурлыгыннан иң беренче үзе ләззәт кичерә һәм шушы сихри гүзәллекне укучыга оста җиткерә белә. Укучы, һәрбер юлдан тәм табып, әсәрнең эченә, “моңнар иленә”, “әкият дөньясына” тирәнрәк керүен сизми дә кала: “... Без шулар, шул матурлыклар уртасыннан, шул моңнар эченнән, табигатьнең өстеннән ярып барабыз... Әнә безнең алдыбызда – барачак юлыбызда, киң яшел ялан белән биек һәм урманлы тау уртасында зур, түгәрәк сихерле күл ялтырый... Ничаклы матурлык!” [2, б. 8].

Авторның табигатьне кеше белән бәйләнештә тасвирлавында ике үзенчәлекне билгеләп үтү мөһим. Беренчесе: табигать тасвирлары булачак вакыйгаларга фон рәвешендә бирелә дә, геройларның киләчәктәге язмышлары хакында хәбәр җиткерелә. Кешеләр нәфесен табигать күренешләре тулы ачып бирә. Икенчесе: табигать хозурлыгын сурәтләп, алдагы вакыйгаларга, кеше халәтенә ишарә ясамыйча, коллизик моментларны кинәт бирә. Бу очракта пейзаж сурәтенә аерым игътибар туа һәм ул импрессионистик күренешләрне хәтерләтә башлый. Автор үз геройларын үзе сурәтләгән табигать белән гармониядә булуларын әйтеп, аңлатып бара. Язучының табигатьне шул рәвештә тасвирлавы тормышның чын табигый матурлыгын күрсәтергә теләве белән аңлатыла.

“Казакъ кызы”, “Диңгездә”, “Табигать балалары”, “Яшь йөрәкләр” һ.б. әсәрләрдә дә табигать тасвиры геройларның язмышына һәм әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларга әхлакый-фәлсәфи шәрехләү рәвешендә килгән.

Г.Ибраһимов совет дәверендә язган әсәрләрендә дә табигать белән кеше мөнәсәбәтенә мөрәҗәгать итә. Табигать күренешләре аша дөньяга карашын, тормыш фәлсәфәсен чагылдыра. Язучының “Кызыл чәчәкләр” әсәрендәге табигать тасвирлары баш геройларның язмышына һәм әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларга барып тоташа. Повестьның төп өлеше авыл күренешен тасвирлаудан башлана. Алар арасында күзгә иң ташланып торганы – Зәңгәр Чишмә тасвиры. Язучы аны табигатьнең гүзәл бер почмагы итеп күрсәтә. Кечкенә күлне диңгезгә тиңләгән әдип, бакчада үскән чәчәкләрне, болыннардагы печәннәрне яратып сурәтли: “...урманнарда меңәр еллык карт наратлар, чыршылар җәен-кышын яшәреп, шаулашып утыралар; елгалар, күлләр буеннан сөзәк сырт булып җәелеп киткән киң басулары шундый бәрәкәтлеләр ки, вакытында җылы яңгыр яуса, кояшлы аяз көннәр булса, бу яланнарның мамык кебек йомшак, көзге төн болытлары кебек куе кара туфраклары ярты дөньяны

туйдырырлык нигъмәтләр бирәләр” [1,б. 290]. Шул рәвешле, язучы табигатьнең биниһая чиксез рухын, мәңгелеген, бетмәс-төкәнмәс матурлыгын, төсләр, исләр байлыгын укучысына җиткерергә омтыла. Авылның табигатькә бәйле күренешен тасвирлаганнан соң, автор авыл халкының йорт төзелешләрен тасвирлауга күчә: “Авылның уртасында зур базар кайный: аның ике ягыннан биек матур сарайлар, зур тимер йозак белән бикләнә торган ак таш кибетләр тезелеп китәләр...” [1, б. 291]. Г.Ибраһимов шуннан соң бай кешеләрнең өйләрен, аннан ярлы тормышлы кешеләрнең каралтыларын сурәтли. Шул рәвешле, әдип геройларның төрле социаль катламнан булуларын күрсәтә.

Табигать образлары ярдәмендә, автор матурлык белән ямьсезлек, яхшылык белән яманлык хакындагы фикерләрен киң җәмәгатьчелек игътибарына җиткерә. Табигать күренеше ярдәмендә ул үз героеның яшәешен, табигатькә булган мөнәсәбәтен, күңел дөньясын күрсәтә, ил күләмендә барган канлы вакыйгаларны, сыйнфый көрәшне ачуга ирешә. Алар ярдәмендә предмет, күренешләргә кешенең күңел дөньясы, хис-кичерешләре, иҗтимагый-сәяси мәсьәләләре белән аналогия үткәрә.

Күргәнебезчә, Г.Ибраһимовның табигать матурлыгын бирү осталыгы, ихлас соклана белүе, табигать образларының күп төрлелеген һәм күп яклыгын сурәтләве, геройларның характерын әсәрдәге вакыйгалар белән үткер бәйли белүе һәм, шул рәвештә, психологик контрастлар, янәшә куюлар, гомумән, кеше мөнәсәбәтен гәүдәләндерүгә табигать аша килүе – гаять кызыклы поэтик функция үти.

Гомумән, татар әдәби әсәрләрендә табигать тасвирлары әнә шулай кешенең күңел дөньясына аваздаш итеп бирелә. Татар язучылары табигатьнең кеше тормышында бик әһәмиятле роль уйнавын яхшы аңлыйлар, шуның өчен үз әсәрләрендә аңа зур урын бирәләр, кешенең рухи дөньясындагы үзгәрешләрне, чор вакыйгаларын, гомум проблемаларны табигать сурәте аша ачалар.

**Әдәбият**


1. Әдәбият белеме. Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.
2. Ибраһимов Г.Г. Хикәяләр, повесть, роман / төз. Р.Акъегет. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 463 б.
3. Хәсәнов М. Галимҗан Ибраһимов // Татар әдәбияты тарихы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – Т. 3. – Б. 338-357.


УДК 821.512.154

## ОСОБЕННОСТИ ВОСПИТАНИЯ МОЛОДЕЖИ НА ОСНОВЕ ИДЕОЛОГИИ ПРОИЗВЕДЕНИЙ Ч.Т. АЙТМАТОВА

***Утанова Суйумкан Кимсановна***
Ошский гуманитарный педагогический университет,
г. Ош, Кыргызская Республика
*e-mail:kerben1996@mail.ru*

***Аннотация.*** *В данной научной статье оценим, которые занимает Чингиз Айтматов в фольклоре и педагогике. Как известно, сквозь все произведения Ч. Айтматова красной нитью проходили самые сложные проблемы в нравственно-воспитательной среде общества. В статье рассматриваются произведения писателя, посвященные истории, культуре и традициям кыргызского народа. Также анализируем труды и отзывы его произведение, которые ранее изучали место и роль произведений Ч.Т. Айтматова на мировой литературной арене.*

*Во всех его произведениях, на любом уровне лежит идея о защите природы. Экологическое воспитание произведений Ч. Айтматова, в данное тяжелое для человечества время, без сомнения служит лучшим средством в экологическом образовании и воспитании молодежи жить в гармонии с природой. Основными идеями его произведений являются устранить эгоизм человечества, который представляет угрозу природе, гармонизировать отношения между человеком и природой.*

**Ключевые слова:** *этнопедагогика; человечество; литература; кыргызский язык; общечеловеческие ценности; цивилизация; экология.*

## FEATURES OF EDUCATION OF YOUTH ON THE BASIS OF THE IDEOLOGY OF CH.T. AITMATOV'S PRODUCTION

***Utanova Suiumkan Kimsanovna***
Osh Humanitarian Pedagogical University, Osh, Kyrgyz Republic

***Abstract.*** *In this scientific article, we will evaluate what Chyngyz Aitmatov occupies in folklore and pedagogy. As is known, the most difficult problems in the moral and educational environment of society ran like a red thread through all the works of Ch. Aitmatov. The article deals with the works of the writer dedicated to the history, culture and traditions of the Kyrgyz people. We also analyze the works and reviews of his work, which previously studied the place and role of the works of Ch.T. Aitmatov in the world literary arena.*

*In all his works, at any level, there is an idea about the protection of nature. The environmental education of Ch. Aitmatov's works, in this difficult time for mankind, undoubtedly serves as the best means in environmental education and upbringing of young people to live in harmony with nature. The main ideas of his works are to eliminate the egoism of mankind, which poses a threat to nature, to harmonize the relationship between man and nature.*

**Keywords:** *ethnopedagogy; humanity; literature; Kyrgyz language; universal values; civilization; Ecology.*

В настоящее время в системе образования в республиканских школах, ВУЗах большую роль вопросы этнопедагогики. Одной из величайших целей человечества является воспитание подрастающего поколения в духе верности общечеловеческим и национальным идеалам гуманизма. В наше время национально ориентированное воспитание молодежи выделяется как одна из важнейших задач системы образования.

Реформа образования – один из важнейших инструментов, позволяющих обеспечить реальную конкурентоспособность Кыргызстана. «Стратегия вхождения Кыргызстана в число 50-ти наиболее конкурентоспособных стран мира» требует, на наш взгляд, такую содержательную систему образования, которая реально позволит формировать и воспитывать у учащихся способности и навыки познавательной деятельности; умение применять приобретенные знания в области научно-технических достижений, в практической деятельности; стремление использовать накопленные человечеством культурные ценности; умение соизмерять свои потребности с потребностями нашего общества; идейно-нравственные качества личности, ее гражданственность и патриотизм.

Большая морально – идеологическая и воспитательная работа должна проводиться в школах, ВУЗах, трудовых коллективах. Большое государственное и общественное внимание должно отводиться существенному укреплению и развитию в стране современной культуры, передовой цивилизации, основанных на гуманистических, духовных и общечеловеческих принципах жизнедеятельности общества. При этом важнейшим духовно – идеологическим источником воспитательной работы среди населения должны быть труды великих писателей, деятелей культуры, образования и науки [1].

И сегодня проведение в школах и ВУЗах в общественных кругах идейно – воспитательной работы по пропаганде передовых идей, изложенных в произведениях Чингиза Айтматова, является крупной актуальной идеологической задачей нашего времени.

Духовность народа содержит в себе такие непреходящие ценность, как чувство уверенности в своём настоящем и будущем, чувство национальной гордости, патриотизма, любви к Родине.

В современном смысле духовность воспринимается как первенство высших духовных ценностей, которые возникают не стихийно: они являются результатом целенаправленной, творческой интеллектуальной деятельности. К духовным творцам исторически относятся поэты и писатели, в творениях которых проявляются не только уровень их профессионализма, но и элементы духовной избранности – честность, правдивость, высокая нравственность.

Духовные ценности из поколения в поколение обогащаются новым содержанием, наращиваются. Но подлинную значимость они обретают тогда, когда доводятся до широкого круга людей, становятся частью их жизни, что достигается через просвещение народа [2].

К таким писателям - воспитателям душ человеческих – относится Чингиз Айтматов, мировая литературная величина. Его произведения, в частности «И дольше века длится день», поражают своей силой и нравственной чистотой. Писатель – мыслитель поднимает глобальные проблемы современного человечества.

В связи с этим необходимо сделать акцент на мыслях Ч. Айтматова о самом себе, о том каким великим и редким человеком был он на протяжении всей жизни. В настоящее время с этим именем тесно связаны все сферы исторического развития кыргызской национальной духовной жизни. Имя

Ч. Айматова будет известным еще несколько тысяч лет. Исходя из истории и убеждений, считается, что это гордое имя было ярким явлением в фольклоре XX века. Это не только слова соотечественника или вымышленное сверхчеловеческое хвастовство, а реально доказанный факт. Произведения Ч. Айматова переведены почти на двести мировых языков, книги напечатаны в сотнях тысячах экземплярах, и до сих пор распространяются и тиражируются

Ни одно из произведений не оставит равнодушным читателя. Переживая судьбу героев, читатели также выносят что-то важное для себя, что заставляет задуматься, дает надежду и стимул к дальнейшему движению к своей мечте [1, с. 2].

Произведение писателя «Саманчынын жолу», увидев в нем как нужно правильно вести семейную жизнь, какие нормы морали должны соблюдаться

Если в других произведениях Айтматова говорится о правилах семейной воспитании, то в повести «Саманчынын жолу» писатель выражает заботу о своем народе, в этом произведении он описывает храброго героя, который пытается уберечь свой народ от внутренних и внешних врагов. Также в этой повести выражены этнопедагогические ценности, как уже было сказано ранее, писатель в своих работах охватывал множество жанров и использовал разных героев, чтобы пробуждать в людях патриотическое начало.

Во второй части этой же главы под названием «культ кыргызской лошади и воспитательные положения в отношениях Танабая и Гульсарат», рассказывается о жизни тюркских кочевых народов в горных регионах, о том, как кыргызы особенно хорошо относились к лошадям, называя их –«лошадь-крылья человека». Кормя их и воспитывая, они передают какие-то этнопедагогические мысли, это идея образовалась, исходя из отношений Таныбайа с его лошадью Гулсара, которые жили безразлучно, несмотря ни на что [1, с. 3].

«Белый пароход» – это подлинная национальная педагогика, так говорится Момуна и его войне с цивилизацией, здесь рассказывается о том, что главный герой - народный воспитатель. Старик Момун был последователем национальных этнопедагогических всемирных течений цивилизации. Он описывает течение, в котором оказался не по своей воле, и он доказывает свою правоту непокладным трудом. Момун – воспитатель детей, общенациональный хранитель народных традиций и обычаев, и он передаст это все следующим поколениям. Он одинаково с автором описывает Орозкула, который не признает учение народной культуры и

живёт своими представлениями. Момун – скромный народный герой (персонаж), его характер, поведение, вера - полностью взяты из жизни и этики Кыргызского народа.

Проблема взаимоотношений между человеком и природой – одна из основных тем в романе. Двух диких зверей, живущих своей жизнью и по своим законам, автор описывает как полноправных, сознательных персонажей. Они способны думать, разделять добро от зла, заботиться о детях, защищать своих детей, плакать, скучать по ним и чувствовать. Мы знаем об их желаниях, мыслях, отношениях друг к другу. Умело открывая их духовный мир, психологию, автор заставляет читателя полюбить Акбару и Ташчайнара и жалеть их, когда они подвергаются различным несчастьям. Самое главное – писатель противопоставляет друг-другу материнское доброе чувство дикой волчицы с преступными деяниями человека, считающегося хозяином ума [3, с. 4].

Но наш великий, известный писатель не был пленником «Социального реализма». Он создал новый век литературы, создал новый метод в литературе, не смотря на все преграды во времена существования СССР. В это время он написал известную повесть «Джамиля», произведение «Лицом к лицу», в которых он выражает свои претензии к власти. Если бы все люди на этой планете желали друг другу добра, любили друг друга, и все были бы за одно, то, может, и войны бы не было. Давайте обратим внимание на вышеуказанные слова. Великий писатель не только обратился к кыргызскому народу, он обратился ко всему миру. В любом случае, если все люди на этой планете будут любить своих детей, на самом деле не будет войны. Потому что, если начнется война, наше будущее поколение окажется под угрозой смерти. Известный писатель напоминает нам о том, что «любовь» спасет мир: «Я являюсь лишь летящей птицей среди стаи. Я журавль. Темной ночью направляюсь к звездам, думаю о своем. Обращаясь к Богу, говоря о людях я плачу ... О люди, относитесь осторожно к земле, и это облегчит вам путь! От неугасающих огней, от бесконечных войн и от неисправимых дел, и пусть спасут вас люди» (Ч. Айтматов) [3].

Каждое событие в произведении, кажется, в содержательном плане напрямую связано с «Легендой о Манкурте», символизируется с последствиями Аральского моря, к которым приводит манкуртизм. Если в романе «Плаха» в целях выполнения плана по мясу осуществили, придумав истребление сайгаков, то в романе «И дольше века длится день», выполняя указание сверху в экономических интересах, жертвуя «природой-матерью», хлопковые поля безмерно расширялись, русла основных рек, впадающих в Арал Аму-Дарьи и Сыр-Дарьи, повернули в сторону посевных полей, вот такие необдуманные действия привели к таким плачевным последствиям – иссушению Арала. Писатель одним событием описывает в романе плачевное состояние в реальной жизни Аральского моря через переживания и размышления трудовых людей Казангапа и Эдигея, сочетая с ним глобальную проблему современности. В произведении это событие описывается следующим образом: “Перед смертью Казангапа они вдвоем ранней весной съездили на Арал. Оказывается, бедняга, ездил попрощаться со своим морем. Вернулся печальный. Море совсем высохло. Шли десять километров по бывшему морскому дну, превратившемуся в глиняный пустырь, и только тогда окунули свои руки в морскую воду» [3;5].

В результате можно сделать вывод, Кыргызские педагоги также принялись изучать этнопедагогическое воспитание. В силу этого она выступает как мощный фактор воспитания личности, способствуя тому, чтобы с одной стороны, очеловечить чувства человека, а с другой стороны создать человеческое чувство, соответствующее всему богатству человеческой и природной сущности. Необходимо донести человечеству, что родственные чувства существуют не только между людьми, но также между людьми и животными могут быть тёплые чувства.

Ч. Айтматов берёт за основу в своих произведениях народные педагогические произведения, включающие систему моральных ценностей, что, несомненно, помогло ему стать национальным писателем.

## Литература


1. Конгайтиева С.А. Ч. Айтматов - мудрец и этнопедагог Научный аспект – 2019 г.
2. Акматалиев А.А. Айтматов: Аалам жана адам. Тил жана искусство маселелери” Манастан Чыңгыз Айтматовго карай: проблемалар жана көз караштар” [Текст] / А.А. Акматалиев. - Эл аралык илимий-практикалык конференциянын материалдары. - Б.: - 2016. - 127б.
3. Муратов А.Ж. Чыңгыз Айтматов - жазуучу-этнопедагог [Текст] / А.Ж. Муратов. - Б.: 2006. - 201б.
4. Айтматов Ч. Сборник сочинений / Романы, повести. Том 4. – Б.: Шам, 1999.
5. Үкүбаева Л. Чыңыз Айтматов жана кыргыз адабияты Текст] / Л. Үкүбаева. - “Турар”. – Б. 2012. - 68б.


УДК 821.512.145

## «СУННАТЧИ БАБАЙ» НА КАЗАНСКОЙ СЦЕНЕ
## «СӨННӘТЧЕ БАБАЙ» КАЗАН СӘХНӘСЕНДӘ


***Хабутдинова Милеуша Мухаметзяновна***
Казанский (Приволжский) федеральный университет,
г. Казань, Татарстан, Российская Федерация
*e-mail: mileuscha@mail.ru*



**Аннотация**. *В статье анализируются спектакль Р. Аюпова “Суннатчи бабай”. Выявлена специфика художественной интерпретации прозы Г. Исхаки. Определена роль этого спектакля в актерской биографии А. Шакирова и режиссерской биографии Р. Аюпова.*



**Ключевые слова**: *татарский театр, проза Г. Исхаки, Р. Аюпов, А. Шакиров, “Суннатчи бабай”.*


## «SUNNATCHI BABAI» ON THE KAZAN STAGE


***Khabutdinova Milyausha Muchametsyanovna***
Kazan (Volga region) Federal University, Kazan, Tatarstan, Russia



**Abstract.** *The article analyzes the performance of R. Ayupov "Sunnatchi Babai". The specificity of the artistic interpretation of G. Iskhaki's prose is revealed. The role of this performance in the actor's biography of A. Shakirov and the director's biography of R. Ayupov is determined.*



**Keywords**: *Tatar theatre, prose by G. Iskhaki, R. Ayupov, A. Shakirov, “Sunnatchi Babai”.*


2021 елның 21 октябрьдә Кариев театры “Сөннәтче бабай” спектаклен журналистларга тәкъдим итте (инсценировка авторлары Б.Минкин, Л.Әбүдәрова). Режиссер Р.Әюповның бөек классик, җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның [1] мирасына беренче генә мөрәҗәгать итүе түгел. 2002 елда Яр Чаллы дәүләт драма театрында ул “Кәләпүшче кыз” спектаклен куйган иде, аны театр белгече А.Б. Иняхин “татар тормышының энциоклопедиясе” дип бәяләде. Минзәлә театрында Р.Әюпов “Сөннәтче бабай” белән “Остазбикә”не сәхнәләштерде. Шушы спектакльләр өчен театр коллективы ТРның М.Җәлил исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. 2018 елда Кариев театрында режиссер “Кәҗүл читек” спектаклен куйды. Сәхнә әсәре безне XX йөз башы татар гаиләсенең көнкүреше, мөселман бәйрәме атмосферасы белән таныштыра [2].

“Сөннәтче бабай”ны мин режиссерның Г.Исхакый дөньясындагы иҗади эзләнүләрен бер төенгә төенләгән йомгаклау спектакле дип кабул иттем. Спектакльнең сюжетында бөек татар

прозаигының “Сөннтәче бабай”, “Ул әле өйләнмәгән иде”, “Остазбикә”, “Кәләпүшче кыз”, “Ике йөз елдан соң инкыйраз” әсәрләренең моивлары үрелеп бара. Сценаристлар үткәннән бүгенгегә күпер салып, киләчәккә күз ташларга омтылыш ясаган.

Татар сәхнәсенең хикәяләүче текстларга карата кызыксынуы очраклы түгел, ул режиссер театры үсеш алган саен тагын да киңрәк кулланыла. Проза режиссерларның иҗади куәтен ачарга ярдәм итә. Б. Минкин, Л. Әбүдәрова сценарийны эшләгәндә, Г. Исхакыйның хикәяләү структурасында булган драматизацияләү потенциалын кулланган: хикәяләүдә монологлар һәм диалоглар өстенлек итә, автор сүзләре аз, герой “сөйләме” алгы планга чыга, вакытның тиз яки акрын агышына мөрәҗәгать ителә... Драматизацияләүне телдән сөйләм характерын тапшыру ысулы буларак кулланып, сценаристлар авторның хикәяләвен ремаркаларга әйләндергән, шуның аша сөйләмнең эмоциональлегенә ирешкәннәр.

Р. Әюповның төп казанышы шунда: ул татар тамашачысына Булатка (К.Тинчуринның “Зәңгәр шәл”е), Әлмәндәргә (Т.Миңнуллинның “Әлдермештән Әлмәндәр”е), Мирвәлигә (А.Гыйләҗевның “Өч аршын җир”е), Гәликәйгә (А.Гыйләҗевның “Әтәч менгән читәнгә”) тиң милли каһарман бүләк итте. Баш рольдә – Әзһар Шакиров. Ул Г.Исхакый прозасын радио аша популярлаштыруга бәһаләп бетергесез зур өлеш керткән артистыбыз.

Мин Р. Әюповның баш рольгә нәкъ шушы артистны чакыруына чиксез шатмын. Артистның масштабына нәкъ шушы роль туры килә. Әзһар абыйның Кариев театры сәхнәсәнә чыгуы труппа өчен дә зур әһәмияткә ия... Р.Әюпов яшь актерларның мэтр белән иҗади хезмәттәшлеге өчен уңайлы шартлар тудырган. Моның файдасы бәһаләп бетергесез! Әлеге осталык дәресләрен артистлар гомер буе истә тотачак.

Р.Әюповның спектакле безне татар авылының көнкүреше белән генә таныштырып калмый, ә татар халкының рухи дөньясына да алып керә... Татар милли характерының асылын тәшкил итә торган, әмма хәзерге заманда безнең күз алдында кыйммәте сөртелә барган сыйфатлар бик нечкә итеп күрсәтелә: олыны олы итеп, өлкән кешегә ихтирамлы мөнәсәбәт саклау, гаиләнең иң югары кыйммәт булуын раслау, исламның яшәү рәвеше булуы, яратуны сүзсез генә белдерү, мәхәллә халкының шатлыкта да, кайгыда да бердәмлеге, сабырлык, хезмәт сөючәнлек, сөйләшкәндә, бер-береңә ихтирам саклау. Р.Әюповка курыкмыйча, тамашачыны “халык көзгесенә” карарга чакыруы өчен рәхмәт. Инсценировка авторлары Б. Минкин белән Л. Әбүдәровага Г. Исхакый сүзләренә сакчыл караулары өчен рәхмәт. Р. Әюповка “заманча режиссер” данына кызыгып, бөек классикның иҗатын ботарламавы, татар дөньясыннан көлмәгәне, XX йөз башы классикасына сак карашы, “нафталин” дип гаепләүләреннән курыкмаганы өчен рәхмәт.

Ә. Шакировның сәхнәдәге монологларын тыңлаганда, мин татар җанының чишмә суыдай сафлыгында коендым... Инсценировкада сюжет хатирәләргә корылган: Г.Исхакый героеның күңел иләгеннән кайчандыр мәктәп программаларына кертелгән, хәзер инде туган телләр белән көрәштә кысрыклап чыгарылган әсәрләрнең сюжетлары уза... Татар баласы бүген, гомумән, әгәр әти-әнисе тиешле гариза язмаса, татар әдәбияты белән танышу мөмкинлегеннән мәхрүм ителгән, язган хәлдә дә атнага әдәбият ярты яки бер дәрес кенә укытыла. Бу елларның “җимешен” безгә киләчәктә бик озак җыярга туры киләчәк әле. Әти-әниләр тәүлек әйләнәсе эштә, балаларның аңын интернет формалаштыра. Без цивилизация дигән булып, буын арты буын югалтабыз... Бүген мәктәпләрдә килеп чыккан гадәттән тыш хәлләр шуны раслый. Р.Әюпов татар халкының үткәне һәм киләчәге арасында ныклы күпер төзергә омтыла, буыннар дәвамчанлыгын күзгә төртеп күрсәтә... Режиссер тамашачыларны уңайлы итеп утырган кәнәфиләреннән борыла-борыла, вазгыятькә төрле яклап карарга мәҗбүр итә.

Р. Әюповның Г.Исхакый әсәрләре буенча куйган соңгы ике спектаклендә коллектив сәхнәләрнең башкарылышы аерым бер дәвамчанлыкка ия: берләшү музыка һәм бию аша бара (композитор А.Әсхәдуллин) [3–4]. Әлбәттә, кемдер татарларда әлеге йола җыр-бию белән башкарылмаган, сәхнәдә төрекләрнең бәйрәм итү мәдәниятенең йогынтысы сизелә дияргә дә мөмкин. Әмма режиссер шул рәвешле спектакльнең пространствосын гомумтөрки катламга кадәр киңәйтә... Әлбәттә, яшь композиторга консультант сыйфатында М.Шәмсутдинова кебек

композитор булса, музыкаль бизәлеш татар көйләренә баерак булыр иде. Музыка малайның сөннәткә утыртылуы - аның Мөхәммәд пәйгамбәр өммәтенә басуы уңаеннан мәхәлләдәге гомуми шатлык рухын җиренә җиткереп күрсәтә.

Спектакль буенча бәхәсләрдән кайберәүләрнең режиссер әйтәсе килгәнне аңламавы билгеле булды: Р.Әюпов спектакль башында татар патриархаль дөньясының идиллиясе белән таныштыра, шуннан соң антитезага таянып, аның җимерелүен күрсәтә, ә финалда геройларны башланып киткәндәге вазгыятькә алып кайта. Анда инде Сөннәтче бабай уйланылган, дөрес карар кабул итәргә тиеш. Шулай, мәсәлән, Р.Мөхәммәтова спектакльнең авторларын катнаш никахларны хуплауда гаепләде, гәрчә спектакльдә мизансценада пауза, хәрәктнең акрынайтылуы, конфликтның мимика аша хәл ителүенә игътибар итәргә кирәк иде. Шәсмине тыңлаганда, Сөннәтче бабай дертләп куя, чөнки ул шушы яшенә җитеп, фаҗиганең чынбарлыктагы масштабларын күрә. Аның “Йөрәгеңне тыңла!” дигән сүзләренә катнаш никахны хуплау түгел салынмаган. Р.Әюпов спектакльдә “бала хакы” дигән төшенчә турында уйланырга чакыра. Эш узган инде, Шәмси гореф-гадәтләрне урап узып, хисләренә бирелгән, акыл белән эш итмәгән, мәхәббәттә ике бала туган. Хәзер инде ул ир-ат буларак, кылган гамәлләре өчен җаваплы булырга, ә иң мөһиме - балаларын тәрбияләргә тиеш. Сөннәтче бабай йомшак сүзләр, әмма ныклы киңәше белән Шәсмигә ир-атның гаиләдәге ролен искәртә. Шуңа “кайнар башларга” суынырга киңәш итәр идем, спектакль катнаш никахларны пропагандаламый, ә проблемаларны калкытып күрсәтә: кемдер йола, традицияләрне санламыйча, шундый адымга бара икән, котылгысыз рәвештә дилемма алдында калачак. Кызганычка каршы, күпләр йолаларның, бәйрәмнәрнең асылын аңламый. Алар саклаучы функциясен үти... Күреп торабыз, туй шаукымында “кияү” / “килен” татар исемнәре ала, никах мәҗлесенә ризалаша һ.б., моның белән хәтта горурланалар. Безнең мәдәнияттә исем алыштыру тыела. Ул язмыш алыштыруга тиң дип кабул ителә. Татарлар, барлык мөселманнар кебек үк тәкъдиргә ышана. Беренче проблемалар бала тугач башлана, аннан соң киеренке вакытларда, авырулар килеп чыкканда, һәркем үз диненә сыена, һәркем үз йоласы буенча җирләргә васыять әйтеп, мәрхүм була... Р.Әюпов бу проблемаларны эмоциональ буяуларны куертып, көзгедәгечә төгәл итеп күрсәтә.

Г.Исхакый сюжетлары йомгагын сүтә-сүтә, спектакльнең авторлары әлеге коллизияләрне Сөннәтче бабайның патриархаль аңы аша уздыра. Бу сәхнәләр картның үләр алдыннан күргән төшләре, яңа хатынның уйламыйча кылган гамәл аркасында газаптан туган саташулары. Р.Закирҗанова үзенең ролен ышандырырлык итеп башкара: артистка ире турында уйламыйча, үз файдасын гына кайгыртучы хатын образын төгәл җиткерә. Бу бик тә нечкә детальләр аша ассызыклана: ул ирен табын әзерләп каршы алмый, аңа юынырга ярдәм итми. Татарларда ир белән яшәү, дип искәртә режисссер, аерым бер вазифаларны күздә тота.

Сөннәтче бабай үзенә карата да шул дәрәҗәдә үк таләпчән. Ул ашыгып, икенчегә өйләнүе өчен үкенә, хатыныннан гафу сорый. Хәтерләсәгез, Кол Галинең новаторлыгы иде бу, әлеге сәхнәгә шушы әдәби традиция яктылыгынна карагыз.

Исхакыйны яшь тамашачыларга якынайту максатыннан, авторлар материалны мозаика, кинематография алымнары аша бирергә тырыша. Боларның барысы да сәхнә күренешләренә динамизм бирә. Тормыш вазгыятьләре хәзерге заманга күпер салуга исәп тота. Спектакльдә без дөньяга үз “мин”ебез аша карамыйча, якыннарыбызны тоярга, вазгыятьне ата-бабаларыбыз күзләре белән үлчәргә, бәяләргә өйрәнәбез. Спектакльнең кыйммәте дә шунда.

Р.Солтанова фикеренә кушылып, коллектив сәхнәләрнең көнчыгыш миниатюрасы техникасында куелуын билгелисе килә. Татарларның матди мәдәнияте предметлары спектакль пространствосында көнкүрештәге мәгънәсеннән бигрәк фәлсәфи мәгънәгә ия була: ак яулык, ахак сәйләннәр, сөннәт пәкесе, шәҗәрә, бишек... Сәхнә кырыйларындагы кәҗә образлары артык тоелды, әгәр дә инде аларга метафорик мәгънә генә салынмаган булса: кәҗә татарларда элек-электән җиңел акыллы, җилбәзәк хайван саналды (борынгы төрки мифка ярашлы, ул Үркерне күрми кала, шуңа да бездә ел әйләнәсе җәй түгел). Кәҗәләр киртә аша кереп, бакчаларны туздыра... Ихтимал, рәссам белән режиссер хәзерге заманда татарларның ата-баба

йолаларын онытуларын, табу нәрсәләргә кагылуларын шулай бәялидер. Чөнки татарларның яшәү рәвеше гасырлар дәвамында формалашкан бит.

Спектакль сәхнәгә куелган саен ныгый барачак, мәгънәләре дә тирәнәячәк әле. Яшь актерларның күбесе рольләрен җиренә җиткереп башкаруы өчен сөендем... Ибраһим ролен башкарган Илсаф Нәҗипов аерым соклануга лаек. Актер дөрес сайланган. Явыз малайларны, заманның “вак шайтаннарын” уйнаган Илназ Хәбибуллин белән Рәис Әхмәтзакировның да эчке экспрессиясе көчле. Үзләренең персонажларының дөньяга карашларындагы җитлекмәгәнлекне актерлар “балалык” аша бирәләр, аларның уены комик төсмерләр белән бирелә, бу исә спектакльнең дидактик тональлегеннән котылырга ярдәм итә. Алсу Фәйзуллина белән Муса Камалов рольләрен дулкынландыргыч итеп башкара. Илфат Габидуллин үзенең монологында ашкынучан. Диләрә Зиннәтова үзәккә үтәрлек. Фернат Насыйбуллинга хәзрәт образын театральлектән һәм эстрадага хас җиңеллектән арындырырга кирәк. Әлеге персонаж финалдагы мизансценада сәеррәк һәм зирәк акыллы Сөннәтче бабайның иманын дәвам итүче булуын күрсәтергә бурычлы бит.

Татар капкаларының кояшлы бизәкләренә нигезләнгән сәхнә бизәлеше дә кызыклы (рәссам Булат Гыйльванов). Һәрбер җиһаз ата-бабаларыбызның тормыш рәвешен искә төшерә. Тәрәзә йөзлекләре Әхсән Фәтхетдиновның “Ияләр” циклын хәтерләтә, бу исә татар халкының этикасы белән таныштыра торган спектакльнең әхлакый кырын да киңәйтә.

Сәхнәдәге күренешләр саташулы йокы эстетикасында сурәтләнә. Асылда ул саташулар зур тетрәнү кичереп, үлем түшәгенә яткан геройның алдан күрүе булып чыга. Премьера вакытында күп кенә эпизодлар, кинематографик графика һәм ут концепциясе аркасында, мираж, притча рәвешен ала... Карт хатирәләр йомгагын сүтә, шуның белән бергә киеренке вазгыятьләрдә җаваплар эзли. Ә.Шакиров Сизиф түгел. Ул Геракл кебек тауга менә, үзе артыннан сукмак түгел, ә милләтнең киләчәгенә киң юл ачып калдыра. Гәрчә финал мизансценасында актер тере шәҗәрә буйлап атлап барганда, аның үтәли карашы, мимикасы, аһәңе, әкренәйтелгән кадрлардагы кебек адымнары аша без физик һәм рухи яктан геройның халык рухы биеклегенә күтәрелүен тоябыз, татарның ерагая барган рухи мәдәнияте офыкларын ачабыз.

## Литература


1. Заһидуллин А.Библиография // Гаяз Исхакый: тарихи-документаль җыентык. Казан: Җыен, 2011. - Б. 739–915.
2. Хабутдинова М., Мотигуллина А., Замалиева Л. Наследие Г. Исхаки в репертуаре современного татарского театра // Филология и культура. 2018. - №4. - С.243–250.
3. Хәбетдинова М.М. Сөннәтче бабайда кунакта // Сәхнә. – 2021. – №12. – Б. 6–8.
4. Хәбетдинова М.М. Спектакль-могҗиза // Сәхнә. – 2019. – №2. – Б.28–31.


УДК 82:801.6

# СУФИЙСКИЕ МОТИВЫ В ТЮРКО-ТАТАРСКОЙ ПОЭЗИИ
# ТӨРКИ-ТАТАР ШИГЪРИЯТЕНДӘ СУФИЧЫЛЫК МОТИВЛАРЫ


***Юсупова Нурфия Марсовна***
***Юсупов Айрат Фаикович***
Институт филологии и межкультурной коммуникации Казанского (Приволжского) федерального университета, г. Казань, Татарстан, Российская Федерация
*e-mail: faikovich@mail.ru*


**Аннотация**. *В статье раскрывается формирование суфийских мотивов в тюрко-татарской поэзии на материале творчества А. Ясави и С. Бакыргани. В ходе исследования*

*акцентируется внимание на выявление особенностей становления и развития в ней суфийских мотивов, а также их «национальной» специфики. Целенаправленный анализ поэтических текстов, оценка их в содержательной и функциональной целостности дадут возможность выделить новые грани не только в творчестве А.Ясави и С.Бакыргани, но и в развитии тюрко-татарской поэзии в целом.*

**Ключевые слова**: *Суфизм; суфийские мотивы; тюрко-татарская поэзия; А.Ясави; С.Бакыргани.*

## SUFI MOTIVES IN TURKIC-TATAR POETRY

***Yusupova Nurfiya Marsovna***
***Yusupov Airat Faikovich***
Institute of Philology and Intercultural Communication of Kazan (Volga Region)
Federal University, Kazan, Tatarstan, Russian Federation

**Abstract**. *The article reveals the formation of Sufi motifs in Turkic-Tatar poetry based on the material of the works of A. Yasavi and S. Bakyrgani. In the course of the study, attention is focused on identifying the features of the formation and development of Sufi motives in it, as well as their "national" specifics. A purposeful analysis of poetic texts, their assessment in content and functional integrity will make it possible to identify new facets not only in the works of A. Yasavi and S. Bakyrgani, but also in the development of Turkic-Tatar poetry as a whole.*

**Keywords**: *Sufism; Sufi motifs; Turkic-Tatar poetry; A. Yasavi; S. Bakyrgani.*

Суфичылык тәгълиматы төрки халыклар арасында да киң җәелә. Төрки-татар төбәгендә аның чагыштырмача тиз таралуы мөселман дәүләтләре белән тыгыз икътисади, рухи бәйләнешләрдә булу белән дә, тарихи-географик шартларга мөнәсәбәтле дә аңлатыла. Галимнәр X-XII гасырларда яшәгән Болгар дәүләте чорыннан алып, 1917 елгы инкыйлабка кадәр татар халкы тормышында суфичылыкның, төрле үзгәрешләр кичереп, төрле шәкелләргә кереп, ислам дине белән бергәлектә яшәвен күрсәтә [8, б. 3]. Идел буе Болгар дәүләте тарихына караган тарихи истәлекләрдә Гарәбстан, Иран, Урта Азия якларыннан килеп, әлеге гыйлемне тараткан күренекле суфи галимнәр белән бергә, Болгарның үз шәйхләре, суфилары булуы турында да хәбәрләр килеп җиткән [5, б. 257].

Шул ук вакытта төркиләр арасында суфичылыкның чагыштырмача тиз үзләштерелеп китүе өчен билгеле бер идеологик җирлек, дөнья, яшәешне танып-белүгә мөнәсәбәтле охшаш караш формалашкан булган дисәк тә ялгышмабыз [13, б. 61]. Билгеле булганча, «борынгы төркиләр, үз тарихларында мәҗүсилектән, күпаллалыктан бераллалыкка күчү, баш алла итеп Тәңрене тану дәрәҗәсенә күтәрелү өчен, зур һәм озын юл үткәннәр. Баш алла дип Тәңрене таный башлаганнар. Дөньядагы һәр гамәл, һәр эш нәкъ менә Тәңре теләге, Тәңре ярдәме, Тәңре теләктәшлеге белән генә башкарыла дип ышанганнар» [10, б. 64]. Бу сыйфатлар, ышану һәм иделлаштыру үзенчәлеге Күлтәгин, Билгә каһан һәм Төнйокык ташъязмаларында да чагылыш тапкан. Аларда каһаннар образлары идеаллаштырыла, камил инсан дәрәҗәсенә күтәрелә, культ тудырылып, алардан соңгы буыннарның, варисларның алардан үрнәк алырга тиешлеге искәртелә, алар тәкъдим иткән кануннарны үтәмәү югалуга алып килә дип раслана. Бу караш төрки халыкларда традицион дөньяга караш төсен ала.

Төрки халыклар яшәгән җирләрдә (Урта Азия, Төркестан, Азәрбәйҗан, Идел-Урал буйлары) таралган суфичылык хәрәкәтен «төрки суфичылык» термины белән атау кулланылышта йөри. Идел һәм Урал буйларында башта Әхмәд Ясәви исеме белән бәйләнгән Ясәвия тарикате киң урын ала, ул беренче төрки суфи оешмасы да булып тора. Ясәвия тарикате – монистик рухтагы тәгълимат, ягъни ул ислам дине кысаларында бер Аллалык идеясен алга сөрә. Бу болгар-татарларны бербөтенгә туплауда, динне саклап калуда әһәмиятле роль уйный.

Мөселман дөньясындагы кебек үк, төрки-татар җирлегендә дә суфилар үз фикерләрен җиткерү юлында иң мөһим мәйдан итеп әдәбиятны аерып куя. Г. Рәхим һәм Газиз Гобәйдуллин күрсәткәнчә, «рәсми ислам дине белән бергә безнең татарлар арасында бик борынгы заманнардан ук алып тасаувыф әдәбияты да таралды. Шуның өчен үзебезнең дини әдәбиятыбызда суфичылыкның бик көчле тәэсирен күрәбез» [1, б. 357]. Бу үзенчәлеккә әдәбият белгече Ф. Туйкә 1920-1930 еллар чигендә үк игътибар итә: «Әлегә чаклы табылган материалларны тикшерү аркасында Идел буе әдәбиятының өч-дүрт йөзлек шул тарихына әдәбиятыбызның суфилык идеологиясе белән сугарылган чоры дип бәһа бирәбез» [11, б. 42].

Суфичылык әдәбиятының формалашып китүе өчен милли күзаллау һәм образлы фикерләүгә бәйле әдәби җирлек булган дисәк тә ялгышмабыз, чөнки сөйгән ярга мәхәббәтне югары күтәрү, аны илаһилаштыру һәм, символик образлар аша җиткерү тенденциясе фольклор әсәрләрендә, халык җырларында ук урын ала, ул символик фикерләүнең беренче баскычы, нигезе булып тора [14, б. 61-91]. Һәр әдәбиятның үз йөзе, традицияләре булган кебек үк, суфичылык әдәбиятын тәшкил иткән хәлдә, һәр халык әдәбиятында формалашкан суфи поэзиянең дә үз үзенчәлекләре, специфик үзгәлекләре бар. Азәрбәйҗан әдәбиятын өйрәнеп, галимнәр суфичылык поэзиясенең формалашу нигезен фольклордагы гыйшык җырлары белән бәйләп карыйлар [4, б. 182-183]. Мондый фикерне төрки-татар әдәбияты мисалында да кабатларга мөмкин булыр иде.

Урта гасырлар фәлсәфи фикерен өйрәнгән галим Рашат Әмирханов билгеләп үткәнчә, төрки-татар дөньясында әдәбият ике юнәлештә: дини һәм дөньяви юнәлештә үсеп китә, беренчесе Хуҗа Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганилар исеме белән бәйләнсә, икенче юнәлеш Йосыф Хас Хаҗиб Баласагуни, Әхмәд Югнәкиләр иҗатларына тоташа [2, б. 34]. Ә. Сибгатуллина Й. Баласагунлының «Котадгу белег» поэмасына да суфичылыкның көчле тәэсир итүен һәм Одгурмыш образында бик ачык чагылуын билгели: Одгурмыш – аскет, сукбай, үзен бары Аллага гына хезмәт итәргә багышлаган дәрвиш: аның ашаганы – үлән тамырлары, эчкән суы – яңгыр сулары, кигән киеме – капчык киндереннән [9, б. 7]. Рус галиме М.С. Фомкин хезмәтләрендә Одгурмыш дәрвиш кенә түгел, шәйх дип дип билгеләнә [12, б. 70]. Әмма суфичылык әдәбиятына хас мотивлар, идея-фикерләр, барыннан да элек, төрки әдипләр Ә.Ясәви һәм С.Бакырганый иҗатларында ачык чагылыш таба.

Урта гасыр фарсы шигъриятендә галимнәр ике юнәлешне аерып билгели: «авыр аңлаешлы гади стиль (саһл-е мөмтани)» һәм «яңа үзенчәлекле нәфис стиль (фиганият)» [7, б. 104-105]. Урта гасыр суфи төрки-татар шигърияте дә әлеге классик юл белән үсә: дидактик башлангычка йөз тоткан гади стильдән – символик сурәтлелеккә, күпкатламлы эчтәлеккә йөз тоткан нәфис стильгә юл тота. Кол Шәриф шигъриятеннән үсеш алып киткән нәфис стиль [6, б. 213] татар шигъриятендә чын мәгънәсендә XIX гасырда, аерым алганда Шәмсетдин Зәки шигъриятендә көчле чагылыш таба.

Ә. Ясәви, аның укучысы С. Бакырганый иҗатлары гади, эпик стильгә йөз тотып үсә. Әхмәд Ясәвинең безнең көннәргә килеп җиткән проза белән язылган, Ясәвия тарикате буенча белешмә-өйрәтмәне тәшкил иткән «Дәфтәри әүвәл» («Беренче дәфтәр»), хикмәтләрне туплаган «Дәфтәри сани» («Икенче дәфтәр», «Диване хикмәт»), С. Бакырганиның 36 хикмәте һәм 3 поэмасы урын алган «Бакырган китабы», аерым китапчыклар рәвешендә дөнья күргән «Ахырзаман» һәм «Мәрьям ана» поэмалары, аңа нисбәт ителгән «Хәким ата» китабы шул хакта сөйли.Аларның әсәрләрендә үгет-нәсихәт, өндәү көчле булып, әсәрләр тәкъдиргә буйсынырга, әхлакны төзәтергә чакыру, җанның Алла белән кушылырга омтылуы, бу җирнең коллык, ялган булуы хакындагы мотивлар белән баетыла; иҗтимагый тәртипләргә, мәҗүсилеккә, башка диннәргә тәнкыйди мөнәсәбәт җиткерелә, рух, җан, яшәү һәм үлем проблемалары һәм аларга бәйле рәвештә яшәү мәгънәсе проблемалары үзәккә куела.

Әсәрләр Аллага якынаюның төрле этаплары хакында мәгълүматлар бирә. Ә. Ясәви, С. Бакырганый әсәрләрендә реаль / трансцендентал дөнья оппозициясе яшәешкә бәя бирү чарасына әверелә. Шушы фонда җир тормышы гөнаһ, наданлык, ямьсезлек, тән ләззәте чыганагы буларак кабул ителә, ә трансцендентал дөнья, киресенчә, яктылык, матурлык, изгелек, Алла белән очрашу урыны буларак күзаллана. Мәсәлән, Әхмәд Ясәвинең лирик герое

җир яшәешенең мәңгелек газаптан торуы хакында сөйләп, бу газапларның суфи шәхесне ахирәт бәхетенә алып киләчәген раслап куя:

*Монда җәфа чиккәннәргә дидары тәхт,*
*Рузы Мәхшәр гата кылгай һәм тәхте бәхт,*
*Ратканда кылган үзе гашыйкка гаһд,*
*Ләмәкәндә Хакдин сабак алдым мына* [15, б. 58].

Реаль / трансценденталь оппозициясе Әхмәд Ясәви әсәрләрендә гариплек, горбәтлек идеясен җиткерүгә дә буйсындырыла. Гомумән, суфи әдәбиятта гариб образы зур урын алып тора. Гариб – ялгыз кеше. Әхмәд Ясәвинеңлирик герое да гариблектә «горбәт чиккән», ягъни чит илдә калырга мәҗбүр булган кеше буларак аваз сала. Әхмәд Ясәви тарафыннан яшәештә инсанның төп вазифасы – «теге», трансценденталь дөньяга күчешкә әзерләнү, илаһият белән кушылу юлына таба җан хәрәкәте буларак билгеләнә.

Охшаш мотивлар С. Бакырганый әсәрләрендә дә дәвам итә. Мисал өчен, аның ожмах белән тәмугның үзара бәхәсенә багышланган шигырендә дөнья сурәте оҗмах / тәмуг каршылыгы аша бирелеп, оҗмах үзенең эчендә пәйгамбәрләрнең һәм иманлы бәндәләрнең, хак мөселманнарның булуы белән мактана, тәмуг исә, киресенчә, газап чигүче кяферләрне, һәртөрле җәзалау рәвешләренең үзендә булуы белән горурлана. Кеше гомере чикләнгән, кеше үлемгә әзерләнергә, оҗмахка ирешерлек гамәлләр кылырга, Аллага якынаерга тиеш дигән фикер әсәрне үтәли кисеп бара. Шуңа бәйле Ә. Ясәви, С. Бакырганый әсәрләрендә аскетлык, дәрвишлек – дөнья малыннан, рәхәтеннән ваз кичү хакында фикерләр актуальләшә.

Төрки-татар суфи шигъриятендә камил инсан теориясенә бәйле фикерләр дә урын ала. Ләкин суфичылыкның бәхәсле һәм катгый тәгълиматы булган вөҗүдия фәлсәфәсендәге ачыктан-ачык пантеизм, яшәешне Аллага тәңгәлләштерү –камил инсанны онтологик яссылыкта шәрехләү –милли мәдәнияттә көчле түгел. Безнең җирлектә вәхдәт әш-шөһүд классик юнәлеше киң тарала. Кеше һәрвакыт илаһи камиллеккә омтылырга тиеш дигән фикер әхлакый эчтәлек ала. Концепциянең нигезендә камиллек үрнәге булган Мөхәммәд пәйгамбәр образына тиңләшергә, ул ирешкән рухи биеклеккә ирешергә омтылыш ята. Алланың сайлап алынган затларыннан булган Мөхәммәд пәйгамбәрнең үткән юлы һәм кылган гамәлләре һәр мөселман өчен үрнәк буларак күрсәтелә. Әлеге өйрәтүгә бәйле, дөнья сурәтендә үзенчәлекле макрокосм һәм микрокосм каршылыгы алга чыга. Әхмәд Ясәви иҗатында Мөхәммәд образын идеаллаштыру сыйфаты аеруча көчле булып тоела. Әйтик, егерме өченче, егерме дүртенче хикмәтләрендә лирик герой, экзальтациягә бирелеп, Хакка ирешү юлында Мөхәммәд пәйгамбәр сыйфатлары хакында бәян итә, Шушы юлда макрокосм һәм микрокосм рәсүл / туфрак бөртеге образлары ярдәмендә тәгәлләштерелә.

Изгелек, фәкыйрьләрне сөю, ярдәмчел булу, булганга канәгать булу, Алла кушканча яшәү, тәкъвалык, шәфкатьлелек,һәрдаим гыйбадәттә булу, шәригать кануннарын җиренә җиткереп үтәү, Алладан ярлыкау һәм җәннәт өмет итү Әхмәд Ясәвинең лирик герое тарафыннан камил инсанның төп сыйфатлары буларак кабул ителә.

Ә. Ясәви, С. Бакырганый әсәрләрендә гөнаһ кылу, аның өчен гафу сорау мотивларын калку: гөнаһ гамәлләр өчен Алладан кичерү сорау кирәк, Алла мәрхәмәтле, чын күңелдән тәүбә итүчеләрне, ярлыкау үтенүчеләрне гафу итә, тәүбәгә килүчеләргә аның нуры иңә, ә тәүбәсезләр бу дөньялыктан кичмәс, шулай итеп, рухи чисталыкка, үлемсезлеккә ирешә алмый кала дип раслана. Шуңа мөнәсәбәттә кешелеклелек сыйфатлары мактала, гуманизм идеясе күтәрелә, суфи лирик герой кешеләрне мәрхәмәтле булырга чакыра.

Суфи әдәбиятта нәфис стиль символларга таянып иҗат итү юлын алга куя. Әмма бу алым гади, эпик стильгә йөз тотып үскән Ә. Ясәви, С. Бакырганый иҗатларын да читләтеп үтми. Мисал өчен, Әхмәд Ясәвинең тормыш-яшәешне, фани дөньяны базар символы аша җиткерүе күренә:

*Төштем узар (гөнаһка), бурак тузар, китсә базар,*
*Дөнья – базар, эчрә кереп коллар азар* [3, б. 8].

Моннан тыш, һәр ике автор иҗатында да шәм символының бер модификациясе булган ут образының еш кулланылуы күренә. Ә. Ясәвинең лирик герое бөтен барлыгы белән иляһи мәхәббәт утында яна.

Шул рәвешле, суфичылык, иҗтимагый, дини хәрәкәт буларак, төрки дөньяда рухи, фәлсәфи, милли бөтенлекне камилләштерүдә әһәмиятле урын тота. Ул әдәбиятны да үзгә мотивлар, суфичыл әсәрләр структурасы, аларга хас үзенчәлекләр белән мәгънә ягыннан баета, образлы фикерләүне үстерүдә әһәмиятле роль уйный.

**Әдәбият**


1. Абилов Ш. Суфичылык // Татар әдәбияты тарихы Алты томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – Т.1. – 360 б.
2. Амирханов Р.М. Татарская социально-философская мысль средневековья: в 2–х кн. Кн.1 – Казань, 1993. – С.34.
3. Бакырган китабы: XII-XVIII йөз төрки-татар шагыйрьләре әсәрләре / текстны басма өчен Ф.Яхин әзерләде. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 8 б.
4. Габиббейли И., Багиров А. Азербайджан – жемчужина Турана: монография-антология. – М.: Изд-во «Худож. лит-ра», 2020. – С. 182-183.
5. Дәүләтшин Г. Төрки-татар рухи мәдәнияте. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 257 б.
6. Загидуллина Д.Ф. Картина мира и художественные особенности средневековой суфийской поэзии // Ученые записки Казанского государственного университета. Серия гуманитарных наук. – 2007. – Т. 149. – Книга 2. – С. 213.
7. Пригарина Н.И. Образное содержание бейта в поэзии на персидском языке // Восточная поэтика. – М.: Наука, 1983. – С. 104-105.
8. Сибгатуллина Ә.Т. Татар әдәбиятында суфичылык (чыганаклар, тематика һәм жанр үзенчәлекләр): филол. ф. д. дис.; Алабуга дәүләт педагогия институты. – Алабуга, 2000. – 3 б.
9. Сибгатуллина Ә. Татар дини-суфи әдәбияты. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2017. – 7 б.
10. Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Т. 1. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 64 б.
11. Туйкә Ф. Тузанлы шүрлекләрдә (әдәбият тарихына материаллар) // Безнең юл. – 1928. - №9. – 42 б.
12. Фомкин М.С. О суфийских мотивах в «Благодатном знании» Юсуфа Баласагуни // Советская тюркология. –1990. –№5. –С.70.
13. Юсупов А.Ф. Атрибуция языка татарской суфийской поэзии XIX века: дисс. докт. филол. наук. – Казань, 2022. – 502 с.
14. Юсупова Н.М. Образ-символ как система номинаций в татарской поэзии первой половины XX века: дис. д-ра филол. наук. – Казань, 2018. – С. 61-91.
15. Ясәви Ә. Хикмәтләр. – Казан: ТР «Хәтер» нәшрияты (ТаРИХ), 2003. – 58 б.

## IV. АКТУАЛЬНЫЕ ПРОБЛЕМЫ СОВРЕМЕННОГО ТЮРКСКОГО ЯЗЫКОЗНАНИЯ. ТОПОНИМИКА И ОНОМАСТИКА ТЮРКСКИХ НАРОДОВ

УДК 811

# ОСОБЕННОСТИ ПРОЗВИЩ В ПРОИЗВЕДЕНИЯХ ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ӘСӘРЛӘРЕНДӘГЕ КУШАМАТЛАРНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Ахметшина Айгуль Дамировна***
Елабужский институт Казанского (Приволжского) федерального университета,
г. Елабуга, Татарстан, Российская Федерация
*e-mail: aigulkabelekez@mail.ru*

**Аннотация.** *В статье рассматриваются особенности прозвищ в произведениях татарской литературы. Во времена наших дедушек и бабушек, прозвище носилось как родовой знак, родовое имя или как дополнение к официальному имени человека. Сложившиеся на основе тотемистических воззрений прозвища сохранились и в современной татарской антропонимической системе. Личные же прозвища были тесно связаны с реальной действительностью, давая метафорическое смысловое содержание, основанное на различных качествах того или иного человека. Они объединяются на основе общих, индивидуальных, физических и духовных качеств человека, профессии, места жительства и других мотивов. Необходимо сказать, что, если имя ребенку дают родители сразу после рождения, то прозвище присваивается коллективом, обществом на разных этапах его жизни.*

**Ключевые слова:** *прозвища; татарская литература; родовой знак; тотемистические воззрения; метафорический смысл.*

# FEATURES OF NICKNAMES IN WORKS OF TATAR LITERATURE

***Akhmetshina Aigul Damirovna***
Elabuga Institute of the Kazan (Volga region) Federal University,
Elabuga, Tatarstan, Russia.

**Abstract.** *The article examines the features of nicknames in the works of Tatar literature. In the time of our grandparents, the nickname was worn as a generic sign, generic name or as an addition to the official name of a person. The nicknames based on totemistic views have been preserved in the modern Tatar anthroponymic system. Personal nicknames were closely related to real reality, giving metaphorical semantic content based on various qualities of a particular person. They are united on the basis of the general, individual, physical and spiritual qualities of a person, profession, place of residence and other motives. It must be said that if the name of the child is given by parents immediately after birth, then the nickname is assigned by the team, society at different stages of his life.*

**Keywords:** *nicknames; Tatar literature; generic sign; totemistic views; metaphorical meaning.*

Татар антропонимик системасында кушаматлар этномәдәни тирәлекнең мөһим берәмлеге буларак исем йөртүче белән исем бирүче арасындагы уңай яки тискәре мөнәсәбәтне чагылдырып, кешегә хас характер үзенчәлекләренең күләмен яктыртып, исем бирүченең прагматик максатларын тормышка ашырып, шәхси һәм тирә-юнь дөнья картинасын ачуда исем бирү сәнгатенең мөмкинлекләрен тулысы белән реальләштергән гаять мөһим антропонимик берәмлекләрне тәшкил итеп торалар. Әйтергә кирәк, әдәби әсәр тукымасында кушаматлар номинатив, шәхесне идентификацияләү, аеру вазифасыннан тыш, әле әдәби

стилистик функция дә үтиләр. Вербаль-семантик яктан караганда, кушаматларда исем бирү сәнгатенең төрле мөмкинлекләре ачыла. Когнитив яктан кушаматлар милли үзбилгеләнү һәм милләтнең характер үзенчәлекләрен чагылдыру мөмкинлегенә ия. Прагматик яктан караганда, кушаматлар билгеле бер социаль катламның төрле коммуникатив шартларын яктырталар [1, б. 142].

Әйтергә кирәк, борынгы бабаларыбыз хәтта фамилияләр кулланып та тормаган. Күп очракта, кеше исеменә, аның этисенең исеме генә кушылып әйтелгән. Ә кайчак, кушамат өстәлгән, дөресрәге алга куеп әйтелгән. Кушаматлар күбесенчә буыннан-буынга күчкән, ягъни нәсел кушаматлары булган. Кайбер очракта, аерым шәхескә кушылганнары да булган. Хәтта безнең балачакта да, зуррак авылларда, кушаматлы кешеләр булгалый иде. Мисал өчен, бер үк исемдәге кешеләр дистәләгән. Ул исемнәрне ярыша-ярыша кушканнармы? Әйтик, Олы Әтнәдә Гомәрләр дистә чамасы ди: “Әсән” Гомәре, “Ленин” Гомәре, “Каеш” Гомәре, “Корт” Гомәре һәм башкалар [2, б. 150].

Чынлыкта да, кушаматсыз гына яшәүчеләр сирәктер бу дөньяда. Сорап тормый гына тагалар да куялар аны. Һәм мәңге котылам димә. Үпкәлә, гарьлән, кимсен – башкаларның соңыннан анда бер эше дә юк.

Борынгы чорларда кушамат нәсел тамгасы, нәсел-ыруг атамасы яки шәхеснең рәсми исеменә өстәмә исем булып йөргән. Тотемистик карашлар нигезендә барлыкка килгән кушаматлар хәзерге татар антропонимик системасында да традиция нигезендә сакланып калган. Шәхси кушаматлар исә, теге яки бу кешенең төрле сыйфатларына нигезләнгән метафорик мәгънәви эчтәлек биреп, чыгышлары белән реаль чынбарлыкка тыгыз бәйле була. Алар кешенең гомуми, хосусый, физик һәм рухи сыйфатларына, һөнәренә, яшәү урынына һ.б. мотивларга нигезләнеп кушыла. Балага исемне тугач та эти-әнисе бирсә, ә кушаматны исә, тормышының төрле этабында коллектив, җәмгыять тага да куя.

Шәхси кушаматларның күбесе кешенең теге яки бу сыйфатын, рухи яки физик билгеләрен турыдан-туры атау юлы белән ясала. Кешенең рухи яки физик сыйфатларын теге яки бу предметка, күренешкә, кош-корт яки хайванга охшату нигезендә барлыкка килгән кушаматлар байтак. Мәсәлән, Борча – кечкенә буйлы, бик хәрәкәтчән яки тиктормас кешегә тагылган кушамат. Шәхси кушаматлар кешенең һөнәренә, эшләү яки яшәү урынына, милләтенә, титулына, социаль чыгышына, берәр сүзне еш кабатлау яки үзенчә әйтүенә, рәсми исемен бозып әйтүгә мөнәсәбәтле рәвештә дә барлыкка килергә мөмкин.

Кушамат терминының икенче өлешендә борынгы төрки телдән килгән *“ат”* сүзе булуы аның тамырлары тирәндә икәнлекне һәм төп исемгә өстәмә рәвештә элек-электән кулланылуны раслый. Борынгы заманнарда кушаматлар фамилия функциясен башкарган дип әйтеп үттек, ягъни кеше исеменә өстәлеп, шәхесне тагын да конкретлаштырган [3, б. 113]. Орхон-Енисей язмаларында, *М.Кашгарыйның “Диване лөгатет төрк”* хезмәтендә исем белән бергә кушамат та аерым функция үти. М.Кашгарыйның әлеге сүзлегендә *“at”* сүзенең беренче мәгънәсе *“исем”* дип күрсәтелсә, икенче мәгънәсе – *“кушамат”* [2, б. 112].

Хәзерге татар әдәбиятында шәхеснең кәсебе-һөнәренә яки эшләү урынына мөнәсәбәтле кушаматлар да еш очрый. Мондый кушаматларның күбесе хәзерге һөнәр атамаларына нигезләнеп ясала. Шулай ук онытылып бара торган һөнәр-кәсепләргә нисбәтле кушаматларның да очравы күздә тотыла: Атҗабар Миннисa (М.Мәһдиев, “Бәхилләшү”), Итекче Җиһанша, Тимерче Нотфый (М.Мәһдиев, “Торналар төшкән җирдә”), Сунарчы Сәбәк (А.Хәлим, “Кыйбла”) һ.б. Хәзерге татар әдәбиятында шәхеснең яки аның ата-бабаларының титулына, социаль чыгышына мөнәсәбәтле кушаматлар да еш очрый: Алпавыт Шәйхи (М.Мәһдиев, “Бәхилләшү”), Зимагур Булат (Ф.Бәйрәмова, “Кырык сырт”), Зимагур (Ахир, “Таш калада баш кала”) һ.б.

Шулай ук, мисал буларак *З. Хәкимнең “Телсез Күке”* [5, б. 479] әсәрен анализлап үтик. Пьеса *“Телсез Күке” кушаматы* белән атап йөртелгән *Зарифның* урман эчендәге йортында барган вакыйга белән башлана. Улы яши торган шәһәргә китәргә теләмәүче әлеге ялгыз картның башта Финляндиягә, аннары Германиягә каршы сугышларда катнашуы, яраларының даими борчып торуы укучы-тамашачыга билгеле була. Өенә әледән-әле караклар кереп, юк-

бар әйберләрен алып китүенә һәм хокук саклау органнары белән шактый үзгә мөнәсәбәтенә бәйле, аның үзенчәлекле характер сыйфатлары ачыла башлый.

*З. Хәким “Телсез Күке”* [5, б. 479] пьесасының жанрын *“театраль роман”* дип билгели. Татар сәхнә әдәбияты өчен яңа жанр. Автор сәхнәгә кую өчен язылган әсәренең романга тиң вакыйга-күренешләрне, гаҗәеп язмышларны үз эченә алуын, аның аерым шәхесләрдән бигрәк халык тормышын чагылдыруына ишарә итә. Ретроспектив алым ярдәмендә бүгенге тормыш белән үткәндәге хәл-вакыйгалар чиратлашып, Бөек Ватан сугышы алды чорыннан алып XX гасыр ахырына кадәрге вакытны үз эченә алган тормыш күренешләрендә авторның милләт язмышы турындагы уйланулары алгы планга чыга. Әсәр башында урын алган эпиграфлар милләтнең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында фәлсәфи уйлануларга этәрә. Укучыда билгеле бер интрига тудырып, автор искәрмәсендә мондый юллар бар: *“Телсез Күке турында мәңге сөйләп һәм мәңге җырлап туймаслык”* [5, б. 43].

Шулай ук, пьесада Зимин белән бәйле вакыйгалар үзгә бер катлам тәшкил итә. НКВД офицеры – системаның тугрылыклы сакчысы. Аның йөзендә без тоталитар җәмгыятьнең кешелексез асылы белән очрашабыз. Үз теләгенә Зимин я юмалап, я алдап, я куркытып ирешергә гадәтләнгән. Шуңа да Зариф белән Зыятдинның җитди каршылыгын һәм бер-берсен яклап, саклап эш итүләрен аңлый алмый. Ике татар егетенең туган җир, халык, аның җыр-моңына бәйле якынаюына, дуслашу-туганлашуына тоталитар система каршы тора алмый. Бер милләт вәкилләренең берләшүендә куркыныч күреп, Зимин төрле юллар белән моңа каршы көрәшә. Хәзер инде аның “эшен” улы дәвам итә. Гомере ахырына якынлашканда Зиминның Зариф янына килүе, билгеле бер дәрәҗәдә күңелен бушатуы, үзенең җиңелүен тануы да булып тора. Шул рәвешле, әлеге каршылыкның чишелеше рәвешендә автор яклаган фикер-карашлар калкып чыга. Алар исә Зариф омтылган Хакыйкать буларак бирелә: Халык тормышының чагылышы булган, Карелия урманнарын, салкын кышларын үтеп чыга алган халык җыры-моңы кешенең көче, рухы, өмете чыганагы булып тора. Зариф сүзләре белән әйткәндә, *“Сугышта винтовканы телсез иткән тел әле яшәячәк ул!. Винтовканы телсез калдырган җырны ничек үтереп булсын икән?!”* [5, б. 231].

Тормыш юлында күптөрле золым кичергән Зариф олы гуманист буларак сурәтләнә. Җаны-тәне белән явызлыкка каршы торучы карт күңелендә үзен кайгы-хәсрәткә дучар иткән кешеләргә карата нәфрәт-ачу хисе юк. Әсәр ахырында Зиминга ул болай ди: *“Мин сине гафу итә алам, тик аңлый алмыйм. (...) Мин сиңа саулык-сәламәтлек телим! Озын гомер телим! Озак яшә! Ике йөз ел, ике йөз илле ел яшә тагын! Чөнки аңламый калган нәрсәләрне аңларга вакыт сиңа күп кирәк. Сорауларыңа җавапларны табарга сиңа озын гомер кирәк! Ниһаять, аңлагач, бәлки, тәүбә итәргә дә бераз вакыт кирәк булыр әле”* [5, б. 243].

Шул рәвешле, әйтергә кирәк, заманның фәлсәфи милли, әхлакый, сәяси һ.б. проблемаларын бер фокуска туплап, бөтен кискенлегендә чагылдырган әсәрнең табышнаңалыгы, бердән, башкаларны кабатламаган милли характерлар тудыруы; икенчедән, катлаулы һәм күптөрле вакыйгаларны бер үзәккә максатчан һәм мәгънәле туплавы; өченчедән, милли проблематиканы татарның рухын билгеләүче җыр-моң төшенчәсенә һәм асылын ачучы Хәтер, Намус, Тугрылык, Игелек сыйфатларына нисбәтле ачуы белән аңлатыла.

Нәтиҗә буларак, түбәндәге фикерне әйтергә кирәк, кушаматлар персонажларның характер үзенчәлекләрен тулырак ачып бирә ала, һәрберсе кеше күңелендәге изге, якты, саф хисләрне барлык мөмкинлеге белән уятырлык итеп сайлаган. Чөнки, алар әдәби әсәрнең идея-эстетик кыйммәтен сәнгатьле чагылдыруда мөһим деталь булып хезмәт итеп торалар. Кушаматлар эмоциональ-экспрессив тирәлектә барлыкка килеп, кулланылыш ала. Матур әдәбият тукымасында, әдәбият әсәрләрендә кушаматлар язучылар тарафыннан отышлы файдаланылып, әдәби алым буларак кулланыла. Әлбәттә, хәзерге татар әдәбиятында әлеге әдәби алымның бик уңышлы мисаллары күзәтелә. Әдәби әсәр тукымасына кертеп җибәрелгән кушаматлар, телнең этнокультур тирәлегенең моделен гәүдәләндереп, әсәрнең төп мәсьәләләрен һәм тирән фикерләрен, әдәби-эстетик концепциясен чагылдыру алымы ролен үти. Кушаматларның антропонимик трансформацияләре сюжет линияләрен куерту,

эмоциональ-экспрессив яки юмористик төсмерләр бирүдән тыш, геройның характер үсеш-үзгәрешен дә ачарга ярдәм итеп тора.

**Әдәбият**


1. Берестова Е. А. Система прозвищ диалектной языковой личности // Вопросы ономастики. – 2015. – № 2 (19). – С. 141–155.
2. Махмуд ал-Кашгари. Диван лугат ат-турк. Свод тюркских слов. – Том 1. – 2010. – 124.
3. Подольская Н. В. Словарь ономастической терминологии. – М. : Наука, 1978. – 198 с.
4. Ушаков Н. Н. Прозвища и личные неофициальные имена (к вопросу о границах) // Имя нарицательное и собственное. – М., 1978. – С. 146 – 172.
5. Хәким З. Телсез күке : пьесалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 479 б.
6. Abdullina G.R. Sultanbaeva K.V. Bakhtiyarova A.N. Kamaeva R.B. Mukimova N.A. About The Problem Of Nickname Separation From Other Onomastic Units Modern Journal Language Teaching Methods (MJLTM) vol.7, Issue 9/1, September 2017. Page 202-207.


УДК 811

# ЛЕКСИКА, ОТРАЖАЮЩАЯ ВОЗРАСТНЫЕ ОСОБЕННОСТИ В СЛОВАРЯХ ТАТАРСКОГО И АНГЛИЙСКОГО ЯЗЫКОВ
# ТАТАР ҺӘМ ИНГЛИЗ ТЕЛЕ СҮЗЛЕКЛӘРЕНДӘ ЯШЬ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕН ЧАГЫЛДЫРГАН ЛЕКСИКА


***Данилова Зульфира Салахетдиновна***
МАОУ «ПОК «Адымнар – Алабуга» Елабужского муниципального района РТ,
г. Елабуга, Татарстан, Россия
*e-mail: 1804000265@mail.ru*
***Ашрафуллина Розалия Илдаровна***
МБОУ «СОШ №10» Елабужского муниципального района РТ,
г. Елабуга, Татарстан, Россия
*e-mail: rozaliya_nais@mail.ru*



**Аннотация.** *Данная статья посвящена изучению лексики, которая отражает возрастные особенности в словарях татарского и английского языков.*



**Ключевые слова:** *полингвальное образование, принцип овладения тремя языками к моменту окончания школы, возрастные особенности, толковые словари, детский возраст, юношеский возраст, взрослый период, старчество, члены семьи.*


# VOCABULARY REFLECTING AGE-SPECIFIC FEATURES IN THE DICTIONARIES OF THE TATAR AND ENGLISH LANGUAGES


***Danilova Zulfira Salakhetdinovna***
MAEI «PEC «Adymnar – Alabuga» Yelabuga municipal District of the RT,
Elabuga, Tatarstan, Russia
***Ashrafullina Rosalia Ildarovna***
MBEI «Secondary School No.10» Yelabuga municipal District of the RT,
Elabuga, Tatarstan, Russia



**Abstract.** *This article is devoted to the study of vocabulary, which reflects the age characteristics in the dictionaries of the Tatar and English languages.*

**Keywords:** *multilingual education, the principle of mastering three languages by the time of graduation, age features, explanatory dictionaries, childhood, adolescence, adulthood, senility, family members.*

Глобализм чорында күп телләр өйрәнүче кеше – мәдәни мирасны һәм илне өйрәнү чараларын саклаучы, төрле халыклар һәм этник төркемнәр арадасында арадашчы. Икътисад, сәнәгать һәм фән өлкәләрендә чит илләр белән элемтәләр өлкәсендә белгечләргә карата таләпләр арта. Шуңа бәйле рәвештә, укучыларның иҗади-шәхси потенциалын үстерү өчен шартлар тудыруга һәм заманча тирәнтен белем бирү мөмкинлекләрен киңәйтүгә аерым игътибар бирелә. Без, күптелле белем бирү комплексы укытучылары, дәресләрдә телләрне чагыштырып өйрәнүгә басым ясыйбыз. Полилингвальлек – ул вакыт таләбе, өч телдә аралашуны күздә тота. Ул телгә, мәдәнияткә толерант мөнәсәбәтне укучыларда милләтара аралашу культурасын формалаштыра. Күптелле булу хәзерге вакытта бик тә дәрәҗәле. Ә вакыт – кеше тормышының әһәмиятле өлеше. Кеше һәм вакыт бәйләнеше буларак яшь үзенчәлекләрен чагылдырган лексик берәмлекләрне инглиз телендә чагыштырма планда өйрәнү укучыларда зур кызыксыну уята.

Татар телендә яшь үзенчәлекләрен чагылдырган лексиканың үзәгендә **“яшь”**, инглиз телендә **“age”** буларак таралыш алган.

Бүгенге көндә аңлатмалы сүзлектә “age” лексемасына болай ачыклык кертелә:

- agenoun (plural ages). 1. кеше гомеренең яисә булган әйбернең вакыт аралыгы. 2. тарихта яки геологиядә махсус вакыт. ages plural бик озак вакыт. come of age – зурларга хас хокук һәм йөкләмәләргә ия булу яшенә җитү.

- age (verb) – (ages, ageing, aged) – картаю.

- aged (adjective) – 1. өлкән яшьтә. 2. Бик карт [3, б. 10].

Татар телендә яшь үзенчәлекләрен чагылдырган лексиканың үзәгендә “яшь” сүзе тора. Төгәлләштереп әйткәндә, бу сүзнең аңлатмалы сүзлектә китерелгән II нче мәгънәсе күздә тотыла: II. Кеше яки кайбер хайван гомеренең бер елы || туган көннән алып үткән вакыт саны, ел исәбе; кешенең, хайванның, үсемлекнең яшәү чоры, периоды [1, б. 663].

Кешенең хронологик яшенә бәйле рәвештә, аны төрле атамалар белән йөртәләр.

Татар халкында яңа туган балага карата *бәби, сабый, нарасый, имчәк баласы* кебек сүзләр кулланыла. Яшь периодының иң беренчесе бәби, сабыйлык чорыннан гыйбарәт. Тормышының әлеге этабында торган затны исемләү өчен инглизләр бик күп төрле лексемалар кулланалар:

infant – яңа туган бала яки кечкенә бала

baby – бик яшь бала

child – 1. яшь кеше; малай яки кыз. 2. кемнеңдер кызы яки улы

kid – 1. бала.

Әлеге сүзләрдән иң еш кулланыла торганы – *child* лексемасы.

Татарларда “балачак” чоры күпләгән лексик берәмлекләр белән атала. Иң элек, шуны искәртик: бала дигәндә, татарлар бишектән төшкән, унике яшькәчә вакыт аралыгында булган кешене күздә тота.

Шуны ассызыклап үтик: инглиз телендә “балачак” периоды үзенчәлекләрен чагылдырган лексемалар әле дә ясалып торалар, ләкин алар инде заман үзенчәлекләрен гәүдәләндерәләр. Бер генә мисал белән чикләник. Соңгы берничә елда kid (бала) һәм adult (олы, балигъ булган) лексик берәмлекләренең берләшүе нигезендә **A kidult’**дигән сүз барлыкка килде. Ул үзен яшьләр субкультурасының бер вәкиле итеп тойган, балалар эшләгән эшләр белән шөгыльләнергә яратучы (уенчыклар белән яки видеоуеннар уйнарга, комикслар укырга, мультфильмнар карарга, һ.б.лар) зур, өлкән кеше дигән мәгънәне белдерә.

Балачак периодыннан соң бала үсмерлек чорына керә.

Аңлатмалы сүзлек мәгълүматлары буенча, үсмерлек периоды “балалыктан яшьлеккә кадәрге вакыт”, ә үсмер “12 дән 16-17 яшькә кадәр булган бала, яшүсмер” [1, б. 734]. Сүзлектә үсмерлек чорына кагылышлы зат атамалары аз санда. Үсмерләргә мөнәсәбәттә егет, кыз,

туташ кебек лексик берәмлекләр дә кулланыла. Үсмерлек периодыннан соң балигълык чоры килә. Бу чор татарларда шактый күп сүзләр белән атала. Мисал өчен, “Синонимнар сүзлеге”ндә мондый вариантлар теркәлгән: “балигъ булу – балигълык, баләгать, җитлегү, яше җитү, буйга җитү, буй җитү, зур булу, зураю, үсеп җиткән булу, җитлеккәнлек, җитешү”.

Үсмерлек периодын инглиз халкы унөч-унтугызяшьләр аралыгы дип билгелиләр һәм тормышының әлеге этабында торган затларга мөнәсәбәттә мондый лексик берәмлекләр кулланалар:

teenager – үсмерлек чорын кичерүче кеше

adolescent – балалык белән олылык арасында торучы яшь кеше [3, б. 7].

juvenile – закон буенча олылар рәтендә карала алмаган яшь кеше [3, б. 254].

junior – 1. яшьрәк. 2. яшь балалар турында. 3. дәрәҗә яки әһәмиятлелек ягыннан түбәнрәк рангта торучы. Кече офицер [3, б. 252].

Үсмерлек периодыннан соң килә торган яшьлек чоры инглиз телендә *youth* лексик берәмлеге белән белдерелә. Әлеге сүзнең мондый мәгънәләре бар: 1. Яшь булу, яшьлек периоды. 2. Яшь егет. 3. Яшь кешеләр [3, б. 555]. Кайвакыт яшьлек һәм үсмерлек периоды лексемалары бер-берсен алыштырырга да мөмкин.

*Яшьлек* периоды яр сөю, өйләнү, кияүгә чыгу, гомумән, яңа социаль статусларга ия булу вакыты буларак күзаллана. Шунлыктан, тормышның әлеге периодына мөнәсәбәттә кияү, килен, ир, хатын кебек туганлык терминологиясен тикшерү урынлы, дип саныйбыз. Гаилә әгъзасы буларак ир – “хатынның бергә тормыш итә торган иптәше” [1, б. 404].

Яшьлек чорыннан соң инглизләрдә maturity дип аталган җитлегү периоды килә. Җитлегү чорын кичерүче затны инглиз телендә берничә лексема белән атыйлар. Шуларга күз салыйк.

adult олы, балигъ булган дигән мәгънәдә. Аңлатмалы сүзлектә бу сүз “тулаем җитлеккән кеше” буларак аныклана.

grown-up – җитлеккән кеше дигән мәгънәгә ия.

Җитлеккән хатын-кызлар woman, җитлеккән ирләр man лексик берәмлекләре белән исемләнә.

Моннан тыш, аңлатмалы сүзлектә урын алган I нче мәгънәсендә, ягъни “хатын-кызга капма-каршы җенестәге кеше”мәгънәсендә дә кулланыла ала.

Гаилә әгъзасы буларак *хатын* лексемасы “иренә карата мөнәсәбәттә: никахланган тормыш иптәше” дигән мәгънәдә кулланыла. Шунысы да бар, әлеге лексик берәмлек аңлатмалы сүзлектә китерелгән I мәгънәсендә дә, ягъни “аерым бер сыйфатларга, табигый үзенчәлекләргә ия буларак, ир җенесенә капма-каршы җенестәге кеше || кыз баладан һәм үсмер кыздан аермалы буларак, шул ук җенестән, ләкин олырак яки балигъ булган кеше” мәгънәсендә дә кулланыла [1, б. 364].

*Килен* лексемасының мәгънәсе болай аңлатыла: “ике туганның хатыны”

*Кияү* сүзе яңа гына өйләнгән егет мәгънәсендә йөри.

Җитлегү периодына, кеше тормышының урта яшьләрдәге чорына мөнәсәбәтле лексик берәмлекләр әз санда булулары белән аерылып торалар һәм, башлыча, мөрәҗәгать сүзләре (әфәнде, гражданин һ.б.лар) һәм мөрәҗәгать сүзләр функциясен башкара торган туганлык терминнарында урын алалар.

Җитлегү периодына кергән кешеләрне татарлар *зурлар*дип атап йөртә башлый. Кешенең җитлегү чорына җитүен мөстәкыйль яши башлау белән бәйләп карау ир, хатын, ир-ат, хатын-кыз, килен, кияү, апа, абый, агай, абзый (урта яшьтәге ир-атка карата мөрәҗәгать сүзе мәгънәсендә) кебек лексик берәмлекләрне дә шушы төркем кысаларына кертү мөмкинлеге тудыра. Күреп үткәнебезчә, биредә урын алган лексик берәмлекләр башка яшь категорияләрендә дә урын алырга мөмкин. Бигрәк тә *егет-җилән, кыз-кыркын* кебек җыйма исемнәрдә бу ачык чагылыш таба. Мисал өчен, аңлатмалы сүзлектә “Егет-җилән – егетләр һәм яшүсмерләр” буларак аныклана Кыз-кыркын лексик берәмлеге сүзлектә “төрле яшьтәге кызлар” дип аңлатыла

Югарыда карап үтелгән лексемалар төсле үк, әлеге төркемдә дә туганлык терминологиясе зур урын били. Аларга күз төшереп үтик.

*Абый* лексик берәмлеге аңлатмалы сүзлектә ике мәгънәдә китерелгән. Абый. “и. 1. Үзеңнән олырак ир туган. 2. Яшь ягыннан үзеңнән олы ир кеше исеменә кушып әйтелә”

*Ага* лексемасының сүзлектә бирелгәнмәгънәсенә күз салыйк: 1. Яшь ягыннан олы ир туган, абый. 2. Үзеңнән олырак, өлкән ир кеше”.

Әлеге лексик берәмлекләргә яшь буенча капма-каршы мәгънәне белдергән туганлык термины – *эне*куела. Сүзлектә бу лексеманың мәгънәсе болай аныклана: “кече ир туган” Моннан тыш, сүзлектә әлеге сүзнең иркәләп эндәшү варианты буларак, *эне + -кәш модаль кушымчасы* моделе буенча төзелгән *энекәш* һәм үзеңнән кечерәк ир кешегә мөрәҗәгать итү варианты буларак *эне + Ізат берлек сан кушымчасы –м* моделе буенча төзелгән *энем* лексик берәмлекләре китерелгән. Һәр ике очракта да бу лексик берәмлек сөйләүчегә караганда кечерәк яшьтә булган кешегә мөнәсәбәттә кулланыла. *Эне* лексемасы, *агай* лексик берәмлеге белән бергә кулланылып, парлы сүз төзү хисабына, *агай-эне* җыйма исем ясауда да катнаша. Аңлатмалы сүзлек аның ике мәгънәсен китерә: “1. Ага һәм эне, агалы-энеле, бертуган ике ир кеше. 2. Үз кешеләр, үзебезнең кешеләр”

Олы кыз туганнарга татарлар *апа, апай, түти* лексик берәмлекләре белән эндәшәләр. Бу лексемалар еш кына яшь буенча үзеңнән олы булган хатын-кызлар исемнәре белән янәшә әйтелә.*Сеңел* лексемасы сүзлек мәгълүматлары буенча, “үзеңнән кече кыз туган” дигән мәгънәдә йөри.

“Картлык” периодына кагылышлы лексик берәмлекләрне тикшерү шуны күрсәтте: татарлар элек-электән өлкән буынга ихтирамлы, игътибарлы булган, гаиләдә әби-бабайларга урын түрдән бирелгән. Әлеге күренешләр картларнызур тормыш тәҗрибәсе туплаган, үгет-нәсихәткә оста, акыл, зирәклек эталоны итеп сурәтләүгә алшарт булып тора. Аңлатмалы сүзлеккә мөрәҗәгать итеп тә моңа мисаллар китерергә мөмкин:

Анакай – олы яшьтәге хатын-кызга мөрәҗәгать сүзе

Абыстай сүзе III нче мәгънәсендә: өлкәнрәк хатын-кызга мөрәҗәгать сүзе || олы яшьтәге хатын-кызны ихтирам итү, зурлау йөзеннән исеменә кушып әйтелә

Татар телендә еш очрый торган мөһим туганлык терминнары рәтендә *баба (бабай), әби* дә бар. *Онык* лексемасы сүзлектә китерелгән “улыңның яки кызыңның баласы” мәгънәсендә йөри

Шулай итеп, татар телендә яшь үзенчәлекләренә бәйле төстә мондый кеше портреты барлыкка килә: яңа туган балага карата бәби, сабый, нарасый кебек лексемалар кулланыла. Үсә төшкәч, балаларны гендер буенча аерымлауга зур игътибар бирелә (кыз, малай). Үсмерлек чорына караган лексик берәмлекләр бик аз санда (үсмер). Яшьлек чоры лексемалары сөйгән яр табу, гаилә кору белән бәйлелектә күзаллана (килен, кияү, ир, хатын). Җитлегү периодында кешене абый, апа, агай, ханым, әфәнде кебек туганлык терминнары, мөрәҗәгать сүзләре белән атыйлар. Лексикографик мәгълүматлардан күренгәнчә, картлык – акыл туплау, зирәклектә, әхлаклылыкта үрнәк күрсәтү периоды буларак тасвирлана.

Инглизләрдә картлык периодын белдерү өчен old age сүзе кулланыла һәм “Инглиз теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә аңа “кешенең картаю периоды” буларак ачыклык кертелә. Картаю периоды үзенчәлекләре инглизләрдә fade (сулу, кибү), wrinkle (җыерчык) кебек лексик берәмлекләр белән белдерелә. Татарлар төсле үк, инглиз халкы да карт кешеләргә ихтирам, кадер-хөрмәт күрсәтә.

Шулай итеп, инглизләрдә тормышының нинди периодында булуына бәйле рәвештә, кешегә мөнәсәбәттә бала (child), үсмер (teenager), яшькеше (youth), җитлеккән кеше (adult), карт кеше (old man) кебек лексемалар кулланыла.

Күзәтүләрдән чыгып шуны әйтергә була, татар телендә дә, инглиз телендә дә яшь үзенчәлеген чагылдырган лексик катлам шактый бай.

## Әдәбият

1. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда / редколлегия Л.Т. Махмутова, М.Г. Мөхәммәдиев, К.С. Сабиров, Ш.С. Ханбикова. – 3 т.: Т – Һ.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 832 б.
2. Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С. Синонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 1999. – 255 б.
3. Хокинс Дж. Толковый словарь английского языка Oxford = Oxford Concise School Dictionary: 40000 слов и выражений. – М.: Астрель АСТ, 2008. – 556 с.

УДК 811

# ХУДОЖЕСТВЕННЫЕ ФУНКЦИИ РЕАЛИЙ В ТАТАРСКИХ ИСТОРИЧЕСКИХ РОМАНАХ

***Камаева Рима Бизяновна***
Елабужский институт Казанского (Приволжского) федерального университета,
г. Елабуга, Татарстан, Россия
*e-mail: kamaeva-r@mail.ru*

**Аннотация.** *В статье рассматривается функционирование реалий в татарских исторических произведениях. В ходе исследования определены и уточнены способы перевода реалий на русский язык.*

**Ключевые слова**: *реалия, художественное произведение, национальный колорит, способы перевода.*

# ARTISTIC FUNCTIONS OF REALITIES IN TATAR HISTORICAL NOVELS

***Kamaeva Rima Bizyanovna***
Elabuga Institute of Kazan (Volga Region) Federal University,
Elabuga, Tatarstan, Russia

**Abstract.** *The article examines the functioning of realities in Tatar historical works. In the course of the study, the ways of translating realities into Russian were identified and clarified.*

**Keywords:** *reality, artwork, national color, translation methods.*

Реалияләр тел һәм мәдәниятнең милли үзенчәлекләрен чагылдыра. Бу лексик берәмлекләр гореф-гадәтләрне, тормыш-көнкүреш предметларын, тарихи вакыйгаларны белдерә. Реалияләрне бер телдән икенче телгә тәңгәл тәрҗемә белән күчереп булмый, шуңа күрә аларны тәрҗемә итүне тикшерү лингвистика өлкәсендә мөһим мәсьәлә булып кала.

Н.Фәттах, М.Хәбибуллин, Р.Батулла, В.Имамов, Ф.Сафин кебек күренекле язучыларның романнарына милли һәм тарихи төсмерләр хас. Алар VII-XVI гасырларда татар халкы тормышын киң колачлый, шул исәптән төрки халыкларның гореф-гадәтләрен, яшәү рәвешен тасвирлый.

Реалияләр куллану язучыларга тасвирлана торган тарихи вакыйгаларны, шул чор өчен характерлы булган тормыш-көнкүрешне реаль тасвирларга ярдәм итә. Тәрҗемә барышында әдәби әсәренең милли-мәдәни һәм тарихи үзенчәлекләрен саклап калу тәрҗемәче алдында торган мөһим бурычларның берсе булып тора. Тәрҗемәдә чынбарлыкны дөрес итеп бирү өчен тәрҗемә ителә торган тел үзенчәлекләрен белү, алар турында дөрес күзаллау мөһим алшарт булып тора. Тәрҗемә бер телдән икенчесенә күчүне генә түгел, ә бер мәдәнияттән икенчесенә күчүне дә аңлата.

Бу эшебездә өйрәнү өчен лексик материал Ф.Сафинның «Саташып аткан таң» («Заблудившийся рассвет» Ф.Фәизев, Р.Хәсәнова тәрҗемәсе), Р.Батулланың “Сөембикә” (“Сююм-бике – царица казанская”, Р.Вәлиев тәрҗемәсе) романнарыннан алынды.

Тикшерү өчен алынган фактик материал күрсәткәнчә, татар фразеологик берәмлекләре составында милли үзенчәлеккә ия тотрыклы берәмлекләр бар.

Ф.Сафинның «Саташып аткан таң» («Заблудившийся рассвет» Ф. Фәизев, Р. Хәсәнова тәрҗемәсе) романында *зиһен сандыгына салып кую* (досл. *положить в сундук памяти*) фразеологизмы кулланылган. Бу фразеологизм сүзлекләрдә теркәлмәгән. *Хәтер сандыгы, хәтер капчыгы*фразеологик берәмлекләрнең үзенчәлекле формасы булып тора. Татар халкында сандык иң кадерле әйбер буларак ассоциацияләнә. *Зиһен сандыгына салып кую* фразеологик берәмлеге җиткерелгән хәбәрнеңбик мөһим булуын, аны истә тотарга һәм хәтер тирәнлегендә сакларга кирәклекне аңлата. Тәрҗемә барышында тотрыклы сүзтезмә *истә калдыр* сүзе белән алмаштырыла, сандык съзе тщрьемщдщ тцшереп калдырыла, шул ук вакытта тәрҗемәче контекстта компенсация алымыннан файдалана, төп герой турында өстәмә мәгълүмат бирә.

«– Ул миңа әйтте, мин сиңа тапшырам. *Зиһен сандыгыңа салып куярга тырыш* син, егет» [4, б. 152]. / «Ченекей зря не скажет, в психологии он гроссмейстер, так что *запомни* его слова, браток» [5, б.151].

Ф.Сафинның шул ук романында *түбәтәй асты бөтенләй ук буш түгел* фразеологик әйтелмә очрый. Тәрҗемә барышында тәрҗемәче калькалаштыру ысулы белән бергә сүзләр өстәү алымыннан да өлешчә файдаланган. *Түбәтәй* сүзе транскрипция алымы белән тәрҗемә ителгән.

« – Җегетнең *түбәтәй асты бөтенләй ук буш түгел*» [4,б. 92]. /« – У этого джигита *под тюбетейкой голова не пустая*» [5, б.84].

Р.Батулланың «Сөембикә» романында (рус теленә Р. Валеев тәрҗемәсе) *сер сандыгындагы сандугач очты чыкты* фразеологизмы кулланылган. Тәрҗемә барышында тәрҗемәче тарафыннан бу тотрыклы сүзтезмә аңлатма бирү юлы белән тәрҗемә ителгән (*поняла, чтооплошала).*

«– *Сер сандыгындагы сандугач очты чыкты*, хәзер аны тотып булмаячак иде» [1, б.162]. / «И тут же *поняла, что оплошала*»[2, б. 92].

Р.Батулланың «Сөембикә» романында *Үткән эшкә салават* җөмләсе тулысынча фразеологик әйтелмәдән тора. Рус теленә тасвирлу ысулы белән тәрҗемә ителә. «*Үткән эшкә салават*»[1, б. 54]. / « – *Что теперь позднее сожаление*» [2, б. 21].

Фразеологик берәмлекләр составындагы реалияләрне (бу очракта сандык, түбәтәй сүзләре) рус теленә тәрҗемә итү барышында тәрҗемәчеләр транскрипция, компенсация алымнарыннан файдаланганнар.

**Әдәбият**


1. Батулла Р. Сөембикә: Кыйсса. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 415 б.
2. Батулла Р. Сююм-бике – царица казанская. Роман. Перевод Р.Валеева. – Казань: «Хәтер», 2001. – 272 с.
3. Салимова Д.А. Тимерханов А.А. Двуязычие и перевод: монография. – М.: ФЛИНТА: Наука, 2012. – 280 с.
4. Сафин, Ф.М. Саташып аткан таң: роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 726 б.
5. Сафин Ф.М. Заблудившийся рассвет: роман. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2014. – 664 с.

УДК 81`371

# ФРАЗЕОЛОГИЧЕСКИЕ ЕДИНИЦЫ, ВЫРАЖАЮЩИЕ ЭМОЦИИ И ЧУВСТВА ЧЕЛОВЕКА, В ТАТАРСКОМ И КИТАЙСКОМ ЯЗЫКАХ

***Кабирова Земфира Зуфаровна***
Елабужский институт Казанского (Приволжского) федерального университета,
г. Елабуга, Татарстан, Российская Федерация
*e-mail: zemfira.khan@gmail.com*

**Аннотация.** *Исследование фразеологии позволяет выявить национально-специфические особенности в языковой картине мира разных народов, в частности, представления о значимых эмоциях человека, в данном случае, представителей татарской и китайской лингвокультур.*
**Ключевые слова:** *языковая картина мира; психоэмоциональное состояние человека; эмотивные фразеологизмы.*

# PHRASEOLOGICALUNITS EXPRESSING HUMAN EMOTIONS AND FEELINGS IN THE TATAR AND CHINESE LANGUAGES

***Kabirova Zemfira Zufarovna***
Elabuga Institute of the Kazan (Volga region) Federal University,
Elabuga, Tatarstan, Russia

**Abstract.** *The study of phraseology makes it possible to identify national-specific features in the linguistic picture of the world of different peoples, in particular, ideas about the significant emotions of a person, in this case, representatives of the Tatar and Chinese linguistic cultures.*
**Keywords:** *language picture of the world; human psycho-emotional state; emotive phraseological units.*

Фразеологизмы играют особую роль в создании языковой картины мира. В устойчивых оборотах нередко отражаются особенности культуры народа, его истории, народные представления о тех или иных предметах и явлениях, национально обусловленные стереотипы восприятия окружающего мира.

Специфика татарских фразеологизмов хорошо видна при сопоставлении с фразеологизмами других языков, соотнесенных с ними по смыслу. Например, по-татарски – чебеннән фил ясау, по-английски – making a mountain out of a molehill (дословно “делать гору из кротовой норы”), по-русски – делать из мухи слона, по-китайски – 小题大做 xiǎotídàzuò (дословно “маленькую проблему сделать большой”). Это сопоставление свидетельствует об оригинальности фразеологии каждого языка.

Как и в татарском языке, фразеологизмы китайского языка отражают менталитет народа, его историю, национальные традиции и обычаи, специфику восприятия окружающего мира. Китайские идиомы — это своеобразные памятники культуры, в содержании которых заключена философская мудрость китайского народа, многовековая история страны, неповторимые национально-культурные черты. Китайский язык богат своим фразеологическим фондом. Через познание происхождения фразеологизмов, а также понимание сущности устойчивых выражений в китайском языке можно познать культуру и самобытность китайского народа [2].

Среди татарских и китайских фразеологизмов существует немалое количество фразеологических единиц, характеризующих чувства человека, как одного из важных психологических и эмоциональных его состояний. Выбор для анализа фразеологических единиц, раскрывающих эмоции и чувства человека, объясняется их широкой

употребительностью в повседневной жизни, а также тем, что они ярко отражают особенности эмоциональной жизни народа.

В.И. Шаховский подчеркивает, что эмоции человека, независимо от национальной принадлежности, являются универсальными, поскольку отражают опыт восприятия и осмысления психической жизни человека. Эмоции и чувства представляют собой основу всего внутреннего мира (организма) человека, результат его активного взаимодействия с объективной действительностью. Грусть, печаль, скорбь, слезы – всё это компоненты одной и той же реакции целостного организма на определенные сложные изменения окружающей среды. По мнению исследователя, эмотивная лексика отражает вербализованные эмоциональные реакции, состояния и отношения людей к миру и к самим себе в этом мире. Коммуникативная потребность в социуме отражает существование лексических средств ее удовлетворения – эмотивных знаков языка [5].

Анализлана торган антиномиянең төп төшенчәләрен карарбыз. «Ата-ана (ата-аналар)»төп төшенчәсе түбәндәге образлар ярдәмендә тәкъдим ителгән.

«Ата-ана мәхәббәте» әти-әнинең үз балаларына булган бәйләнешенең тирәнлеген күрсәтә: *Ата-ана догасы утка-суга батырмас; Ата йөрәге таудан өлкән, ана йөрәге диңгездән тирән; Бала – бәгырь; Бала өчен кеше утка-суга төшәр.*

«Ата-анага мәхәббәт» ата-аналар мәхәббәтенеңикенче ягын чагылдыра, һәм әти-әни янындавакытта тынычлык һәм уңайлылык хөкем сөрүен күрсәтә:*Атасы бар – чәчәк, анасы бар – гөл.*

«Ата-аналарның кабатланмас булуы» әти-әнинең алыштыргысыз һәм иң якын кешеләре булуын, әтинең яки әнинең кеше язмышында аерым урын алып торуын күрсәтә: *Ана – йортның тирәге, Кояш янында җылылык, ана янында тереклек.*

«Ата-ананың кырыслыгы» балалар тәрбияләү белән бәйләнешне күрсәтә. Бу исә татар лингвомәдәниятендә ата-ана мәхәббәтенең башка бер ягы: *Алтмыштагыга суксаң да, алтыдагыга сукма, Артык кыссаң, сытыла.*Әти – гаилә башлыгы һәм туйдыручы. Иң авыр хезмәт мәшәкатьләре әти җилкәсенә төшә. Әти – татар җәмгыятендә гаилә тормышының төп мәсьәләләрен хәл итүдә өстенлекләр һәм гаиләдә кагылгысыз дәрҗәсе бар кеше. Бу татар мәкальләрендә ачык чагыла. Мәсәлән, *Ата аркасы – кала аркасы.* Моннан тыш әле гаилә башлыгы – үрнәк тә, балаларына тәрбия һәм киңәш бирүче: *Җәйләүгә тугай яхшы, киңәшкә атай яхшы.*

Татар лингвомәдәниятендә ата-аналарга карата барлыкка килгән бәя мәкальләрдә дә теркәлгән. Ата-аналарны илаһилаштыру аларның Аллаһы Тәгалә белән бәйләнешен чагылдыра Атаң-анаң – икенче Аллаң; Ана хакы – Алла хакы дигән мәкальләр шул турыда сөйли.

Этномәдәни бәйләнешләрне тикшерүчеләр гаилә әгъзалары арасында рольләр бүленешенең аерым үзенчәлекләрен билгеләп үтәләр.Әтиләр күбрәк милләткә хас милли үзаңны формалаштыруда катнашалар, ә әниләр, нигездә, мәдәният һәм көнкүрешкәбәйле үзенчәлекләрне тапшыралар.Татар гаиләсендә ана икътисади яктан иерархик буйсынуда яши, ул гаиләдә өй хуҗалыгын алып барырга, балаларны карарга тиеш була, һәм бу яктан ул бик мөһим эш башкара.

Балаларны тәрбияләү процессында гаиләнең иң мөһим бурычларыннан берсе – этномәдәни кыйммәтләрне тапшыру, этник үзаң тәрбияләү.Нәкъ менә гаиләдә балалар милли гореф-гадәтләр, халык риваятьләре белән танышалар.Бер этнос вәкиле буларак гаилә хәзер дә мөһим роль уйнавын дәвам итә.

Мәкальләрдә «Балалар» төшенчәсе бик күпкырлы чагылыш тапкан. Татар мәкальләрендә түбәндәге образлар бар.

«Балалар – шатлык (Дети – радость)» балалар һәм ата-аналар арасындагы яхшы мөнәсәбәтләрне күрсәтә.Балалар әтиләренә рәхмәтле, һәр нәрсәдә тыңлаулы, тыныч, өлкән яшьтәге әти-әниләренең язмышына җаваплылыкны үз өсләренә алырга әзер һ. б.: Бала – ана-анага алтын багана.

«Балаларның шөкерсезлеге» балаларның үз ата-аналарына карата битарафлыгы билгеләрен күрсәтә.Мондый тормыш ситуацияләре типик һәм сизелерлек паремия катламы белән чагылдырыла: Явыз бала атасының авызын ябар, Күз нурым дип атаганым күз утымны очырды.

«Ятимлек» образы ятимнәрнең бәхетсез язмышын, мәхрүм ителүен һәм үпкәсен, шулай ук аның иң яхшы өлешенә һәм хәтта күк көчләре ярдәменә өметен күрсәтә:Ятим балага ярдәм ит, Ятимнәрнең бәйрәме – яңа күлмәк кигәндә һәм башкалар.

Шулай итеп, үткәрелгән тикшерену нәтиҗәсендә түбәндәге нәтиҗәләр ясарга мөмкин. Мәкальләрдә башка жанрлар белән чагыштырганда тыңлаучыга тәэсир итү, кешегә җәмгыять, гаилә яки шәхси мәнфәгатьләрдә нәрсә эшләргә ярамаганлыгын күрсәтеп, нәрсә файдалы икәнлеген күрсәтү омтылышы ныграк сизелә. Күренешне тасвирлап, мәкальләр аңа бәя бирәләр. Бу контраст образларны һәм төшенчәләрне чагыштыруда ачык күренә. «Ата-аналар – балалар» антиномиясе төрле тормыш күзәтүләрен, традицион күзаллауларны, фәлсәфи гомумиләштерүләрне чагылдыруның образлы-конкрет формасын, шул телдәсөйләшүчеләр

өчен иң мөһим күренешләрне, аларның мәкальләрдә чагылыш табуын күрергә мөмкинлек бирә.

Шулай итеп, татар мәкальләре үзләренә хас үзенчәлек буенча аеруча тәэсирлелеккә омтыла һәм шул ук вакытта еш кына ике предметны яки күренешне чагыштырырга мөмкинлек бирә.

**Әдәбият**


1. Исанбет Н. Татар халык мәкальләре: кереш мәкалә һәм аңлатмалар белән: в 3 томах.Т. 2. – Казан: Татар. книж. изд., 2010. – 749 с.
2. Селиверстова Е. И. Вода и водоём в русской паремиологии: бинарные отношения // «Вода»в славянской фразеологии и паремиологии: в 2 т. – Будапешт: Тинта, 2013. – С. 554-560


УДК 398.33

## СОЦИАЛЬНО-КУЛЬТУРОЛОГИЧЕСКИЕ АСПЕКТЫ ОБРЯДА «СӨРӘН СУГУ»


***Самитова Савия Гималтыновна***
Казанский научно-исследовательский университет,
г. Казань, Татарстан, Российская Федерация
*e-mail: savilas@yandex.ru*



**Аннотация.** *Настоящая работа посвящена исследованию генезиса и бытования обряда «Сөрән сугу». На основании изучения социально-культурологических аспектов названного обряда были выявлены особенности, характеризующие роль последнего в социальной и духовной жизни татарского народа, также интерпретированы ритуалы, символизирующие поло-возрастные формы инициации.*



**Ключевые слова:** *Сөрән сугу; национальный обрядовый праздник; инициация; приданое; татарский.*


## SOCIO-CULTURAL ASPECTS OF THE «SORAN SUGU» RITE


***Samitova Saviia Gimaltynovna***
Kazan Research University,
Kazan, Tatarstan, Russian Federation



**Annotation.** *This work is devoted to the study of the genesis and existence of the rite "Soran Sugu". Based on the study of the socio-cultural aspects of this rite, the features characterizing the role of the latter in the social and spiritual life of the Tatar people were identified, rituals symbolizing the gender-age forms of initiation were also interpreted.*



**Keywords:** *Soran sugu; national ceremonial holiday; initiation; dowry; Tatar.*


Сөрән салу, сөрән сугу – (сурен) старинный татарский народный обряд сбора приданого (подарков) на весенний обрядовый праздник Сабантуй. Будучи праздником весеннего цикла, проводится после завершения посевных работ накануне Сабантуя.

Традиционно такой обряд бытует у многих народов региона Среднего Поволжья – Прикамья – Приуралья и назвается почти одинаково: у башкирдов – «һөрән», у чувашей – «серен», у марийцев –«сюрем», у удмуртов – «сурен». Отчетливо прослеживается связь обряда с общими языческими корнями народов Поволжья и Приуралья. Марийский «сюрем» имеет

важное религиозное значение для марийцев, является одним из главных праздников летнего календарного цикла, сопровождается крупным молением с жертвоприношением, проводится группой деревень, чуваши проводили «серен» для ритуального очищения-изгнания из селения злых духов накануне великого дня Манкун (праздник весеннего нового года по древне-чувашскому календарю), «сурен» у удмуртов считается обрядом очищения путем умывания, окуривания помещений, животных; очерчивания металлическим предметом границ усадьбы, группы людей; постукивания палкой по воротам, домам – *изгнание шайтана.*

Другое, более важное значение ритуала постукивания ворот жердью имеет символическое значение. Для разных народов этот образ имел одни и те же значения: столб, шест, посох, мировое дерево ассоциировались с мужским производительным началом – фаллосом.Фаллический символ служил знаком плодородия, мужского начала, физической и духовной силы, благополучия, жизни, урожая, активности. Календарные обряды и традиции татар берут начало с древних времен – тенгрианства. Фаллический культ своими корнями восходит именно к культу Неба древних тюрки. Он являлся важным атрибутом в всех обрядах.

У казанских татар бытовал иной вариант обряда, схожий с днем сбора крашеных яиц и назывался сөрән сугу (ударять, стукать), сөрән чабу (бегать, скакать) или сабантуй күкәе җыю (сбор яиц на сабантуй). В сборе их так же участвовали только юноши, которые группировались по 10-15 человек и разъезжались на украшенных лошадях. В больших деревнях таких групп было несколько. Сбор яиц сопровождался различными прибаутками, словами благодарности, исполнением песен и танцев.

После завершения сбора яиц юноши состязались в беге, конных скачках, победителей одаривали собранными яйцами.

На сбор приданого допускалисьтолько юноши и подростки в национальном одеянии с длинным шестом, куда завязывали подарочные платки и вышитые полотенца. «Сөрән сугу» – чисто мужской праздник без участия женщин. В древние времена праздники отмечались лицами одного пола, а участвовать в нем представителям другого пола не разрешалось.

В традиционных обрядах всех народов, в том числе и «Сөрән сугу», сохранившихся до наших времен, можно обнаружить нечто подобное древних ритуалов поло-возрастного посвящения – инициации. Целью обряда «Сөрән сугу»является своего рода идентификация юношей, которые утверждают, что они зрелые полноправные члены общества и доказывают обществу свое право на самостоятельное существование. После свершения определенных торжественных действий, они получают новый статус «мужчина», которым позволено обзавестись собственной семьей и бытом. Именно по этой причине в «Сөрән сугу»могли участвовать только юноши. Следует отметить и тот факт, что инициации мальчиков и девочек, почти всегда проходили отдельно, так как практические навыки поведения их семье, обществе в корне отличаются друг от друга.

Ритуал инициации в народных обрядах всегда проводился группами, а не индивидуально, что создавало некий опыт коллективной трансформации. Указывая на психологическое значение таких обрядов, К.Г.Юнг пишет: «Регрессивное отождествление с низменными и наиболее примитивными состояниями сознания неизменно связывается с обретением более высокого смысла жизни; таков живительный эффект регрессивного отождествления с полуживотными предками Каменного века»[6, с.154].По мнению психолога, инициации способствуют нормальному развитию и взрослению человека без болезненных переживаний и не позволяют ему впадать в инфантильные состояния. После прохождения ритуала юноша сам способен решать свои проблемы, не прибегая помощи родителей, то есть, не впадая в регрессивные состояния (в детство). К.Г.Юнг, указывая важность инициации в становлении зрелой личности с развитой Самостью, также отмечает, что «источником дальнейшего роста в Героя в конечном итоге в Мудрого Старца, воплощая, таким образом, все аспекты Самости возможна только через преобразования и инициации» [4, с.132].

Юноши верхом («атлы сөрән») на наряженных лошадях объезжали или пешком («җәяүле сөрән») обходили деревню, собирая подарки для праздника — вышитые и тканые полотенца, яйца и др. Особое внимание уделяется при этом к домам, в которых проживают

девушки на выданье или молодые невесты. Юноши, переходившие из детства во взрослую жизнь, обходя дома села, высматривали девушек, выбирая себе невест. Второй смысл обряда и его ритуальное содержание, как отмечает М.Х.Бакиров, сводилось к громкому приветствию наступающей весны и одариванию жертвенными подарками юношей ради будущего урожая [1, с.55].

Специально для обряда одевают валенки. История их уходит в далекое прошлое данного обряда. Как пишет Бакиров М.Х. «Будучи праздником весеннего возрождения, он проводился обычно в апреле, когда начиналась весенняя распутица и ледоход, и накануне выгона скота на пастбище и весеннего сева» [1, с.55]. Юноши ходили по деревне сутки, по ночам было холодно, а валенки согревали их и защищали от холода.

«Сөрән сугу»– это обряд по приготовлению матушки-земли к севу. Люди, таким образом, готовили ее к приему семян и просили дать хороший урожай. На третий день проводился самый большой праздник Сабантуй. В Сурене участие в празднике одних только ребят, по всей вероятности, раскрывает эротическую сторону обряда. Земля в тюркской мифологии представляется существом женского рода. И, вероятно, по этой причине Сурен и Сабантуй являлись мужскими праздниками и на поле выходили лишь мужчины. У татар женщины также не принимали участия в весенне-полевых работах. По данным, полученным от жителей деревеньТатарстана в настоящее время обряд Сурен проводится как сбор подарка к Сабантую. Значение и функции обряда претерпели некоторые изменения. Но одно осталось неизменным – в нем участвуют только ребята-призывники.

Заклички, которые произносили сборщики, содержали в себе различные благопожелания тем, кто был щедр в своих угощениях.

В основе обряда «Сөрән сугу» лежит магическое значение очищения перед наступлением весенних работ. Как у славянских народов очищение происходило через священный огонь. Для этого на околице села или на возвышенности рядом с деревней жгли большие костры и перепрыгивали через них. Тем самым участники «очищались» от грехов, от воздействия злых духов. Отправляясь туда, говорили, что идут караулить [5, с.33]. Во время обряда исполняется и своя поэтика:

| | |
|---|---|
| *Алтын гына да ишек, көмеш тупса,* | *Двери-то, петли серебряные,* |
| *Атлый гына да йөгереп без кердек,* | *Прибежали-то мы к вам теперь,* |
| *Әби дә бабай – илнең солтаннары,* | *Дед и бабка – самые почетные (дорогие),* |
| *Табынарыгызны хуп күрдек.* | *А столы-то нам впрямь по душе.* |
| *Аслары да йомырка, өсләре май,* | *Понизу-то яйца, сверху масло,* |
| *Төбеләрең телең йотарлык,* | *Яичница-то – язык проглотишь,* |
| *Кибән-эскертләрегез ишәйсен,* | *Да прибудет вам стогов и скирдов-то,* |
| *Гомерегездә күрмәгез тарлык.* [2, с.74]. | *И никогда не знайте нужды.* |

Традиционный обряд весеннего цикла – «Сөрән салу»сохраняет свою аутентичную семантическую структуру, продолжает развиваться и в наши дни в татарских деревнях всех районов Республики Татарстан.

**Литература**


1. Бакиров М. Татарский фольклор: монография. Второе дополненное издание. – Казань: АН РТ, 2018. – 406 с.
2. Баязитова Ф.С. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары – Казан: Татар.кит. нәшр., 1995 – 158 б.
3. Самохвалов В.П. Психоаналитический словарь и работа с символами сновидений и фантазий. – Симферополь: СОНАТ, 1999. – 184 с.
4. Уразманова Р.К. Обряды и праздники татар Поволжья и Урала – Казань: Дом печати, 2001. – 198с.
5. Уразманова Р.К. Современные обряды татарского народа. – Казань, 1984. –160 с.

6. Юнг К.Г. О перерождении// Синхронистичность. – М.: РЕФЛ-БУК, 1997. –313 с.

УДК 808.1

# ОПЫТ ПЕРЕВОДА ПРОИЗВЕДЕНИЙ МУСЫ БИГИЕВА НА ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК И СОВРЕМЕННЫЙ ТАТАРСКИЙ ЛИТЕРАТУРНЫЙ ЯЗЫК МУСА БИГИЕВНЕҢ ӘСӘРЛӘРЕН ТАТАР ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ТӘҖРИБӘСЕ ҺӘМ ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕ

***Хайрутдинов Айдар Гарифутдинович***
Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, г. Казань, Российская Федерация
*e-mail: khaidar67@mail.ru*

**Аннотация.** *В данной статье рассматривается ряд вопросов, стоящих в ходе перевода древних религиозных книг на современный татарский язык, рассказывается о их влиянии на развитие татарского литературного языка.*

**Ключевые слова**: *религиозная лексика; вопросы перевода; транслитерация; орфография; религиозное наследие.*

# EXPERIENCE IN TRANSLATING MUSA BIGIEV'S WORKS INTO TATAR AND MODERN TATAR LITERARY LANGUAGE

***Khairutdinov Aidar Garifutdinovich***
Sh. Marjani Institute of History, Kazan, Tatarstan, Russia

**Abstract.** *The article discusses a number of issues that remained during the translation of ancient religious books into modern Tatar, talks about their impact on the enrichment and development of the Tatar literary language.*

**Keywords**: *religious vocabulary, translation issues; transliteration, spelling, religious heritage.*

Инде берничә дистә ел дәвамында хәзерге татар әдәби теле лексикасының дини эчтәлекле сүзләр, гыйбарәләр, төшенчәләр исәбенә киңәюе күзәтелә. Әлеге процессның нигезендә узган гасырның 90-нчы еллар башында ислам диненең халык тормышына кайта башлавы ята. Татар әдәби теле лексикасының баюы ике юл белән бара: берсе дини лексиканың сөйләм теленә тәэсир итүе, икенчесе – әдәби телнең язмада теркәлгән шәкеленең, ягъни китап һәм массакүләм матбугат чаралары теленә тәэсир итүе. Искә алынган юнәлешләр эчендә барган үзгәрешләр, әлбәттә, тел галимнәре тарафыннан өйрәнелергә тиеш һәм өйрәнелә дә булса кирәк. Бу йөздән сөйләм телебездә дини лексиканың бик сай һәм гаять чикләнгән бер катлам буларак дәһрилек дәверендә дә яшәп килгәнен истә тотарга кирәк. Әмма, шул дәһрилек дәверендә дини әдәбият дигән төшенчә юк дәрәҗәсендә иде. Һәрхәлдә, нәшриятләрдә рәсми басмалар буларак чыккан дини китаплар юк иде. Соңгы берничә дистә ел дәвамында бу хәл кискен сурәттә үзгәрде. Бүген без татар телендә язылган дини әдәбият массивының барлыкка килүен бер чынбарлык итеп кабул итә алабыз. Шуңа күрә, минем уйлавымча, сөйләм теле белән китап телен чагыштырганда, иң зур һәм тирән үзгәрешләр китап теленә хас.

Әлеге процессны вакыт агымы күзлегеннән, ягъни 1990-нчы еллар башыннан хәзерге көнгәчә, карап өйрәнү дөрес булыр иде. Әмма шулай итәр алдыннан минем бераз алга китеп сүз йөртеп аласым килә. Мисал өчен, 2007нче елдан башлап Россиядә ислам тарихын һәм мәдәниятен тирәнтен өйрәнгән белгечләр әзерләү программасы кысаларында әзерләнгән уку-укыту кулланмаларның, шул исәптән төрле дисциплиналар буенча программалар, методик кулланмалар, лекцияләр, дәреслекләр, хрестоматияләр һ.б. шундыйларның татар телендә

чыкканнарын китерәсем килә. Әлеге программада миңа 2007 нче елдан башлап 2016 елга кадәр автор, белгеч (эксперт), рецензензияләр язучы һәм эшне килештерүче (координатор) булып эшләргә туры килде. Шул дәвер эчендә минем кулларым аркылы имзам куелган эш рәвешендә генә 200дән артык уку-укыту кулланмалары узды (координатор буларак үзем аркылы үткәгән кульязмаларның саны, әлбәттә, күпкә артыграк). Аларның күпчелеге урыс телендә язылган иде, әмма арада татар телендә язылганнары да бар иде.

Искә алынган кульязмалар мәсьәләнең асылын күрсәтә: хәзерге вакытта татар әдәби телендә яңа катлам лексик-семантик төшенчәләр барлыкка килә, ул да былса дини лексика, дини төшенчәләр. Болар сөйләм телебездә сакланып калган һәм шактый примитив дини лексика кысаларына сыймыйлар, чөнки элек андый лексиканың күпчелеген дини йолаларга караган сүзләр һәм төшенчәләр тәшкил иткән булса, хәзерге вакытта телебез дини-фәлсәфи лексика исәбенә киңәя. Минем чыгышым әлеге процессның үзенчәлекләрен күренекле татар дин галиме, ислам фәлсәфәчесе Муса Бигиевнең әсәрләрен хәзерге татар теленә тәрҗемә итү тәҗрибәсе нигезендә күрсәтүгә багышлана.

Татар әдәбиятендә борынгы әсәрләрне тәрҗемә кыйлу өлкәсендә зур тәҗрибә тупланган. Шулай да татарчага тәрҗемә фәнендә яңалыкларга да урын бар. Әлеге мәсьәлә хәтта көнүзәк мәсьәлә булып тора. Алга таба әйтеләсе сүзләрем дә Бигиевнең гыйльми мирасын тәрҗемә итү мисалында шул мәсьәләне чишү юлында ясалган тәкъдимнәр буларак кабул ителсен.

Тел белеме күзлегеннән караганда Муса Бигиевнең мирасы дини төшенчәләрне, аерым алганда ислам фәлсәфәсен татар, яки, дөресрәге, госманлы-татар телендә бәян иткән булуы белән дә әһәмияткә ия. Галимнең әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү эше дә акрынлап бара. Мәсәлән шәех мөфти Равил хәзрәт Гайнетдин тарафыннан җитәкләнгән Русия мөселманнарының рухани нәзарәтендә эшләүче мөфтинең урынбасары Вәис углы Дамир Мөхетдинов тарафыннан татар дини мирасын халыкка кайтару буенча күләмле зур эш алып барыла. Бигиев кенә түгел, башка татар дин әһелләренең дә әсәрләре тәрҗемә ителеп сыйфатлы китаплар буларак дөнья күрә. Шул исәптән, Муса әфәнденең әсәрләрен татар теленә тәрҗемәләре дә чыгачак. Шушы эш барышында байтак кына кызыклы лингвистик күренешләргә юлыктым.

Муса әфәнденең язма теле турында сүзгә күчәм. Аның китап телен татар китап теле дип атап булмый, чөнки ул шактый үзгә. Аны хәтта госманлы теле дип атау дөресрәк булыр иде. Әмма аның үз әсәрләрен татар укучысы өчен дә язган булуы, әлбәттә, Бигиевнең язма телен татар әдәби теленең, татар китап теленең бер аерылгысыз күренеше буларак кабул итәргә тиешбез. Димәк, татарлар өчен госманлы телендә язылган дини әсәрләрнең барлыгы үзеннән үзе аерым һәм үзенчәлекле бер филологик мәсьәлә тудыра.

Муса Бигиевнең дини фәлсәфәгә, гакыйдә мәсьәләләренә һәм дә теге яки бу шәригать мәсьәләләренә караган әсәрләрен тәрҗемә иткәндә мин шартлы рәвештә “аңлатмалы тәрҗемә” дигән алымның урынлы булуына килдем. Бу алым беренче чиратта, бүгенге көн укучысына авторның фикерләрен мөмкин кадәр аңлаешлы рәвештә җиткерүне тәэмин итә торган комплекслы тәрҗемә итү ысулын күздә тота. Гомумән алганда, теләсә нинди әдәби әсәр, бигрәк тә дини әсәрләр, берничә мәгънәви катламнан гыйбарәт булган нәрсә. Бигиев китапларын алганда исә, алардагы шундый мәгънә катламнарның берсе дә үзенең эчтәлеген җиңел генә ачмый. Димәк, аңлатмалы тәрҗемә ул һәр шундый катламны бүгенге укучы тарафыннан кабул ителерлек хәлгә китерүдән гыйбарәттер.

Мәслән, китапның язуын, ягъни графикасын алыйк. Сер түгел, бүгенге көндә гарәп язуын танучылар күпчелекне тәшкил итмиләр. Аны таныганнары да, мәсәлән, мәдрәсә бетергән кешеләр, билгеле катлам лексик байлык ичкләренәнн чыкмыйлар. Ягъни дини фәлсәфә һәм төшенчәләр белән бәйле сүз катламнарына кермиләр. Димәк, гарәп язуыннан гыйбарәт булган бу мәгънәви катламны үзләштерү күпкә кыенлаша.

Гарәп язуын танысак та, каршыбызда әсәрнең тагын бер мәгънәви катламы, ягъни Муса-әфәнденең кулланган язма теле дигән катлам пәйда була. Бу катлам да үзенең эчтәлеген җайлы гына ачмый, чөнки моннан алда инде искәртеп узганымчы, Муса-әфәнденең язма теле ул хәзерге татар теленнән шактый ерак, хәтта бик ерак тора. Ул тел хәзерге татар теленнән күпкә

бай, галим кулланган сүзләрнең күбесе бүгенге көн укучысына таныш түгел, анда бөтенләй ят сүзләр һәм гыйбарәләр бихисап, ул телнең тирәнлеге-киңлеге таң калдырырлык. Ул телнең фәлсәфәсе һәм сурәтләү мөмкинлекләре бөтенләй башка. Муса-әфәнде «Милләт атасы» данын казанган Исмәгыйль Гаспралыдан васыять буларак кабул ителгән чын мәгънәдә уртак төрки телдә язган.

Бу хәлдә аңлатмалы тәрҗемә кыйлу эше иске татар теленнән хәзерге татар теленә кайтарудан гына гыйбарәт түгел, ул күпкә кыенрак эш булып чыга, чөнки сүз иске татар теленнән тәрҗемә итү түгел, уртак төрки телдән тәрҗемә итү турында барырга тиеш. Ул телдә күпләп очраган ят вә аңлаешсыз сүзләрне хәзерге телгә тәрҗемә итү заруриятендә генә чагылмый ул. Монда бөтенләй үзгә булган фикерләү рәвешен аңлау зарур, аны хәзерге укучыга таныш булган төшенчәләргә әйләндерү зарур. Монысы иң авыр эш, чөнки йөз ел элек язма телебез бөтенләй башка төрле булган. Хәзерге вакытта безнең сөйләм телебез әдәби телдән әллә ни аерылмый, чөнки үз вакытында чын әдәби, фәнни телебез читкә алып атылган да, аның урынына сөйләм теле әдәби тел дәрәҗәсенә куелган булган. Биредә без чираттагы мәгънәви катламга юлыгабыз: ул да булса – уртак төрки тел. Кыска гына итеп әйткәндә, Муса-әфәнденең язма теле ул мәдрәсә-фәлән тәмамлаган мәгърифәтле татарлар тарафыннан гына түгел, Төркиядә дә, Госманлы империясе биләмәләрендә дә иркенләп укылган һәм аңлашылган. Шуннан файдаланып, Муса әфәнде хәтта 1931 елда да әле татар-госманлы телендә язылган кайбер әсәрләрен Мисырда бастырган булган, чөнки аны укырлык зыялылар даирәсе ул заманда әле һаман да сакланып килгән булган. Ул гына да түгел, Муса-әфәнде өчен «татар теле», «төрек теле» дигән төшенчәләр гомумән булмаган. Аның өчен бу ике тел бер булган. Моның шулай икәнлеге китапның тәрҗемәсен укырганда яхшы күренә һәм, өстәвенә, «китапның мәгънәви катламнары», дигән гыйбарәнең дә ни икәнлеге аңлашыла.

Бу “аңлатмалы тәрҗемә” ысулын укучы өчен камилләштерү, аны тирәнәйтү эше һаман дәвам итә.

Эшнең нинди булуын күрсәтер өчен Бигиев әсәрләренең берсеннән бер мисал китерәсем килә:

«*Мәзһәбләрнең беренә ияру зилләтләреннән*[4], *кәлам ысуллары белән тәхриф кыйлынмак*[5]*нәкыйсаларыннан*[6]*Коръән кәрим, минем игътикадымда, әлбәттә, пакьтер. Игълалчыларның*[7]*ислахларына ихтыяҗ кичерү мескенлекләреннән Коръән кәримнең могъҗизалы назымы*[8]...».

Әлеге мисалда очраган Китап сәхифәләренең байтагында аңлаешсыз сүз вә гыйбәрәләрнең аңлатмалары астөшермә шәкелендә бирелде. Аерым очракларда бу астөшермәләр ясау алымы хәттин ашкан кебек күренергә мөмкин.. Юкса, бу җөмлне дә башкалар кебек татарчага мөмкин кадәр тулырак тәрҗемә итеп булыр иде кебек. Әмма, бу очракта асыл нөсхәдәге сүзләрнең күбес тәрҗемә ителмичә калдырылды. Болай итүнең мәгънәсе бар, чөнки биредә авторның фикерләрен генә түгел, ул кулланган терминнарны да күрсәтү зарурияте бар. Мондый алым дини тематика белән якыннан кызыксынучылар өчен уңайлы булыр дип ышанып калам.

Астөшермәләр ясау алымы Муса-әфәнде кулланып та, безгә аңлашылмаган сүзләрнең һәммәсенә дә кагыла, дип кабул итәргә ярамый. Астөшермәләрдә асыл тексттагы сүз вә гыйбәрәләрнең бер өлеше генә бирелде, чөнки һәр аңлашылмаган сүзнең мәгънәсе астөшермәгә юлланган булса, китапның яртысыннан артыгы шул астөшермәләрдән гыйбарәт булыр иде. Нәтиҗәдә аны ни тәрҗемә дип атап булмас иде, ни аңлап булмас иде. Шуңа күрә,

---

[4]*Зилләт* – түбәнсенү, хурлык.

[5]*Тәхриф кыйлынмак* – үзгәртелү, мәгънә бозылу.

[6]*Нәкыйса* – пычырак.

[7]*Игълал* – сүздәге сузык авазларның урыннарын үзгәртүдән гыйбарәт булган алым. Гарәп телендә кыска сузык авазлар язуда хәрефләр белән түгел, хәрәкәләр белән белдереләләр. Шуңа күрә сүзнең мәгънәсен хәрефләргә кагылмыйча хәрәкәләрне алмаштыру исәбенә үзгәртергә мөмкин. Мәсәлән: *җәннәт* (оҗмах) һәм *җиннәт* (җенләнү, тилелек).

[8]*Назым* – сүзләр, гыйбарәләр, җөмләләр һәм эчтәлекнең камил бербөтенлегенән гыйбарәт булган Коръән тексты.

асыл нөсхә мөмкин кадәр тулы рәвештә татарчага тәрҗемә ителде. Әмма, болай ителгәндә дә телебез аз булса да баеп, киңәеп китәр дигән өмет белән кайбер «ят» сүзләр тәрҗемәгә кертелде, һәм аларның мәгънәләре махсус аңлатмаларда ачылды.

Китапны тәрҗемә итеп, аңлаешлы бер шәкелгә китергәннән соң эшне тәмамнан санарга ярамый, чөнки бу очракта китапка салынган тагын бер мәгънәви катлам ачылмыйча кала. Ул да булса асыл китапта телгә алынган шәхесләр, китаплар, вакыйгалар. Болар турында да мөмкин кадәр күбрәк мәгълүмат бирелергә тиеш, чөнки бу Муса-әфәндене заманын да, аның интеллектуаль офыкларының киңлеген дә яхшырак аңларга мөмкинлек бирә. Автор телгә алган шәхесләр арасында кемнәр генә юк. Аларның һәрбере милләтебезнең һәм ислам дөньясының горурлыгы, бүгенге көндә дә безнең өчен үрнәк булырлык олпат затлар.

Бигиевнең әсәрләрендә гарәп һәм фарсы телендә бирелгән шигъри юллар да байтак, чөнки Муса-әфәнде борынгы гарәп һәм фарсы әдәбияте һәм шигърияте белгече, хәтта остасы булган. Болай булганда без китапның тагын бер мәгънәви катламы турында сүз йөртә алабыз. Бу мәгънәви катламны да, әлбәттә, сыйфатлы тәрҗемә итүне кайгыртырга кирәк.

Моннан тыш, орфография, тагын да төгәлрәк итеп әйтсәк – гарәп-фарсы сүзләр һәм терминнарны хәзерге татар телендә бирү (транслитерация) мәсьәләсе дә бар. Әлегә кадәр кабул ителгән транслитерация кагыйдәләре кайбер очракларда үзен акламый. Бу йөздән, дини текстларны тәрҗемә иткәндә кулланылу өчен махсус тамгалар кабул итү урынлоы булыр иде.

Мәсәлән:

*Заман* (زمان) сүзе һәммәбезгә мәгълүм. Әмма Бигиевнең әсәрләрендә шул ук мәгънәдә булган (زمن) *зәмән* сүзе дә кулланыла. Бу ике сүзнең хәзерге татар теле кагыйдәләре буенча язылышында аерма юк, ә ул булырга тиеш.

Алга таба *заман* (ضمان) (җаваплылык; тәэмин итү(гарантия) сүзен алыйк: бу сүзнең татарча язылышы *заман* (زمان) сүзенең язылышына туры килә. Һәрхәлдә, М.И. Мәхмүтовнең “Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге”ндә (Казан, 1993. Т. I.) бу ике сүз берберсеннән румалы I һәм II саннары белән аерымланганнар. Әмма Бигиевнең фикъһыга караган китапларын тәрҗемә иткәндә ни кыйлырга? Әлеге ике сүз арасындагы аерманы ничек күрсәтергә? Сүзләр очыраган саен астөшермәләр язаргамы, җәя эфендә гарәпчә язылышларын китерергәме? Әмма мәсьәлә ике хәрефнең берберсеннән аерманы күрсәтүгә генә кайтып калмый. Андый хәрефләр гарәп әлифбасында байтак. Андыйлардан (ز), (ض), (ذ), (ظ) кебекләрен атау да җитә. Татар язуында болар һәммәсе дә *З/з* хәрефе белән биреләләр. Чынлыкта, әлеге хәрефләрне хәзерге татар языунда чагылдырыр өчен парлы хәрефләр яки махсус тамгалар кабул итәргә кирәктер, могаен: (ذ) - З̧/з̧; (ز) – З/з; (ض) - Ḋ/ḋ; (ظ) – Ӟ/ӟ.

Кузгатылган мәсьәлә гаять киң һәм тирән, аны бер мәкалә кысаларында, әлбәттә, хәл итеп булмый. Ул комплексло гыйльми-филологик тикшеренү башлануын һәм белгечләрнең бу юнәлештә даими төстә эш алып баруларын таләп итә.

**Әдәбият**


1. Бигиев М. Шәригать исламия әлифбасы мөсабәсендә игътибар кыйлына билүр кавагыйд фикъһия: Әхкям шәргыя мәҗәлләсенә мәдхаль улмак сыйфатыйлә. –Казан: Әхмәд әл-Исхакый, 1910. – 232 б.
2. Мәхмутов М.И., Хәмзин К.З., Сәйфуллин Г.Ш. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге (татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре). I том. – Казан: Иман, 1993. – 448 б.

УДК 82

# ПОНЯТИЕ «ЦЕННОСТЬ СЛОВА» В ЛИТЕРАТУРНЫХ ПРОИЗВЕДЕНИЯХ XXI ВЕКА: ОБЩЕТЮРКСКОЕ НАЧАЛО И СОВРЕМЕННЫЙ ВЗГЛЯД
# XXI ГАСЫР ӘДӘБИ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ «СҮЗ КЫЙММӘТЕ» ТӨШЕНЧӘСЕ: ГОМУМТӨРКИ БАШЛАНГЫЧ ҺӘМ ЗАМАНЧА КАРАШ

***Ханнанов Рамиль Гумарович***
ГАОУ «Полилингвальный комплекс «Адымнар - путь к знаниям и согласию»,
г. Казань, Татарстан, Российская Федерация
*e-mail: ramilkhannanov@yandex.ru*

**Аннотация.** *В статье рассматриваются актуальные вопросы языка современных художественных произведений, делаются выводы о часто допускаемых ошибках, определяются способы решения данной проблемы.*

**Ключевые слова:** *литературный язык; значение (ценность) слова; литературный стиль; литературное редактирование и корректировка.*

# THE CONCEPT OF «THE VALUE OF THE WORD» IN LITERARY WORKS OF THE XXI CENTURY: COMMON TURKIC ORIGIN AND MODERN VIEW

***Khannanov Ramil Gumarovich***
SAEI «Polilingual complex «Adymnar - the way to knowledge and consent»,
Kazan, Tatarstan, Russian Federation

**Abstract**. *The article discusses topical issues of the language of modern works of art, draws conclusions about common mistakes, identifies ways to solve this problem.*

**Keywords**: *literary language; meaning (value) of a word; literary style; literary editing and correction.*

Тел – тере организм. Ул һәрвакыт үсештә, үзгәрештә, хәрәкәттә. Матур әдәбият – телнең көзгесе. Без ничек сөйләшәбез – әсәрләребездәге геройлар да шулай. Әдәбият халыкның, милләтнең тормышын чагылдыра. Халык: “Хәрәкәттә – бәрәкәт”, ди. Туган телнең саулыгы, иминлеге милләтнең сәламәтлегенә бәйле. Милләт кай тарафка таба ни рәвешле хәрәкәт итсә, телебезгә насыйп бәрәкәтне дә шул яктан көтәргә кирәк. Төп максат – бәрәкәт китерердәй кыйбланы дөрес билгеләү.

Теоремалар дәлиллисе юк. Халык язучысы Марсель Галиев тел организмында барган процессны гади генә аңлата: “Үз байлыгыннан үзе сыгылып торган тел тирәгенең эшчән тамырлары җир тирәнлегендәге чишмәләргә тоташкан да, яшәү сутын гасырлар төпкеленнән ала-ала, өскә, яктыга чөеп, һәммә яфрак-сүз кадеренә микъдарлап тараткан”.

Күрәбез ки, язма һәм сөйләм телебезнең сафлыгы хакында сүз йөрткәндә, “җир тирәнлегендәге чишмәләргә тоташкан эшчән тамырлар” кәлимәсен онытмау зарур. Ягъни хәзинәбез бай, тиешлесен юллап ала белергә генә кирәк. Аеруча да бүгенге әдәбиятыбызны барлыкка китерүче каләм ияләренә. Кызганыч, юллау күп вакыт сарыф иткәнгәме, үзгә тел сүзләрен файдаланып юанучылар нур тизлеге белән көннән-көн арта бара.

Әдәби телгә хәрәкәтчәнлек, җанлылык өстәргә теләүме – сүз сәнгатенә гади сөйләм лексикасы мулдан үтеп керде. Аеруча да чит телләрдән алынган кыска, яңгыравык, “ата торган” сүзләргә баеп барабыз. Алар матур әдәбиятны да шактый чуарлый. “Тәки” (так и) кәлимәсе инде калыплашып урнашып килә, “кәнишне”, “зерә”, “жәлке”ләр әкренләп үз урынын дәгъвалый, “патамушты”, “тучны”, “пака-пака”лар чиратка тезелгән. Заманында оялып кына “ишек шакыган” “бит” (ведь) сүзенең безнеке түгеллеген хәтерләүче дә сирәктер бүген...

Шул рәвешле, туган телебезнең сүзләрен читкә тибәреп, башкалардан әҗәткә кәлимәләр җыябыз. Без моңа мохтаҗмы? Бәхәсле сорау.

“Утта тотылып, сандалда чүкелгәннән соң, үз телебезнең яңгырашына ягымлыланып күчкән” алынма сүзләргә ихтирам, олы хөрмәт белән якын килергә чакыра Марсель Галиев “Рух” поэмасында. Ә без шулай итәбез дә. Әби-бабайлар, телләрен сындыра-сындыра, аларны әйтергә юкка өйрәнгәнмени?!

Бөек шагыйребез Дәрдемәнд исә заманында болай ди: *“Канча тартсаң, и мөхәррир, сүзне чит тел сибенә, / Тел ясалмас, гәр туган сүз ятмаса үз ибенә”.*

Үз ибенә яткыручы, әлбәттә – халык, чөнки тел берәр сүзне син яисә мин ялгыш әйтүдән генә бозылмый. Хак хөкемне халык чыгара. Һәм... вакыт. Шулай да алама гадәт җилем кебек бик тиз ябышкан заманда сак кылану, итәк-җиңнәрне җыеп йөрү мәслихәт.

Туган телдәге үз сүзләребезне, аеруча да аларның мәгънәләрен тәгаенләмәү очракларының ишәюе көн кадагында тора. Әдәби әсәрләрдә каләм ияләре еш бутаган синонимик рәтләрнең берсе “дәвер”, “чор”, “заман”, “вакыт”, “чак”, “мәл” исемнәре белән бәйле.

“Университетта (мәктәптә, мәдрәсәдә һ.б.) уку дәверендә”, дип язуны гадәткә керттек. Кешегә карата әйтелгәнен баштан ук искәртеп куйыйк. “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге” (алга таба – сүзлек) “дәвер”сүзен түбәндәгечә шәрехли. *Дәвер – чор, заман. Вакыт. Берәр процессның үсешендәге бер баскыч, стадия.*Күргәнебезчә, дәвер шактый зур вакыт аралыгын үз эченә сыйдыра. “Университетта уку чоры”, дию дә телебезгә туры килеп бетми. “Чор” сүзе, гомумән, фигыльләр янәшәсендә кулланылмый диярлек, чөнки кешенең эш-гамәлләрен төгәл билгеләгән фигыльләр аның төсмерен тарайта: “бару чоры”, “ашау чоры”, “уку чоры”, “эшләү чоры”, дип сөйләшми татар. Сүзлектә “чор”ның биш мәгънәсе тәкъдим ителә. *Чор – 1. Нәрсә белән дә булса (мәсәлән, иҗтимагый шартлар белән) чикләнгән вакыт аралыгы, бер процесс, вакыйга барган вакыт. 2. Ниндидер күренекле вакыйгаларны үз эченә алган, үзенә нинди дә булса үзенчәлекләр хас зур вакыт аралыгы. 3. Үсешнең, берәр эшчәнлекнең бер стадиясе, аерым бер моменты. 4. Хәзерге заман, хәзерге вакыт. 5. Геологик система катлауларының утырмалары барлыкка килгән вакыт аралыгы, эраның бер өлеше.*

Күргәнебезчә, “дәвер” һәм “чор” сүзләре башлыча киңрәк, глобаль; тәгаен бер кешенең эш-гамәле белән генә чикләнмәгән вакыт аралыгын билгеләгәндә кулланылалар. Аларга мәгънәдәш “заман” сүзе бар.Сүзлек аны түбәндәгечә аңлата:***заман*** *– җәмгыять яшәвенең бер вакыты, чоры; вакыт.*

“Университта укыган заманда”, дип язсак, тагын кешегә мөнәсәбәте булмаган билгесезлектә яшеренеп калган борынгы чор мәгънәсе килеп чыга, әкият башламына охшаш (борын-борын заманда), еллары төгәл ачыкланмаган калып формалаша.

Ә менә “университетта укыган чакта”, “университетта укыган вакытта”, дисәк, кешегә карата әйтелүе белән дә, мәгънә ягыннан да дөрес яңгырый. Сүзлектә “чак”ның – ике (*чак – 1. Кеше билгеле бер урында яшәгән, булган яисә яшь аралыгына туры килгән вакыт. 2. Нинди дә булса эш-хәрәкәт башкара торган, берәр күренеш бара торган вакыт*), “вакыт”ның унбер мәгънәсе бирелә. Безнең очракка туры килгәннәрен генә алыйк. *Вакыт – 1. Нәрсәнең дә булса секундлар, минутлар, сәгатьләр, еллар, гасырлар һ.б. шундыйлар белән исәпләнә торган яшәеш арасы, дәвамлылыгы. Яшәеш дәвамлылыгын үлчәү берәмлеге. 2. Берәр эш, вакыйга барган чак. 3. Берәр эш өчен билгеләнгән срок. Билгеләнгән срокның чиге.*

Вакыт аралыгын белдергән “мәл” сүзе дә бар (сүзлектә:*мәл – чак, вакыт*),тик таррак мәгънәле булу сәбәпле, ул безнең очракка туры килми.

Шулай итеп, “университетта укыган чакта”, “университетта укыган вакытта” дип язу мәслихәт.

Әдәби телебезнең сафлыгына хилафлык китерергә әзер торган күренешләр һәрвакыт уяу. Җирле сөйләшләрнең әрсез сүзләре, сүз формалары да әнә шундыйлардан.

“Бересе”, “өчесе”, “берсесе”, “бусысы”, “ансысы”, “бүгенгесе”, “дәүрәгрәк” – диалектология фәнендә кушымчаларның плеонастик (икеләштереп) ялгануы аркасында барлыкка килгән әдәби тел хаталары. Алар фәкать урта диалектның Казан арты һәм Бәрәңге

сөйләшләренә карый. Күп кенә язучыларыбызның, мөхәррирләрнең дә шул төбәкләрдән чыгуын исәпкә алганда, әлеге хаталарны булдырмый калырга тырышу өметсез нәтиҗәләр бирә.

*"Бүген ничәсе әле ул? Бересеме?" "Авылдан мәрхүмә әнкәйнең өчесен укытып килдек". "Бүгенгесе көндә тормышыбыз җиңел түгел"* кебек калыпларны әдәби телебездән кысрыклап чыгара алуыбыз бик шикле. Нишләп алайса "икесесе", "алтысысы" түгел, мәрхүмнәрнең "кырыгысы"н укытмыйбыз? Чөнки әдәби телдә мәсьәләнең хак чишелеше болай яңгырый: бер+е, ике+се, өч+е, алты+сы, тугыз+ы, кырык(г)+ы. Тартыкка беткән санга – тартым кушымчасының -ы/-е, сузыкка беткән санга -сы/-се варианты ялгана. Бутарга ярамый торган бер очрак бар: тартыкка беткән микъдар саны өченче затта тартым белән төрләнсә, -ысы/-есе кушымчасы ялгана. Мисал: *"Нәселгә калдырылган унөч сарыгымның унысы – ак, өчесе кара иде".* Күрәбез, мәгънә гел үзгә. Әгәр бик тә "бутыйсыбыз килә" икән инде, мәсьәләнең асылын болайрак аңлатып була: *"Айның утыз көне бар. Бүген безгә шуларның өчесе килгән, иртәгә дүртесе киләчәк! Шуңа күрә бүген өче түгел – өчесе, иртәгә дүрте түгел – дүртесе".* Тик бу әдәби тел нормасыннан бик ерак тора һәм аның камиллегенә хилафлык китерә.

Әдәби әсәрләрдә сүзләрне урынсыз куллану очраклары белән бәйле хаталар да еш күзәтелә. Мәсәлән, "нинди" белән "кайсы" алмашлыклары ничек аерыла? "Аңлатмалы сүзлек" болай ди: *"Нинди – кемнең яки нәрсәнең дә булса үзенчәлеге, сыйфаты турында сораганда кулланыла".* Мисал: *"Шагыйрь яшәгән заманны күзаллап, аның кечкенә Апуштан зуп-зур Тукай дәрәҗәсенә күтәрелә алуын, бөеклеккә нинди фаҗигаләр бәрабәренә ирешүен тирәнтен аңларга телим". (Зиннур Мансуров)*

*"Кайсы – күпләр арасыннан берсен белү өчен сораганда кулланыла".* Мисал: *"Бишегемне тирбәткәндә, әнкәй / Кайсы көйне икән көйләде?" (Газинур Морат)*

"Кайда" һәм "кая" алмашлыклары белән дә шул ук хәл.

"Аңлатмалы сүзлек"тә: *"Кайда – кемнең яки нәрсәнең урынын белергә теләп сораганда кулланыла".*Ягъни, төгәл җирлек күздә тотыла, абстрактлыкка урын калдырмый. Мисал: *"Әлү! Кызым... Азалия! Син кайда?" (Ркаил Зәйдулла)*

*"Кая – кайсы җиргә, кайсы якка".* Ягъни, төгәл урын күздә тотылмый, гомумилекне белдерә, абстракт юнәлеш-тарафны билгеләү максатында кулланыла. Мисал: *"Аларның һәркайсы Рәискә, фәрештә үк булмасалар да, эш-гамәлләре, сөйләгән сүзләре, язган әйберләре белән каядыр биектә, күктә утыручылар булып тоела иде". (Флүс Латыйфи)*

Күргәнебезчә, "нинди" белән "кайсы"ны, "кайда" белән "кая"ны тиешле урында куллану артык авырлык сорамый. Инде "белән" бәйлеген куллануның бүген актуаль яңгыраган урынлы-урынсыз очракларына тукталыйк.

"Аңлатмалы сүзлек"тә "белән" бәйлегенең унбер мәгънәсе бар. Җиденчесе (безнең очрак) болай: *белән – вакыт төшенчәсен биргән исемнәр янында килеп, вакыт хәле (рәвеш) ясый.*

Замандаш язучыларыбызның әсәрләрендә тәүлек вакытына нисбәтле бәхәсле очраклар да күзгә еш чалына башлады: "иртә белән", "кич белән", "төнлә белән".

Тәүлек вакытларына аерым-аерым тукталыйк һәм сүзлектән аларның мәгънәләрен барлыйк.

*Иртә (исем) – тәүлекнең бер өлеше, көннең беренче сәгатьләре, көннең башы.* Бу исемнән вакыт хәле (рәвеш) ике юл белән ясала: *-н* кушымчасы (суффиксы) *(иртән – иртә белән, иртәнге вакытта)* һәм *"белән"* бәйлеге *(иртә белән – иртән, көннең башында)* ярдәмендә.

*Көн (исем) – тәүлекнең бер өлеше, кояш чыкканнан башлап, кояш батканчыга кадәрге вакыт, иртәдән кичкә кадәр булган ара.* Әлеге исемнән вакыт хәле (рәвеш) бер генә юл белән ясала: *-дез* кушымчасы *(көндез – иртә белән кич арасындагы вакытта)* ярдәмендә. (Рифкать Әхмәтьянов төзегән "этимологик сүзлек" болай ди: "Бу борынгы сүз "андыз", "балдыз", "кондыз" һ.б. моделендә ясалган булырга тиеш: -дыз / -дез морфемасының асылы әлегәчә

ачыкланмаган”. Ачыкланмаса да, “көндез” сүзенең тамыры “көн” булуда шик тумый.) “Көндез”гә *-ен* кушымчасы ялганып, шул ук мәгънәдәге сүз ясала – *“көндезен”.*

Бер искәрмә бар. XX гасыр башы татар әдәбиятында “көндез” сүзе исем буларак та кулланылган. Мисал: *“Июньнең башы, ап-ачык кояшлы көннең көндезе”. (Фатих Әмирхан)* Бу очракта: *көндез (исем) – иртә белән кич арасындагы вакыт.* Әмма әлеге форма инде актив түгел.

*Кич (исем) – тәүлекнең көн бетеп, төн башлануга кадәр булган вакыт арасы.* Бу исемнән вакыт хәле (рәвеш) ике юл белән ясала: *-ен* кушымчасы *(кичен – кич булгач, кич вакыты җиткәч)* һәм *“белән”* бәйлеге *(кич белән – кич җиткәч)* ярдәмендә.

*Төн (исем) – тәүлекнең кояш батыштан кояш чыгышка, кичтән иртә беләнгә кадәрге өлеше.* “Төн”нәнвакыт хәле (рәвеш) бер генә юл белән ясала: *-лә* кушымчасы *(төнлә – төнге вакытта)* ярдәмендә.

“Көндез белән”, “көндезен белән” димәгән кебек, “төнлә белән” дип сөйләү, язу да хата. Рәвешне тагын да рәвешләрәк итү нигә хаҗәт? “Майлы май” мислерәк килеп чыга бит! Әле аның “иртә белән”е дә колакны сагайта. (Ә менә “таң белән” табигый яңгырый.) “Иртәнге якта”, “иртәнчәк” кебек кәлимәләребез юкмыни?!

Күрәбез ки, грамматик кагыйдә нигезендә, “белән” бәйлеге тәүлекнең ике генә (иртә, кич) вакытына нисбәтле вакыт хәле (рәвеш) ясауда катнаша.

Ясау дигәннән, әзер, мөкәммәл сүзнең “тормышы”на тыкшынып, кирәкмәгән кушымчалар өстәп, камил укылышны абындыру очраклары аз түгел. “Мөмкинчелек” – әнә шундыйлардан.

“Аңлатмалы сүзлек”тә “мөмкинчелек” сүзе юк! Ә *мөмкинлек – 1) берәр эш-хәлнең булу-булмавын тәэмин итә торган хәл, шарт, җай. 2) мөмкин булу, ихтималы булу, ихтималлык,* дип шәрехләнә.

Сүз ясалышы ягыннан мантыйкка таянып фикерлик: “мөмкинлек” – *“мөмкин”* хәбәрлек сүзеннән *-лек* кушымчасы ярдәмендә ясалган исем. “Мөмкинче” кәлимәсе телдә юк. Ә *-чылык /-челек* кушымчасының үтәгән вазифасы үзгә бит. Ул ике генә сүз төркеменнән яңа сүзләр ясый: исемнән – исем (кошчылык, дәүләтчелек һ.б.), рәвештән – исем (азчылык, түбәнчелек, кимчелек һ.б).

Семантик яктан янәшә булган, ләкин өчесе өч төрле модаль мәгънә төсмерен белдереп килгән, бүгенге әдәби телдә актив кулланылышта йөргән хәбәрлек сүзләребез нибары өчәү генә: “кирәк” (зарурилык / необходимость), “тиеш” (тиешлек / долженствование), “мөмкин” (мөмкинлек / возможность). “Мөмкинчелек” вариантына калган икесен куеп карыйк: “кирәкчелек”, “тиешчелек”. Яңгырыймы? Юк! Димәк, грамматик хата.

“Өлкән буын телне салмак олыгайтып яшәтсә, яшь буын телне санлап яшәртә. Шушы табигый бизмәннең ике яссылыгы да тигез тибрәнештә булганда гына телнең терек сулышы бөтен мөмкинлегенә киерелеп ачыла”, – ди Марсель Галиев.

Шуңа күрә, әдәби традицияләргә тугры калып, туган телебезнең сафлыгын, камиллеген хәзерге заман әсәрләрендә дә сакларга омтылырга кирәк. Ата-бабаларыбыздан килгән сүз-сурәт энҗеләре XXI гасыр әдәбиятында да бар тулылыгында чагылсын, киләчәк буыннарга “терек сулышы” зәгыйфьләнмичә барып җитсен иде.

**Әдәбият**


1. Галиев М. Әсәрләр. 6 томда. – Т 2. – Казан: Идел-Пресс, 2011.
2. Дәрдемәнд. Фотоальбом (Төз. Зөфәр Рәмиев, текст авт. Лирон Хәмидуллин). – Казан: Татар.кит.нәшр., 2003.
3. Татар грамматикасы. 3 томда. – Т 2. – Мәскәү: ИНСАН, Казан: ФИКЕР, 2002.
4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1977, 1979, 1981.

УДК 82

# КОНЦЕПТ «ЖИЗНИ» И «СМЕРТИ» В РАССКАЗЕ РУСТЕМА ГАЛИУЛЛИНА «ПРОЩАЙТЕ, ЛЮДИ!» РӨСТӘМ ГАЛИУЛЛИННЫҢ «ХУШЫГЫЗ, КЕШЕЛӘР!» ХИКӘЯСЕНДӘ «ЯШӘҮ» ҺӘМ «ҮЛЕМ» КОНЦЕПТЫ

***Хуснутдинова Раиля Нуретдиновна***
ГАОУ «Полилингвальный комплекс «Адымнар - путь к знаниям и согласию»,
г. Казань, Татарстан, Российская Федерация
*e-mail: khusnutdinova-railya@mail.ru*

**Аннотация.** *В статье рассматриваются концепты«жизнь» и «смерть» в рассказе молодого писателя Р. Галиуллина «Прощайте, люди!», делаются выводы об их роли в понимании главной идеи произведения.*
**Ключевые слова**: *Р. Галиуллин; «Прощайте, люди!»; концепт «жизнь»; концепт «смерть».*

# CONCEPTS OF «LIFE» AND «DEATH» IN THE STORI «FAREWELL, PEOPLE!» BY RUSTEM GALIULLIN

***Khusnutdinova Railya Nuretdinovna***
SAEI «Polilingual complex «Adymnar - the way to knowledge and consent»,
Kazan, Tatarstan, Russian Federation

**Annotation.** *The article considers the concepts of "Life" and "Death" in the story of a young writer R. Galiullin "Farewell, people!", conclusions about the role of these concepts in understanding the main idea of the story are made.*
**Keywords:** *R. Galiullin; Farewell; people; concept of "Life"; concept of "Death".*

Концептларны өйрәнү заманча лингвистикада зур роль уйный, чөнки концепт, тел кебек үк, кешенең аңын һәм менталитетын формалаштыра. Концепт дөньяны танып белүнең мөһим чарасы булып тора, концептлар җыелмасы – «...кеше аңының һәм фикерләүнең мәгълүмати базасын тәшкил итә» [4].

Концептларны өйрәнү – язучының иҗатын өйрәнүдә аеруча зур әһәмияткә ия. Шунысын истә тотарга кирәк: авторлык концептлары булган сүзләрне, сүтезмәләрне, фразеологизмнарны, синонимик рәтләрне җентекләп өйрәнмичә,әдәби әсәрне анализлау мөмкин түгел. Әсәрдәге концептларны анализлау аерым язучының дөньяга карашын билгеләргә ярдәм итә һәмүзеңә дә уйланырга, эзләнергә этәргеч ясый

Әгәр аңлатмалы сүзлеккә күз салсак, **Яшәү** – 1) гомер итү, тору; 2) нәрсә белән дә булса кызыксыну, нәрсәне дә булса тормышта иң әһәмиятлесе дип исәпләү; актив, эшчән тормыш алып бару; 3) нинди дә булса тормыш алып бару; 4) кайда да булса даими рәвештә тору, урнашкан булу; 5) берәр нәрсәнең эшен, хәрәкәтен дәвам иттерү турында; 6) күч.мәгъ. саклану, онытылмау; 7) боер.фиг.форм. яшә, яшәсен. Уңышлы эшләр, бәхетле тормыш һ.б. кебек изге теләкне, хуплауны белдерә[5, с. 664-665].

**Үлем** – 1) Организмныңэшчәнлеге тукталу һәм аның һәлак булуы; организмда яки аның бер өлешендә матдәләрнең биологик алмашынуы тукталу; 2) кеше яки хайванның яшәүдән тукталу хәле; 3) хәб.функц.- начар нәрсә, кайгы, бәла [5, с. 728].

Әлеге төшенчәләрне тагын бионика фәне өйрәнә. (Бионика – инглиз. bionics,bion сүзеннән – тере җан, организм; грек. Bioo – яшим).Фәлсәфи күзлектән караганда, Яшәү – дөньяның үзенчәлекле сыйфатый халәте һәм, бәлки, Галәм үсешендәге мөһим баскычтыр. Бергсон аны образлы итеп – янып төшеп баручы ракета белән чагыштыра: ракетаның

кубарылучы кисәкләре үле матдә хасил итә. Фәндә биологик системаның эшчәнлеге тукталу буларак каралган үлем фәлсәфәдә рациональ кабул итү һәм аңлау сорала торган иҗтимагый феномен дип аңлатыла [6, с. 273].

Изге китапка да күз салу мөһим, чөнки Коръән ул – Аллаһның кешелек дөньясына биргән илаһи программасы һәм инструкциясе.Яшәү һәм үлем ул – кешенең ике халәте. Яшәүдән курыкмаган кеше үлемнән дә куркырга тиеш түгел.Никадәр генә дөньяны яратсак та, барыбер калдырып китәчәкбез. Байның да, ярлының да, көчленең дә, көчсезнең дә, хуҗаның да, хезмәтченең дә үлемнән котылып калу чарасы юк.Үлем ул – мәңгелек халәткә күчү капкасы гына. Аллаһ кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып, нәфесеңнән өстен булып яшәгәнсең икән, үлем ул – мәңгелек сәгадәткә күчү капкасы һәм хак мөэмин аннан курыкмас, җанын җиңел бирер. Әгәр үзеңне генә яратып, Аллаһны танымыйча, нәфес колы булып яшәсәң, үлем – мәңгелек газапка алып керүче капка, андый кеше үлемнән курка һәм җанын да авыр бирә. Пәйгамбәребез: «Үлем – иң зур гыйбрәт һәм иң зур гыйбадәт», – диде. Үлем безгә ни өчен яшәвебезне аңларга, гамәлләребезне төзәтергә, күңелләребезне нечкәртергә ярдәм итә.

